ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№02 (397)
ФЕВРАЛЬ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ВЛАДИМИР ПАВЛЕНКОВНЫҢ «БАТЫРЛЫК ӨЧЕН» МЕДАЛЕ



№02 (397)
ФЕВРАЛЬ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Олег Платонов, Наилә Хәйретдинова
Фотографлар: Александр Ефремов, Айдар Мөшәрәпов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Владимир Павленков. Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-0018
Басарга кул куелды: 19.02.2025
Чыгу көне: 24.02.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ҺАВА ШАРТЛАРЫНДА

Февральдә, традиция буларак, «Татарстан» журналы ирләрчә җитди, кырыс, хәрбигә әверелә. Чөнки бу айның төп бәйрәме – Ватанны саклаучылар көне. Хатын-кызлар үзләренең әтиләрен, бабайларын, ирләрен, улларын, оныкларын, дусларын һәм коллегаларын котлый. Бүләкләр хәстәрли, бәйрәм табыны кора һәм кинәт кенә, мең мәшәкать эчендә туктап калып, бер хакыйкатькә төшенә: сүз бит аларга туган, газиз һәм якын кешеләр турында гына бармый. Ә кулларында ил язмышы булган затлар турында.

Алар офис портфеле тотып эшкә яисә кармак эләктереп балыкка чыгып китәсе урынга, көннәрдән бер көнне, кулларына корал алып, моннан мең чакрымнар еракка – ватанны сакларга юл тотарга мөмкин. Теләсә кайсы мизгелдә. Кабат әйләнеп кайтмаска да – язмышка нәрсә язылгандыр…

Шуңа күрә безгә аларны тагын да ныграк кадерләргә, яратырга кирәк. Кочакларга, үбәргә һәм котларга:

Бәйрәм белән сезне, кадерле Ватанны саклаучыларыбыз!

Сезне һәрчак ярата торган редакциягез.

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп бирешлә,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп бирешлә,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары ТИК ТАТАРСТАНДА

КАЗАН ЭЗЕ – АНТАРКТИДАДА

Антарктиданы 1820 елның 28 гыйнварында ачалар. Бу ачышны Россия хәрби-диңгез экспедициясе җитәкчеләре Фаддей Беллинсгаузен һәм Михаил Лазарев исемнәре белән бәйләп карау гадәткә кергән. Асылда исә «Восток» белән «Мирный» шлюпкаларында билгесез материкка 205 ел элек иң беренче булып якын килгән бердәнбер галим 25 яшьлек Казан университеты профессоры Иван Симонов була. Кем белә, бәлки, нәкъ менә ул беренче булып горизонттагы кар-боз белән капланган тауларның яңа континент икәнен абайлап алгандыр? Иван Симонов бу җир тирәли экспедициядә астрономия, география, этнография, биология буенча күзәтүләр алып бара – монысы инде тәгаен дәлилләнгән факт. Ул әле беренчеләрдән булып Антарктидадагы магнит полюсын да билгели, һәм бу бик әһәмиятле ачыш санала.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Дөньяның иң гүзәл урыны
Әби патша татар авылын ничек шәһәргә әйләндергән

8. Пушкин әкиятендәге ботка
Безнең кайсы продуктка дус булмаган илләрдә дә ихтыяҗ зур

12. Мальдивмы? Булмас, димә!
Шәп су коену урыны кайда пәйда булачак

14. Буача яңарыш
Кайсы лицей 3D-технологияләр белән дус

18. Җылы кием-салымнан алып беспилотникларга кадәр
Район фронтка ничек булыша

20. Уңыш коды
Ни өчен яшьләр «Мирас»ка тартыла

24. Сугышкан. Янган. Исән калган. Җиңгән
Ничек 105 яшькә җитәргә һәм ирешкәннәрдә туктап калмаска

28. Патшабикә рөхсәт биргән мәчет
Тинчәле тарихы ни сөйли

игелекле эшләр

48. Дошманга каршы – берүзе
Капитан Әхмәтшин экстремистларны ничек туктаткан

50. Өч сугышчы
«Сугыштан соң» дип аталган монументта кемнәр сурәтләнгән

56. Куркусыз командир
Герой танкист бер бәрелештә 16 танкны ничек сафтан чыгарган

58. Кавалерист кыз
Соколов фамилиясе астында кем яшеренгән

62. Гамьле әңгәмә
Махсус хәрби операциядәге сугышчылар нинди җырларны яратып тыңлаган

66. Күрү үзлегенә ия газ
Фән безне нәрсә белән шаккатырырга сәләтле

74. Һәр кешенең әрнүе үзенекедәй
Халык предприятиесенең халык директоры

мәңгелек кыйммәтләр

78. Бронзада, ташта, хәтердә...
Каюм бабай мирасы

84. Китап киштәсе
Язучы Марат Кәбиров нәрсәләр укый

88. Таныш булыгыз: Кайнар Булок
Кышлакта кунакта

96. Каллиграфия серләре
Казанда нинди күргәзмә ачылды

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: media.kpfu.ru

Акыллы гамәлләр

21.01

Сергей Иванов, Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе, – ведомство коллегиясендә:

– Без 10 ел элек республикабызга 5 миллион турист китертү турында хыялланган идек, бүген бу санга якынлашабыз. Республикабызның бай туристлык потенциалын исәпкә алып, бүген үз алдыбызга 2035 елга 10 миллион турист килергә тиеш дигән план куябыз. Әйе, соңгы елларда Татарстанның туризм буенча төрле рейтинглар башында торуына күнектек, әмма 5 миллион, 7 миллион яки 10 миллион саннарына ирешү өчен безгә әле бик күп эшләргә кирәк. Бүген үк туристлар агымы һәм кунакханәләрдә урнашкан кунаклар санының арту тизлеге акрыная башлады, бу – зур проблема.

Игелекле эшләр

20.01

Владимир Машков, Россиянең халык артисты, Мәскәүдәге Олег Табаков театры һәм «Современник» театры сәнгать җитәкчесе, – Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының яңа бинасы ачылышында:

– Шундый гаҗәеп иҗади урын булдыру – Татарстан өчен генә түгел, бөтен Россия өчен зур вакыйга. Килеп туктагач, бу матурлыкны күреп хәйран калдым һәм театрның идеясе белән идеологиясенең абсолют үтә күренмәлелек һәм дөньяга ачыклык булуын аңладым. Бу талантлар кристаллы кебек тоелды. Мондый урын яшьләр өчен дә, сәхнә осталары өчен дә гаҗәеп мөмкинлекләр ачачак. Мин бу уникаль урынга сокланып карыйм һәм монда, һичшиксез, бик күп илһам-дәрт, матурлык туачагына ышанам!

Мәңгелек кыйммәтләр

19.01

Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан мөфтие, – махсус хәрби операция зонасында, «Батыр» батальоны сугышчылары белән аралашканда:

– Тылда без Аллаһы Тәгаләгә сезнең исәнлек өчен дога кылабыз һәм сугышта яклавын, якыннарыгыз янына исән-сау кайтаруын, җиңүне тизләтүен сорыйбыз. Сезне Аллаһка ышанып тапшырабыз! Аллаһ кодрәте дошманнан сакласын, хәвеф-хәтәрләрдән коткарсын, сугышта ышанычлы көрәштәшләр бирсен, йортларыгызга һәм тылдагы якыннарыгызга иминлек бүләк итсен. ИншаАллаһ, явызлыкны җиңү сезнең кулда булыр!

Фото: ТР Диния назарәте матбугат хезмәте, tatar-inform.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Екатерина II татар авылын **ничек** Сембер губернасы шәһәренә әйләндергән

Ап-ак шикәрне **кайда** җитештерәләр

Иң шәп су коену урыны **кайда** пәйда булачак

Ничек 105 яшькә җитәргә һәм ирешкәннәрдә туктап калмаска

Патшабикә рөхсәт биргән мәчет **кайда** төзелгән



Фото: buinsk.tatarstan.ru. Иллюстрация: Оксана Кузнецова

ДӨНЬЯНЫҢ ИҢ ГҮЗӘЛ УРЫНЫ!

БУА. ПАТШАБИКӘНЕҢ ҖИҢЕЛ КУЛЫ БЕЛӘН...

Шәһәргә керү юлында голливудча бик зур ак хәрефләр, Шикәр паркы, «Мальдив» пляжы, гашыйкларның бакыр фигуралары... Йә, кайда без?

– Дөньяның иң гүзәл урынында! – дип елмая безгә очраган кешеләр. – Буа дигән шәп шәһәрдә! Һәм аңа озакламый – аз да түгел, күп тә түгел – 245 ел тула.

Әйе, әйе, нәкъ менә 245 ел элек, 1780 елның 15 сентябрендә, патшабикә Екатерина II Буа дигән кала төзү турындагы указга кул куя. Бераз вакыт узгач, Буага «яшел басудагы көмеш йонлы сарык» гербы бирелә. Әлеге дә баягы 1780 елның 22 декабрендә Сенат докладында распаганча, «монда әлеге төр хайваннар күп булганга күрә». Шулай итеп, патшабикәнең җиңел кулы белән Буа Сембер губернасындагы шәһәргә әверелә.

Билгеле инде, ерак Әби патша заманнарында «шәһәр» дип аталса да, ул хәзерге күзаллаудан шактый ерак була. Зур сала, дисәк, дөресрәктер. Баштарак исеме дә Архангельское дип йөртелә әле аның.

Бүген Буа шәһәрендә 20,5 меңгә якын кеше яши, ә район авылларында – ике мәртәбә күбрәк. Монда татарлар да, руслар да, чувашлар да, башка халык вәкилләре дә бар.

Ә ничек яшиләр, дисезме? Хәзер беләбез.

АП-АК БИЗНЕС

Шикәр шикәр инде ул. Бусы да Тамбовта яисә Кубада җитештерелгән шикәрдән әллә ни аерылмыйдыр инде, дип уйлыйбыз без, Буа шәһәренең төп предприятиесе ишек төбенә җиткәч. Һәм, туктале дип, әлеге чәнечкеле сорауны шикәр заводы инженеры Наталья Шитовага юллыйбыз:

– Менә сез Буаныкын, үз шикәрегезне, башкаларныкыннан аера алсызмы?

– Әлбәттә! – дип, икеләнергә урын калдырмый Наталья. – Безнеке ап-ак, иң агы, миңа калса...

Иң ак шикәрнең (республикада, илдә, дөньяда?) ничек ясалуын аңлар өчен, барысын да үз күзебез белән күрергә уйлыйбыз. Әйтергә кирәк, бик тәэсирле күренеш. Безнең күз алдында аяусыз автомат транспортер буенча килгән шикәр чөгендерен «мунча кертә», ягъни юа, чистарта, чайкый һәм парлый. Монда мунча да, фин саунасы да, хәтта Түбән Кама термалары да бер якта торсын. Әле бу эшнең башы гына – алга таба барысы да диярлек кеше күзенә яшерен ябык торбаларда, колонналарда башкарыла. Чип-чиста чималны ваклап торганда, пешереп, сиропка әйләндергәндә, цехта һәрвакытта да диярлек тропиклардагы кебек эсселек тора – ай-һай рәхәт түгел, ахры, «шикәр тормышы»...

Монда эшләүчеләргә дә авырдыр инде, диешәбез. Без әле шул вакыт эчендә генә дә манма тиргә батарга өлгердек.

– Юк, – дип җавап бирә Наталья, тагын безне гаҗәпкә калдырып. – Җитештерү процессы тулысынча автоматлаштырылган, шуңа күрә сез монда кешеләрне күрмәссез, алар бары

Фото: Айдар Мөшәрәпов

тик оператор бүлмәләрендә, лабораторияләрдә генә утыра, анда да кондиционерлар эшләп тора.

Һәрбер оператор бүлмәсе – корабльдәге штурман урыны кебек. Бөтен эш барышы уч төбендәгедәй күренеп торган мониторлар «курсны югалтмаска» ярдәм итә. Наталья Ковалева – шундый штурманнарның берсе. Үз «корабы», дөресрәге, процесс белән ул инде унбиш ел идарә итә, шуңа күрә биредә соңгы дистә ел эчендә барган барлык цифрлы трансформацияләрне ул үз күзе белән күргән кеше.

Үзгәрешләр җитди: бүген буалылар ун ел элек белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк чөгендер эшкәртергә сәләтле. Бер сезонга монда 100 мең тоннадан артык шикәр җитештерелә. Сүз уңаеннан, Татарстанның шикәргә булган еллык ихтыяҗы – 150 мең тонна. Җитештерү ни дәрәҗәдә нәтиҗәле соң? Бер деталь. Берничә ел элек шикәр чыгышы буенча (17,81 процент) рекорд куеп, Буа шикәр заводы тармактагы 75 Россия предприятиесе арасында иң яхшысы дип табылган.

Ә калдыкларны нишләтәләр?

– Алар юк, – дип аңлата Наталья Шитова. – Чөгендер калдыгы, ягъни түп шунда ук грануланган терлек азыгына әйләнә. Азык патокасын (бәрәңге балын) шулай ук сатабыз, аны, мәсәлән, чүпрә ясауда кулланалар. Суны да сак тотабыз – чөгендерне югач, ул беркая да агызылмый, чистартыла һәм, технологик чылбырга кайтарылып, яңадан кулланыла.

Завод ел саен берничә миллиард сумлык продукция чыгара, салымнарны вакытында түли һәм җитештерүне модернизацияләүгә даими рәвештә шактый зур акчалар тота, чөнки базар тик торырга ирек бирми. Планда, дип сөйләделәр безгә, технологияләрне алга таба да камилләштерү.

– Бездә шикәр заводлары сезон дәвамында гына эшли, шикәр чөгендерен озак саклап булмый, югыйсә ул үзенең баллылык сыйфатларын бик тиз югалта, – дип аңлатты белгечләр. – Франциядә, мәсәлән, шикәр дә ясыйлар, «артык» чөгендердән саклаганда үз үзлекләрен җуймый торган сироп та җитештерәләр. Димәк, теләсә кайсы вакытта кулланып була торган чимал килеп чыга. Без ни өчен шундый технологияне кертә алмыйбыз, ди?

Монысы инде – киләчәккә планнар арасында. Ә бүген – менә ул, кулланышка әзер, беренче кардай ап-ак Буа шикәре конвейер буенча «йөгерә». Бәлки, чыннан да ул башкаларга караганда аграктыр?

БАЗАР ЗИЛЗИЛӘСЕННӘН ДӘВА

Заводның эшләп торуы бик әйбәт, әмма җитәрлек күләмдә сыйфатлы чимал булмаса, рекордлар турында хыялланырга гына калыр иде. Бу турыда сезгә, мөгаен, шикәр чөгендере үстерүче теләсә кайсы фермер әйтер һәм үзенчә хаклы да булыр. Чималны Каф тавы артыннан эзләмәгәнгә күрә, Буа предприятиесенең эше уңышлы бара да. Тәэминатчыларның зур өлеше – завод кергән холдинг составындагы район хуҗалыклары. Ерак ташыйсы түгел, чәчкәннән алып казып алганчыга кадәрге бөтен процесс катгый контроль астында уза, шуңа күрә оптималь срокларда иң яхшы сыйфатларга ия чимал алу мөмкинлеге дә күп тапкырларга арта.

Димәк, үстерелгән чималны сату гына түгел, аны эшкәртү, өстәвенә тирәнтен эшкәртү – күп кенә аграрийларның хыялы биредә күптәннән инде фантазия түгел, ә чынбарлык. Өстәлгән бәя, өстәмә керем һәм базар ыгы-зыгыларыннан саклау кебек гарантияләнгән дивидентлар да шуннан килә. Чөгендер үстерүчеләр һәм аны эшкәртүчеләр арасында урнашкан аерым мөнәсәбәтләр чималны юк бәядән генә сатып җибәрүгә юл калдырмый.

Шунысы да бар: авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүгә басым ясау районның үзенчәлекле визит карточкасы булып тора. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда һәм эре фермаларда савып алынган сөтне дә еракка ташыйсы юк

– Буада үзләренең сөт заводы эшләп тора. Бодайны сатып алганнарын көтеп амбарларда саклыйсы юк – монда югары сыйфатлы спирт җитештерә торган завод та бар. Сүз уңаеннан, билгеле бер аракы брендының яртысын Буа спиртыннан ясыйлар.

ТӘМЛЕ СЫЙЛАР

Буада безгә җирле ит комбинаты – «Карлинский» Ит йортына барырга да тәкъдим иттеләр. Биредә җитештерелә торган колбаса һәм башка ит ризыкларының төрләрен язып, вакытыгызны алмыйк – монда җаның ни тели, шул бар. Предприятиенең төп «фишка»сы атамаларының төрлелегендә дә түгел. Шикле сыйфатка ия ризыкны да тәмле итәргә сәләтле өстәмәләр турында әйтеп тә торасы юк. Монда башка, мөһимрәк сыйфатлар алга чыга.

– Безгә мондый өстәмәләр кирәкми, чөнки эшкәртә торган чимал үзебезнеке. Сыйфатлы, яңа җыеп алынган, – дип аңлата предприятие директоры Зөлфәт Йосыпов. – Барлык технологик чылбыр – терлекләрне чалу, эшкәртү, итне бүлү – барысын да биредә оештырдык, шуңа күрә җитештерүгә бары тик яңа чалган терлек ите генә бара. Итнең сыйфаты турында мөгезле эре терлек һәм дуңгызларны симертү процессында ук кайгыртабыз – без «Авангард» хуҗалыгының филиалы булып торабыз. Комбинат тулы куәтенә эшли: биредә хуҗалыкта җитештерелгән итнең өчтән икесе эшкәртелә. Әле кайчан гына болай түгел иде. Бүген ике тапкырга күбрәк ит эшкәртелә, чөнки эшне ике смена итеп оештырдык. Итне күмәртәләп сатып җибәрүгә караганда үзеңдә эшкәртү файдалырак, продукциягә ихтыяҗның артуы да шуңа этәрә. Безнең колбаса, ветчина, бекон, шашлык кебек ризыкларыбыз Татарстанда гына түгел, Удмуртиядә дә, Ульяновск өлкәсендә дә яхшы сатыла.

Инде быел гына да «Карлинский»да бер миллиард 275 миллион сумлык продукция җитештерелгән һәм сатылган. Ризыкларның күрше төбәкләргә озатылуы белән бергә, предприятиенең керемнәре артуы да технологик чылбырның дөрес оештырылуы хакында сөйли. Яшьләр дә бирегә эшләргә бик теләп килә. Хезмәт хакы да кызыктырырлык – уртача 56 мең сум. Аена 150 мең сум акча эшли торган белгечләр дә бар.

Чистартылмаган ашлык.

ПУШКИН ӘКИЯТЕННӘН АЛЫНГАН РЕЦЕПТ

Без кунак булган тагын бер урын – «Полба-М» Буа заводы. Предприятиенең директоры да, хуҗасы да Марат Фәсхиев үз продукциясе турында бик кызыклы итеп сөйли.

– Пушкин әкиятендә поп үз хезмәтчесе Балданы нәрсә белән сыйлавын хәтерлисезме? – дип сорады ул, елмаеп. – Борай белән! Югыйсә Балда авыр хезмәттән күптән кәкрәйгән булыр иде. Борайда аксым йомыркадагыдан күбрәк! Иртән борай боткасы ашасаң, кичкә кадәр тук буласың!

Бүген сәламәт туклану тарафдары булган теләсә кайсы кешегә таныш культура безнең эшкәртүчеләр өчен беренче урында түгел, аны чистарту да проблема, җиһазлары

да кыйммәтле. Ләкин Марат Әхкәмович, базарда пәйда булган бушлыкны күреп, үз вакытында тәвәккәлләргә карар кыла һәм ялгышмый. Берничә ел тик торган цехны эшләтеп җибәрә, җиһазлар сатып алуга шактый акча сала. Буа бораен кулдан суырып диярлек алалар – үзебезгә караганда, Европада, бигрәк тә Германиядә популяр икән.

Бүген аек акыллы немецлар һәм аларның күршеләре терсәкләрен тешли: Буа борае билгеле сәбәпләр аркасында аларга барып җитә алмый. Сату базарының күпмедер өлешен югалткан Фәсхиев төшенкелеккә бирелми: үзебезнекеләргә күбрәк кала, ди. Шунысы да яхшы: ул инде күптәннән борайны чистарту белән генә чикләнми. Предприятиедә эшкәртүнең тирәнлеге – күпләрне көнләштерерлек. Борай, ярдырылган борай, борай токмачы һәм борайдан макарон ризыклары – әлеге продуктлар барысы да конвейердан сатуга әзерләнеп – биш йөз грамм авырлыкта, пакетка салынган килеш төшә.

Сүз уңаеннан, чит ил сатып алучылары Татарстан бораен сатып алу юлларын эзләүне туктатмый, диләр. Мәсәлән, безгә дус илләрнең берсе аша. Фәсхиев моңа аңлатма бирмәде, яшик әле, күз күрер, дип кенә җавап кайтарды.

Предприятиенең директоры да, хуҗасы да Марат Фәсхиев үз продукциясе турында бик кызыклы итеп сөйли.

Борайдан ясалган продуктлар барысы да конвейердан сатуга әзерләнеп – биш йөз грамм авырлыкта, пакетка салынган килеш төшә.

Иң ахырдан.



Буа: төзелеш

«МАЛЬДИВ»ТА ОЧРАШЫРБЫЗ!

– Әйдә бүген «Мальдив»ка барып кайтабыз?

– Әйдә! Ун минуттан пляжда очрашырбыз!

Быел җәй шәһәрдә шундыйрак сөйләшүләр күп булыр, мөгаен. «Буа кайда да, Мальдив утраулары кайда, – дип каршы төшәр географияне яхшы белүчеләр. – Безнең монда беркайчан да пляж булганы юк...»

Дөрес, беркайчан да булмаган. Бу якларлардагы Карлы елгасында җәй көне су чыпчык коенырлык кына була. Әмма Буа халкы үҗәт бит ул. Әллә кая барып йөрмәс өчен, ял итү, су коену урынын үзебездә булдырырга кирәк, дигән карарга киләләр. Һәм ул бик шәп булырга тиеш. Суы диңгезнекеннән чистарак, комы океан утравындагыдай булсын. Тормышка ашмаслык хыялмы бу? Һич юк!

- Менә ул безнең «Мальдив», - ди Буа районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Рифат Хәмидуллин, Казандагы Аккош күледәй сулыкны күрсәтеп. – Күл ничек пәйда булдымы? Казыдык без аны. Су кайданмы? Артезиан скважиналары бораулыдык...

Сулыкны гидротехника фәненең барлык кагыйдәләре буенча төзегәннәр. Гигант чокыр казып, йөзләрчә машина туфрагын чыгаргач, булачак күлнең төбенә махсус япма түшәгәннәр. Ярларына тонналап чиста ком ташыганнар. Безнең Мальдив утрауларында булган юк, әмма биредәге пляжның күпләрне көнләштерерлек булачагы инде хәзер үк күренеп тора.

Хәер, нигә булачагы? Ком өстендә шезлонглар, кием алыштыру урыннары, коткаручылар каланчалары - барысы да инде әзер, кызынырга, коенырга яратучыларга җәйне көтәргә генә кала. Июньдә исә, сусаклагычка артезиан суын тутыргач, биредә марафон йөзешләре дә үткәрү мөмкин булачак. Инде хәзер үк кайберәүләр, әледән-әле килеп, суның күпмегә күтәрелгәнен чамалап китә...

- Ә җыелган суның агып китәр юлы бармы соң? – дип кызыксынабыз Рифат Хәмидуллиннан.

- Әлбәттә, – ди үз эшен яхшы белүче җитәкче. – Без күлне агымсулы итеп ясадык.

БАКЫЙ УРМАНЧЕ МУЗЕЕ

Мальдив утрауларындагыдай пляж белән күл Буаның яңа җәмәгать мәйданы саналса, Бакый Урманче музее мәдәни мәйдан булачак. Ачылачак музейда татар сынлы сәнгатенә нигез салган бөек шәхесебезнең әсәрләре, шәхси әйберләре һәм башка раритетлар тупланыр, дип ниятләнә. Нигә Буада, дисезме? Атаклы рәссам һәм скульптор Буа районындагы Күл Черкене авылында туган, анда бүген кечкенә генә музей эшли. Ә менә тәүге татар рәссамының колачына тәңгәл килерлек, аның картиналары һәм сыннарыннан даими экспозиция оештырырлык галерея туган ягында моңарчы булмаган.

Гаделсезлекме? Әлбәттә. Шунлыктан Буа халкы Урманче ватанында шундый музей оештыру идеясен күтәреп чыккан

Фото: Александр Ефремов

да инде. Аны Татарстан Рәисе хуплаган. Җирле бюджет акчасына бинаның проекты әзерләнгән, төзелешкә исә акчаны республика биргән. Бу бина чын-чынлап шәһәрнең бизәгенә әйләнер, дип өметләнәләр.

Өч катлы бинаның фасады Буаның тарихи йортлары өслүбендә, түбәсе пыяла, күргәзмә заллары белән музей экспозициясе 1900 квадрат метр мәйданны биләячәк... – бөек останың сәнгать җәүһәрләре тупланган зиннәтле бина шундый булачак. Хәзер биредә буяу-бизәү эшләре бара, аннары экспозиция эшләнәчәк, әсәрләрне саклау өчен идеаль шартлар тудырылачак. Бакый Урманченың яңа музее быел август аенда ачылыр, дип көтелә.

ЮЛЛАР, ЮЛЛАР...

Сәнгать югарылыгыннан җиргә төшик әле – шәһәр һәм авыл юлларына күз салыйк. Буада һәм аның әйләнә-тирәсендә яңгыр яуган саен баткакка әйләнә торган, таш түшәлмәгән юллар күптән юк инде. Биредә юллар яхшы, чөнки аларны салу һәм төзекләндерү даими һәм эзлекле рәвештә алып барыла. Мәсәлән, былтыр җирле һәм төбәк әһәмиятендәге юлларда 290 миллион сумлык эш башкарылган. Буаның үзендә генә дә Исхакый, Степная һәм тагын дүрт урамда юл өслеге яңартылган.

- Юлларның яхшы булуы – уңай күренеш, әмма алар районның бөтен җирендә дә бик шәп булырга тиеш, – дип уйлыйлар биредә. – Авыл җирлекләрендә 100 чакрымга якын юл асфальт-бетоннан, әмма әле таш түшәлгәннәре дә, бөтенләй түшәлмәгәннәре дә шактый. Бурыч – юл челтәрен даими камилләштерү. Быел, мәсәлән, бу максатка төрле программалар буенча 730 миллион сумга якын акча бүленде, шуның 412 миллионнан артыгы – җирле юлларга.

Гражданнар үзләре дә актив. Алар, тупланган акчага үз торак пунктларында юллар, тротуарлар төзү яки яңарту өчен, авыл җыеннарында үзсалым акчалары җыю турында карар кабул итәләр: җыелганның һәр сумына бюджеттан дүрт сум өстәлү бик шәп стимул бит. Былтыр Буа авылларында үзсалым акчасына өч километрга якын юл төзелгән һәм ремонтланган.

БУА-СИТИ? БУЛМАС, ДИМӘ!

Көрәш, тренажёрлар, бокс заллары, баскетбол һәм волейбол мәйданчыклары, шахмат клубы урнашкан «Импульс» универсаль спорт залы. «Максат» футбол манежы. Балалар сәнгать мәктәбе. «Мирас» яшьләр үзәге. Хореография залы, вокал, тавыш яздыру, сәнгать студияләре, универсаль зал, коворкинг һәм уку залы булган күпфункцияле мәдәният үзәге...

Болар Буада соңгы биш елда төзелгән һәм яңартылган заманча объектларның кайберләре генә әле. Хәер, биредә инде ирешелгәннәргә әллә ни игътибар бирергә яратмыйлар. Ә менә киләчәктәге гаять зур проектлар турында мавыктыргыч итеп сөйли беләләр.

– Менә карагыз, бу безнең балалар өчен яңа сәламәтләндерү-савыктыру лагере, – дип схеманы күрсәтә Рифат Хәмидуллин. – Бөтен уңайлыклары булган йокы корпуслары, спорт мәйданчыклары, кинозал... Һәм болар барысы да искиткеч саф һавалы нарат урманында урнашачак. Бернинди такта йортлар да юк – алары бит инде узган гасыр, балалар өчен бөтен шартлар тудырылачак. Яңа лагерьда барысы да үтә заманча булачак.

Һәм лагерь гына да түгел. Төзеләчәк мәктәп бинасы проекты да заман таләпләренә җавап бирә. Архитектурасы ягыннан бик кызыклы, керамогранит фасад, витражлар, биек түшәмле һәм «горизонтның уңай ягына караган» (аңлатма язуында шулай диелгән – *ред. иск.*) тәрәзәле иркен кабинетлар, мини-футбол кыры, резин япмалы уен мәйданчыклары һәм пандуслар...

Тагын әле Буа шәһәрендә өр-яңа торак район пәйда булачак. Җирле ипподром территориясендә ун гектар җирдә мәйданы 63 мең квадрат метрга якын заманча торак – биш-тугыз катлы, бераз тәбәнәгрәк йортлар, социаль һәм мәдәни-көнкүреш объектлары, җәмәгать мәйданнары төзеләчәк... Күпчелеген хосусый йортлар тәшкил иткән шәһәр өчен бу чын Буа-сити булачак.

Киләчәктә шәһәр бизәгенә әйләнәчәк микрорайон урынында бүген ялан кыр әле. Әмма инде Буа халкы якын киләчәктә яңа йортларда өй туйлары гөрләячәгенә шикләнми.

Артык кыю хыялларммы? Ләкин исегезгә төшерәбез: бу бит Буа. Биредә сүзен эше белән раслаучы уңган, булдыклы халык яши.

Буа: мәдәният

БУАЧА ЯҢАРЫШ

Күз алдына китереп карыйк әле: балалар сәнгать мәктәбендә укучылар еллар буена бер катлы җимерек бинада, кысан шартларда кайнаша, ә аннары, көннәрдән бер көнне, кинәт, аларга өч катлы яңа бина бүләк итәләр. Караңгы салкын подвал төзекләндерелә, анда хәзер уңайлы гардероб, яңа спортзал, хәтта мәктәп музее да урнаша. Театр артистлары кечкенә бүлмәләрдән соң иркен, үз душы булган гримёркаларга тиенә, ә авыл клубы залында элеккеге каты, җайсыз утыргычларга алмашка уңайлылары пәйда була. Һәм яңа тавыш аппаратурасы кайта.

2 нче лицейның яшь кулинарлары.

Үзләре эшләгән, белем алган, буш вакытын уздырган, яшәгән мохиттә шартлар шулай уңай якка үзгәргәнгә, кешеләрнең ничек шатланганын күз алдына китереп була, билгеле. Буа районы мәгариф һәм мәдәният өлкәләренә теге яки бу дәрәҗәдә катнашы булган һәркем өчен узган ел куанычларга бай булган – биредә инфраструктура тулаем яңарыш кичергән. «Татарстан» хәбәрчеләре, әлеге урыннарда булып, барысын да үз күзләре белән күреп кайтты.

СЫРНИКЛАРДАН – ЧАТ-БОТЛАРГА КАДӘР

Буаның 2 нче лицеена төшке аш алдыннан килеп төштек. Безне шунда ук сырниклар һәм кайнатма белән чәй эчәргә чакырдылар. Бу әллә ни гаҗәп тоелмас та иде, әгәр чәй мәҗлесебез узган урын үзе үк гаҗәеп булмаса! Яңа технология кабинеты кулинария патшалыгына тиң, дисәк тә, ялгышмабыз. Монда бар да заманча – индукцияле плитә, тәм-томнар пешерү өчен духовка... Бишенче сыйныфта укучы кызлар безгә кабинет буйлап экскурсия уздырды – алар барысы да формадан, ягъни ак блузка белән шакмаклы итәктән, алъяпкычтан, башларында – косынка. Экскурсия белән беррәттән, алар кунакларга сырник әзерләү серләрен дә чиштеләр, чәйгә кушып пешерелгән файдалы үләннәр турында да сөйләделәр.

– Мондый кулинария бүлмәсе районда башка бер җирдә дә юк, – дип, зур горурлык белән сөйләде лицей директоры Людмила Абрамова.

Районда гына түгел, мондыйлар һәр затлы фатирда да булмаска мөмкин... Без укыгандагы хезмәт дәресләрен искә төшереп уфтаныргa, Буа балалары өчен куанырга гына кала. Тәмле итеп пешерә белүче хуҗабикәләр үсеп чыксын үзләреннән!

Яңартылган технология кабинетлары – 2024 елда капиталь ремонттан соң үзгәреш кичергән урыннарның берсе генә. Кабинетлар тезе-

Фото: Александр Ефремов

Биология кабинетында хәзер цифрлы микроскоплар тора.

леп киткән уку-укыту блогында озаккарак тукталсаң (ә без шулай иттек тә), әле тагын малайларның технология дәресләрендә урындыклар юнып-ясап утырмавын, ә прототиплаштыру белән шөгыльләнеп, 3-D принтерлар белән эш итүенә шаһит буласың. Могҗизалы техника ярдәмендә ясалган пластик шахматлар сыйныф каршындагы стеллажга тезеп куелган, ә директор бүлмәсенең түрендә – шул ук укучылар кулы һәм 3-D технологиясе ярдәмендә җыелган «Колшәриф» мәчете моделе.

2 нче лицей укучылар саны ягыннан Буаның иң зур мәктәбе санала. Элегрәк физкультура белән шөгыльләнер өчен, укучыларның бер өлеше күршедәге спорт комплексына йөргән – лицей анда зал арендалап торган. Хәзер инде үзләрендә шөгыльләнәләр: иске спорт залын ремонтлаганнар, аңа өстәп, тагын берсен тулысынча төзекләндерелгән подвал мәйданында башлангыч сыйныфлар өчен ачканнар.

Зал белән янәшәдә – бильярд өстәле. Югары сыйныфлар, дәресләрдән соң, шушында мәш килә, диделәр. Чынлап та, җылы, якты, нурлы урын, аны хәтта подвал дип атавы да кыен.

Мәктәп коридорлары да үзгәргән. Биредә хәзер бөтен җирдә төрле төстәге диваннар тора – тәнәфес вакытында барлык укучылар да чабып йөрмәскә мөмкин бит, кемдер, әйтик, китап белән мавыгып, диванда утыра, дәресен кабатлый. Тәрәзәләрдә – жалюзи. Диварларда – илһамландыра торган цитаталар. Кечкенә сыйныфлар өчен уен зоналары каралган.

«Мәгариф» федераль проекты кысаларында кабинетларның җиһазлары да яңартылган. Мисал өчен, биология дәресендә укучылар цифрлы микроскоп белән эшлиләр, аңардан сурәт смарт-тактага проекцияләнә. Башлангыч сыйныфларда лего-конструкцияләрнең нигезләрен өйрәнәләр, робототехника дәресләре белән программалаштыруны үзләштерергә әзерләнәләр. Сүз уңаеннан, программалаштыру белән шөгыльләнә торган югары сыйныфлар «Телеграм»да һәртөрле тематик чатботлар ясарга өйрәнә. Бу хәзер яшүсмерләр арасында гаять популяр: кызык та, әле тагын киләчәк тормыш өчен перспективалы күнекмәләр алырга да ярдәм итә.

Лицейга бу елны педагогика вузын яңа гына тәмамлаган дүрт яшь укытучы килгән. «Яңа эшли башлаган яшь педагогларга, – дип сөйләде безгә Буа районы мәгариф идарәсе башлыгы Наталья Македонская, – бер тапкыр 50 мең сум акча түләнә». Быел әле аларга яңа йортта социаль найм буенча фатирлар да бирелгән. Районда яшьләр кайтып эшләсен, яшәргә калсын өчен шартлар тудырыла, бу күренеп тора.

Яңа, яшь белгечләр, дигәннән. Лицей буйлап сәяхәтебезнең башыннан ахырына кадәр безне «яшь папараццилар» озатып йөрде. Алтынчы сыйныф укучылары Ралина белән Люба инде икенче ел рәттән «телевидение» өчен җаваплы икән: телефонга лицей тормышын төшереп баралар, соңыннан репортажларын мәктәп мессенджерлары, социаль челтәрләрдәге чатларга юллыйлар. Башкаладан килгән журналистлар турында да сөйләми кала алмыйлар иде, әлбәттә. Сәяхәт тәмамлангач, кызлар энәсеннән-җебенә кадәр төпченеп, интервью алды: ошадымы сезгә безнең лицейда, янәсе. Әлбәттә, коллегалар, башкача була да алмый!

ӨЧ КАТТАГЫ МАТУРЛЫК

Кара спорт формасы кигән, үреп салган чәч толымнарына ак бант таккан кызлар педагог күрсәткән катлаулы хәрәкәтләрне кабатлый, четерекле бию позицияләренә баса, станокта шөгыльләнә... Хореография классының зур көзгеләре, аларны чагылдырып, залны балалар белән шыгрым тулы итеп күрсәтә...

Буаның яңа Балалар сәнгать мәктәбе бинасында хореография заллары икәү. Димәк, классик бию төркемнәре дә, халык биюе төркемнәре дә бер үк вакытта шөгыльләнә ала. Чишенү бүлмәләрендә душ та бар, ә тәрәзәдән Буага гаҗәеп манзара ачыла.

– Узган елга кадәр барыбыз да диварлары яргалана башлаган, үзе җимерек хәлгә килеп барган бинада укыдык-укыттык, – дип искә ала Балалар сәнгать мәктәбе директоры Альбина Кәримова. – Ә бездә бит әле тагын уен коралларында уйный торган музыкантлар да, вока-

Хореография классындагы дәресләргә балалар бик җитди карый.

Чигү дәресендә.

листлар да, кул эшләре белән шөгыльләнүчеләр, ягъни декоратив-гамәли сәнгать бүлеге дә бар... Өч йөзгә якын бала!

Яңа өч катлы бинага мәктәп узган елда аяк басып керә. Программаны киңәйтү-тирәнәйтү яңа перспективалар, мөмкинлекләр дә ачыла. Мәсәлән, элек музыка бүлегендә балаларга баян белән фортепиано гына тәкъдим итә алсалар, хәзер инде күбрәк уен кораллары булачак, диләр. Декоратив-гамәли бүлектә исә балчыктан чүлмәк ясау сәнгате өйрәтелә башлаячак – инде чүлмәк ясый торган бөҗралар сатып алынган, яндырыр өчен мичләр дә әзер икән. Сәйлән белән чигүгә дә аерым кабинет бирелгән – анда заманча тегү машиналары тезелеп тора.

Рәсем сәнгате белән мавыгучы балаларны өченче катта урнаштырганнар – тәрәзәдән ачылган манзара аларга перспективаның нәрсә икәнен тоемларга ярдәм итсен, дип, әлбәттә. Рәсем сәнгате өчен бит әле яктылыкның ничек төшүе дә гаять мөһим.

Яшь вокалистлар без килгәндә Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышлап әзерләнә торган программаны кабатлый иде. Яңа актлар залында узарга тиешле бу чарада сугыш чоры җырлары башкарылачак. Бик күп кунаклар килүен көтәләр һәм җитди әзерләнәләр.

ТӘГӘРМӘЧЛЕ ТЕАТР ӨЧЕН – ЯҢА ЙОРТ

Буаның яңа заман тарихында театр ничек барлыкка килгән соң? «2002 елда, – дип искә ала Буа районы мәдәният идарәсе башлыгы Ринат Гыймранов, – Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтының актёрлык бүлеген тәмамлап кайттым, шуннан башланды инде...» Биредә ул бер мәдәният оешмасын җитәкләгән. Нәкъ менә шул елларда иҗатта кайнашкан дуслары белән бергә халык театры төзергә дигән карарга килгәннәр.

– Арабызда түрәләр дә, укытучылар да, китапханәчеләр дә бар иде... – дип искә ала Ринат Җәүдәт улы. – Кичләрен мәдәният йортының иске бинасында очрашабыз, пьесалар укыйбыз, сайлап алып, иртәнге дүрткә кадәр репетиция ясыйбыз... Үзебез декорацияләрен әмәллибез, үзебез музыкасын язабыз, грим салабыз, костюмнар тегәбез... Районның мәдәният бүлеге биргән иске генә автобуста бөтен Россия буйлап гастрольгә чыгып китәбез. Бер ай эчендә 28 әр спектакль уйный идек, ә бит бу әле – төп эшебездән калган буш вакытыбызда!

Энтузиазмны бәяләми калмыйлар – 2007 елда Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев халык театрына махсус указ белән дәүләт театры статусы бирә.

Коллективка ул вакытта элеккеге кинотеатр бинасын «бүләк итәләр». Ә узган елның декабрендә алар чын-чынлап тантана итә – театр карамагына артистлар ихтыяҗын күздә тотып тулысынча яңартылган, төзекләндерелгән район мәдәният йорты бинасын тапшыралар.

– Мондый матур театрда эшләп караганыбыз юк иде әле! – дип, шатлыгы белән уртаклаша Татарстанның атказанган артисткасы Гөлзада Камәртдинова. Ул безне театр буйлап йөртә, барысын да тәфсилләп сөйли-күрсәтә-аңлата.

Чынлап та, бер стильдә затлы итеп бизәлгән театр пространствосы күзне иркәли. Кергән җирдә үк – авыл тәрәзәләрен хәтерләтеп эшләнгән агач рамнар, бу күркәм образ гына түгел, фотолокация дә. Замана тамашачысы андыйны ярата, шәп уйлаганнар. Фойе һәм кече зал-трансформерның бәрхет диварларында чәчәк таҗын хәтерләткән татар милли бизәкләре... Фойедагы коридорларның берсендә – кубоклар торган стенд. Бу – театрның күпсанлы фестивальләрдән алып кайткан бүләкләре: Россия буйлап кына да түгел, хәтта чит илләрдән – Казахстаннан, Сербиядән, Төркиядән.

Ни кызганыч, без килгән көнне театр буш иде – артистлар чираттагы гастрольгә китеп барган булып чыкты. «Без бит – тәгәрмәчле театр, авылларга, башка шәһәрләргә, хәтта төбәкләргә дә даими йөреп торабыз», – ди Гөлзада Камәртдинова.

Әмма туган шәһәрләре Буада да аларны гел көтеп алалар. 400 кешелек яңа залга билетларны инде, безгә әйтүләре буенча, сатып алып бетергәннәр.

Узган елны Буа театры тулысынча яңартып төзелгән мәдәният йорты бинасына күченә.

Сергей атакай инде 20 ел буена Алших авылындагы изге Маргарита гыйбадәтханәсендә хезмәт куя.

СОЦИАЛЬ, ӘММА РУХИ ЭЧТӘЛЕКЛЕ

Районның яңартылган мәдәният учаклары буйлап сәяхәтебез Алших авылында дәвам итә. Мондагы мәдәният йортына эләккәнче, җирле гыйбадәтханәгә кереп чыгарга ниятлибез. Кечкенә генә агач чиркәү безне, беренче чиратта, үзенең «исеме» белән кызыксындыра. Россия чынбарлыгында бу сирәк очрый – ул Азап Күрүче Маргаритага багышланган.

Чиркәүне 2000 нче елларда чыгышы белән моннан булган бер эшкуар үз акчасына төзеткән, ди. Ә Маргарита, христиан канУннары буенча, аның кызының изгесе икән.

Храмга быел 25 ел тула. Шуның 20 елы буена монда баш рухани булып Сергей Раевский тора. Келәүләрнең кайсыберләре чуваш телендә алып барыла, дип сөйләде ул безгә. Бу аңлашыла да, чөнки авылның 60% тан артык кешесе әлеге милләт вәкиле санала.

– Ял көннәрендә һәм бәйрәмнәрдә, – ди Сергей атакай, – тирә-юньдәге авыллардан да киләләр, келәү вакытында хәтта кысанрак та булып китә.

Авыл балалары өчен Сергей атакай белән аның хатыны якшәмбе мәктәбе оештырган – дәресләр өйләрендә уза икән. Өйләре шунда янәшәдә генә – ишегалды аша, балаларга рухани белем бирер өчен бер бүлмәне махсус хәстәрләгәннәр. Парталар да бар, такта да, бар да – чын мәктәптәгечә.

Монда социаль ярдәм белән дә шөгыльләнәләр, мохтаҗларга булышалар, оекбашлар белән перчаткалар бәйлиләр, махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен дарулар сатып алалар, балалары һәлак булган ата-аналарны ташламыйлар. Ә авыл зиратында яңарак кына кәшәнә торгызганнар: хәзер анда килеп дога укырга була, бакыйлыкка күчкән туганнары өчен шәм дә куя алалар.

АЛШИХ – ОЧРАШУЛАР ҮЗӘГЕ

Алших мәдәният йорты безне уйнап торган гармуннары һәм җырлары белән каршы алды. Концерт залына уздык – «Калина» җирле чуваш фольклор ансамбле репетиция ясый. Күршедә генә, иркен якты бүлмәдә, яшүсмерләр гөр килеп өстәл теннисы уйный.

– Малайлар хәзер көн дә килә, – дип елмая мәдәният йорты директоры Татьяна Киргизова. – Өлкәннәр дә, җай тапса, рәхәтләнеп кереп чыга, алар күбрәк бильярд уйный. Узган елны бездә капиталь ремонт булды, хәзер мәдәният йортына киләсе килеп тора.

Алшихта 700 гә якын кеше яши. Мәдәният йортына, дип сөйли безгә Татьяна Киргизова, олылар да, балалар да рәхәтләнеп йөри. Фольклор коллективлардан кала, биредә театр, хореография түгәрәге эшли икән, «Оста куллар» дигән мәктәп укучыларына юнәлтелгәне дә бар. Капиталь ремонт вакытында китапханәне тулаем яңартканнар, туган якны өйрәнү музееен да. Яңа концерт залында исә хәзер яңа мультимедиа җиһазлары бар, теләсә кайсы дәрәҗәдәге артистларны кабул итәргә дә оят түгел, дип елмая директор. Февраль аенда авыл халкын Чуваш филармониясе артистлары концерты көтә. Үзләренең иҗат коллективлары да яңа программа әзерли, биредә сәнгатькә тартылу тагын да көчле хәзер.

– Без клубта салкын, уңайсыз чакта да гел җыела идек, җыр-биюләребезне кабатлап, концертлар оештырып яттык, – дип елмая «Калина» ансамбленең җырчы «кызлары» – авылның пенсионерлары. – Хәзер инде җылы да, якты да, заманча җиһазлар да бар, ни күңелең белән түзеп өйдә утырырга кирәк, киләбез дә җитәбез!

Шулай, яшәү рәвеше, кайсыдыр заманның философы әйткәнчә, аңга да тәэсир итә, ә бәлки, аны билгелидер дә әле. Яхшы шартлар тудыру бик әһәмиятле, димәк, кешеләрнең кәефе дә яхшы, эшләргә йөрәкләре дә дәртләнеп тора, дигән сүз. Матурлык белән ешрак очрашырга да омтылыш көчле – аның барлык чагылышларында да.

«Калина» чуваш ансамбле репетиция вакытында.

Буа: волонтёрлык

Буалылар гуманитар ярдәм алып килгән.

ФРОНТКА ЯРДӘМ

Фронтка ярдәм буалыларның көндәлек яшәү рәвешенә әйләнгән. Алар җиңүне якынайту өчен көчләреннән килгәннең барысын да эшли, чөнки ул җиңү – барыбыз өчен дә бер. Алгы сызыктагы сугышчыларга мораль ярдәм дә, игътибар күрсәтү, кайгырту да – бик кирәк.

ГУМАНИТАР ЯРДӘМ ҖЫЮ ШТАБЫ

Махсус хәрби операция башланганнан бирле Буа районыннан фронтка 136 ир-ат мобилизацияләнгән, 274 кеше контракт буенча һәм үз теләге белән киткән. Сугышчыларга ярдәм күрсәтү максатыннан биредә гуманитар ярдәм җыю штабы эшли. Волонтёрлар белән тыгыз хезмәттәшлектә һәм җирле оешмалар, предприятиеләр белән бәйләнештә, хәрби хезмәттә булучылар өчен, аларның гаиләләре өчен кирәк-ярак әйберләр туплана.

ҖЫЛЫ КИЕМНӘН БАШЛАП, БЕСПИЛОТНИКЛАРГА КАДӘР

Буалылар махсус хәрби операция барган зонага даими рәвештә гуманитар ярдәм илтә. Сугышта катнашучы буалыларга 16 автомобиль, шул исәптән УАЗ «буханка», ВАЗ 21070, «Нива-Шевроле» машиналары, «Урал» мотоциклы, моннан тыш, 100 тонна гуманитар йөк илтеп тапшырылган. Барлыгы – 70 миллион сумлык. Иң беренче чиратта кирәк булган әйберләрне биредә өзлексез җыеп илтәләр: җылы кием, квадрокоптерлар, БПЛА детекторлары, рацияләр, бензопычкылар, медикаментлар, төнге күрү приборлары, җылыткыч мичләр, генераторлар һ.б.



ХӘРБИ ХЕЗМӘТТӘГЕЛӘРНЕҢ ГАИЛӘЛӘРЕНӘ ЯРДӘМ

Хәрби хезмәттәгеләрнең гаиләләренә даими ярдәм күрсәтеп торыла: балаларына ташламалар, түләүсез транспортта йөрү, түгәрәкләрдә бушлай шөгыльләнү каралган. Көнкүреш йә булмаса хуҗалык мәсьәләләрендә ихтыяҗ туса, мондый гаиләләр өчен махсус волонтёрлык ярдәме күрсәтү оештырылган.

Фото: Александр Ефремов

Тиз генә салып пешерә торган аш. Бөтен продуктлары да үзебезнеке: ит, баскан токмач, бакчадан җыеп алган үләннәр, тәмләткечләр.

«Күл Черкене авылы әбисеннән...»

АЛАРНЫ ЯРАТАЛАР ҺӘМ КӨТӘЛӘР...

«Ветераннар советы» штабындагы склад шыплап тулган. Һәр әйбернең, продуктның үз тарихы бар – мондыйны уйлап чыгарып булмый. Гуманитар ярдәм штабы җитәкчесе Резидә Мостафина белән бергә, ветераннар һәм ветеринар техникум студентлары махсус хәрби операция зонасына җибәрер өчен чираттагы йөкне туплый.

– Безнең үз бәйләү төркемебез бар – алар солдатларга оекбашлар бәйли, – дип сөйли Резидә Илгизәр кызы. – Кемдер тиз генә салып пешерә торган аш хәстәрли. Бөтен продуктлары да үзебезнеке: ит, баскан токмач, бакчадан җыеп алган үләннәр, тәмләткечләр. «Чишмә» хорына йөрүчеләр, әнә, акча җыеп, әйберләр сатып ала...

– Бер әбекәй 40 кульяулык алып килеп тапшырды, һәрберсенә: «Улым, Җиңү яулап, исән-сау әйләнеп кайт!» – дип язган. – Боларын инде волонтёрлар искә алып сөйли.

– Әле беренче мәртәбә йон оекбашлар җибәргәндә... анда да язу бар иде: «Күл Черкене авылы әбисеннән». Бер солдат, отпускка кайткач, әбине эзләп килде., бәйләгән оекбашлары өчен күп рәхмәт укыды, үзен күрәсе килгән...

– Балалар сугышчыларга рәсем ясый, хат яза. Хәтта бөтенләй бәләкәйләр дә. Бервакыт «Алга» батальонынннан яраланып кайткан солдат килде. Үзенә хатлар язган садик малайларына уенчыклар таратты. Башкалар нәүмизләнеп калмасын өчен, аларга да шоколадлар өләште. Мондый хәлләр көнелдә уелып кала, – ди Резидә Илгизәр кызы. Коллегалары аның сүзләрен дәррәү күтәреп ала:

– Безнең бер Бөек Ватан сугышы ветеранына быел октябрьдә 100 яшь тула. Ул әйтте: «Мин сугышны үз күзем белән күргән кеше, анда иң кирәге нәрсә икәнен беләм!» Һәм махсус бик олы-ы-ы-ы оекбаш бәйләргә кушты... – Сөйләүчеләр кулларын ике якка җәеп җибәрә. – Менә шундый киңлектә... Аның килене штабка олы-ы-ы-ы оекбашны бәйләп алып та килде: «Солдатларга җибәрегез, минем оекбашларны кисеннәр! Шундыйларны мин Бөек Ватан сугышы барганда кидем!» – дип әйтергә кушты әткәй, ди...

– Безнең Буада Николай Нестеров исемле солдат бар. Шулай берсендә отпускка кайтты. Штабка килде. Бездә алтынчы сыйныф укучылары экскурсиядә чак иде. Балалар барысы да Николай белән дуслашып бетте. Аңа фронтка, үз куллары белән ясап, саклый торган бөтиләр җибәрәләр. Ул аларга мәктәп музее өчен әләм алып кайтып бүләк итте. Хәзер инде балалар сигезенчедә укый, ә ул, отпускка кайткан саен, алар белән волейбол уйнарга килә, йә баскетбол... Аерып алып булмый балаларны үзеннән...

– Безнең халык Буада пешкән икмәкне бик ярата. Ниндидер аерым бер тәме бар безнең ипинең. Аны да сугышчыларга юллыйбыз. Бер майор-танкист хат та язып салды: «Посылканы ачып җибәрдем – ә анда ипи! Күзгә яшьләр килде... Әйтерсең, әнием янына кайтып килдем. Аның белән икәү, бер өстәл артында кара-каршы утырып, ипи белән чәй эчкәндәй булдым...»

Ничек уйлыйсыз, ни өчен яшьләр Буадан китми? Нигә аларны зур кала утлары кызыктырмый? Чөнки утлар да, яшьләр һәм канатлары ныгып өлгермәгәннәрдә кызыксыну уятырдай башка бөтен нәрсә дә үз районнарында бар. Өстәвенә, барысы да якында, янәшәдә генә. Укырга, эшкә, секция-түгәрәкләргә, ниндидер күңел ачу чараларына барып җитәр өчен, бөкеләрдә вакыт уздырырга, җәмәгать транспортына утырып, шәһәрнең бер башыннан икенчесенә барырга кирәкми. Кайвакыт юл аркылы гына чыгасы һәм син, мәсәлән, «Мирас» Яшьләр үзәгенә эләгәсең.

Буа: яшьләр

УҢЫШ КОДЫ – БУАДА

– Безнең «Мирас»ның эшли башлаганына бер генә елдан артык, – дип сүзен башлады әлеге якты, креатив бинада урнашкан үзәк директоры Диләрә Газизова. – Әмма монда инде 783 чара үткәрелде: фестивальләр, брейн-ринг, квест, психологик тренинг, мастер-класслар, «Гаилә кунак бүлмәләре», ШТКлар, хакатоннар, «Яшьләр советы», махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен гуманитар ярдәм оештыру максатындагы хәйрия чаралары, караоке кичәләре, «Буаның уңышлы кешеләре» очрашуы... Ә Сабан туенда, спорт бүлеге белән берлектә, хәтта фиджитал-көрәш тә үткәреп карадык!

ИҢ АКТИВЛАР ӨЧЕН

– Шулкадәр күп чараларны ничек оештырып өлгерәсез? Кешеләрегез күп күренми.

– Штатны арттыру – минем хыял, – дип елмая Диләрә Минисламовна. – Яшьләр белән эшләү буенча нибары ике белгеч бар. Кем эйтмешли, көнне төнгә ялгап эшлибез. Әле ярый актив балалар күп. Быел «МИРАС» активын оештырдык. Алар – барлык чараларда да беренче ярдәмчеләребез.

IT-ВУНДЕРКИНДЛАР ӨЧЕН

Район башлыгы Ранис Камәртдинов күрсәтмәсе буенча программалаштыру юнәлешендә түгәрәкләр эшләтеп җибәрдек. Башта – 1-8 сыйныф укучылары өчен, аннары 9–11 сыйныфлар өчен ачтык. Бу түгәрәкләргә ирле-хатынлы Мулеевлар җитәкчелек итә: кечкенәләрдә Анастасия Юрьевна алып бара, зурраклар Руслан Вадимович белән шөгыльләнә.

Казан IT-паркы белән килешү төзедек, хакатон уздырдык, анда балалар мобиль кушымталар буенча үз идеяләрен тәкъдир иттеләр. Иң сәләтле балалар район башлыгының «Уңыш коды» төркемендә бушлай шөгыльләнә.

IT-юнәлешенә бездә гомумән ихтыяҗ зур. Анастасия Юрьевна төркемендә 8–14 яшьлек 62 бала Python, Коду гейм лаб, Скретч кебек заманча программа телләрен өйрәнә. Аларның берсе дә мәктәп программасына керми. Балалар программалаштыру буенча төрле воркшопларда шөгыльләнә. 43 кеше турыдан-туры программалаштыру белән шөгыльләнә, 10 кеше веб-анимацияләр ясау буенча воркшопларда катнаша, 9 кеше модельләштерүне өйрәнә. Бер үк вакытта чат-ботлар булдыру буенча ИТ-парк курслары да бушлай үткәрелә.

Фото: Александр Ефремов

Зурлар төркеме – 15–17 яшьлекләр – Python теле нигезендә олимпиадаларда була торган программалаштыру белән шөгыльләнә, кад-системалар нигезендә 3D-модельләштерүне өйрәнә, архикад буенча курслар башладылар. Шулай ук информатика буенча БДИга әзерлек курслары да бар.

IT-биеклекләрне яулау компьютер һәм ноутбуклар белән җиһазландырылган киберзалда бара.

ЙОГАГА ГАШЫЙКЛАР ӨЧЕН

Алдагы кабинетта безне Алена Артемьева каршы алды. Психолог, коуч, нейрографика буенча белгеч һәм хатын-кызлар остазы – кыскасы, бөтен нәрсәне булдыра. Без кергәндә дә ул үзе кебек сөйкемле бер ханымга консультация бирә иде.

– Хатын-кызлар Алена Вячеславовна белән сөйләшкәннән соң ачылып китә, – дип аңлата Диләрә Минисламовна. – Ул күпкырлы белгеч, йога дәресләрен дә алып бара. Безнең шәһәрдә бик популяр юнәлеш. Яхшы физик формага ирешергә, нерв системасын тынычландырырга, аң-зиһенне чистартырга, эшкә сәләтне һәм стресска чыдамлыкны арттырырга ярдәм итә.

ЯШЬ ГАИЛӘЛӘР ӨЧЕН

Ял көннәрендә яшьләр үзәгендә гомумән аншлаг. Яшүсмерләр һәм яшь гаиләләр «Мафия» һәм «БУМ» өстәл уеннарын уйный, «Гаилә игротекасы», «Гаилә йогасы» эшли... Буалылар гомумән коллектив уеннарны үз итә. Бигрәк тә уеннардан соң бергәләп тәмләп чәй эчәргә форсат чыкканда. «Мирас»та барысы да чын гаиләләрдәге кебек җылы, күңелле итеп оештырылган.

БӨТЕН КЕШЕ ӨЧЕН

Биредә чит телләрне өйрәнергә теләүчеләр дә килә – «Инглиз телен яратучылар клубы»на, «Кытай телен яратучылар клубы»на.... Кич белән яшь-җилкәнчек «Яшьләр биюләренә» җыела.

Тәүлек буе эштә булуларына карамастан, үзәк хезмәткәрләре яңадан-яңа кызыклы идеяләре белән уртаклашып торалар.



– Якын араларда фото- һәм видеостудия, тавыш яздыру студиясен эшләтеп җибәрергә, шулай ук «Мортал комбат», ФИФА компьютер уеннары уздырырга ниятлибез... – дип санап китә Диләрә Минисламовна, бармакларын бөгә-бөгә.

Мондый уй-ниятләр белән янганда, Буа яшьләренә күңелсезләнергә урын калмаячак. Аларның төп бурычы – ничек тә булса озаграк яшь булып калудыр.

Буа: спорт

АТАКЛЫ ЯКТАШЛАР ИСТӘЛЕГЕНӘ

Буада якташларны ничек олылауларын музейда гына түгел, ә спорт ярышларында да күрергә була. Спорт чаралары традиция буенча, зурдан кубып, киң колач белән нәкъ менә алар истәлегенә уздырыла. Димәк, спортчылар да, җанатарлар да район тарихында җуелмас эз калдырган затларны беркайчан да онытмаячак, дигән сүз.

КАМИЛ ЗЫЯТДИНОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Ел саен Буада студентлар командалары арасында хоккей буенча турнир үткәрелә. Ул Россия һәм Татарстанның атказанган табибы, Буа ягында туып-үскән күренекле шәхес Камил Зыятдиновка багышланган. Турнир инде 8 ел дәвамында «Арктика» боз сараенда Камил Шәһретдин улының туганнары, Казандагы Буа якташлыгы һәм Буа ветеринар техникумы ярдәме белән оештырыла.

САБИРҖАН НӘФЫЙКОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Февраль ае җиткәч, Буада ел саен шәхси беренчелеккә чаңгы буенча районара ачык ярышлар уза. Алар СССРның спорт мастеры, Татарстанның атказанган тренеры, Буа районының Адав-Толымбай авылында туып-үскән Сабирҗан Нәфыйков хөрмәтенә оештырыла. Бәйгеләрдә чаңгы ярышы буенча төрле яшьтәге спорт мастерлары катнаша һәм ярыша. Иганәчеләр – Буа якташлык җәмгыяте һәм Сабирҗан Нәфыйковның улы Айдар.

МАРАТ САДЫЙКОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Район башлыгы Ранис Камәртдинов тырышлыгы һәм көче белән Буада милли көрәш актив үсә. Тренерларга район җитәкчесе тарафыннан һәр яклап зур ярдәм күрсәтелә. Алар, үз чиратында, авылларда яшьләр белән шөгыльләнә, шәһәр спортчылары белән дә эшли. Спортның бу төре уртак көч белән популярлыкның иң югары ноктасына җиткән. Баштарак район ярышлары уздырыла башлаган. Һәм менә икенче ел рәттән инде алар масштаблы республика ярышлары дәрәҗәсенә чыккан. Бу ярышлар Буа туфрагында

Фотолар Буа районы администрациясе архивыннан

туып-үскән тагын бер якташларына – күптән түгел генә арабыздан китеп барган ТР сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков истәлегенә багышлана.

АЙРАТ САДЫЙКОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Өченче ел рәттән буалылар махсус хәрби операция ветераннары һәм гамәлдәге хәрби хезмәттә булучылар белән бергә мини-футбол ярышлары уздыра. Әлеге турнир махсус хәрби операциядә катнашкан спортчы – Буада барысы да яраткан һәм хөрмәт иткән Айрат Садыйков истәлегенә оештырыла. Ике көн дәвамында уздырыла торган төбәкара ярышлар каһарманның туган көне алдыннан – гыйнвар башында үтә. Беренче көнне ветераннар командалары уйнаса, икенче көнне яшүсмерләр ярыша. Барлыгы 20 ләп команда катнаша бу ярышларда. Бүләкләү тантанасында МХОда катнашучы егетләр була – отпускка кайтучылар, реабилитациядәгеләр. Ике көндә дә тулы аншлаг, ди, чөнки буалылар – махсус хәрби операция каһарманнарының спорт буенча әзерлеге үсеп килүче буыннарга илһамланып өчен менә дигән үрнәк.

СПОРТТАГЫ ҖИҢҮЛӘР

Буа муниципаль районы 2024 елда Татарстан Республикасының XXI «Сәламәтлек» авыл Спартакиадасында бронза призёр була (II төркем).

Данила Смирнов – 2024 елда бөтен стильләр буенча карате дөнья чемпионатында көмеш призёр була (Орёл шәһәре). «2024 ел спортчысы» Данила – «Ел алгарышы» номинациясендә җиңүче.

Алинә Хәйруллина – чаңгы ярышлары буенча ТР беренчелегендә күп тапкырлар призёр. Ул – Татарстан Республикасының чаңгы ярышлары буенча егетләр һәм кызлар җыелма командасы әгъзасы.

Раяз Миначев – күп тапкырлар бадминтон буенча ярышлар призёры. 2024 елда Самарада узган егетләр һәм кызлар арасындагы бадминтон буенча Бөтенроссия ярышларында парлы, ялгыз разрядларда көмеш призёр була.

2011–2012 елларда туган егетләр командасы, 2012–2013 елларда туган кызлар командасы волейбол буенча ТР беренчелегендә ел саен призёр булып киләләр. 2011–2012 елларда туган егетләр волейбол буенча Татарстан Республикасы егетләр җыелма командасына керә.

Волейбол буенча ирләр җыелма командасы Кукмарада 2024 елда узган республика авыл районнары арасындагы иң көчле волейбол командалары Кубогында дүртенче мәртәбә беренче урын ала.

Мини-футбол буенча 2007–2008 елларда туган егетләр командасы 2024 елда Татарстанның кече шәһәрләре командалары арасында җиңү яулый.

2024 елда 18 яшькә кадәрге юниорларның хоккей буенча 3 кә 3 форматындагы Татарстан Республикасы беренчелегендә (2006 ел) **«Арктика» спорт мәктәбендә тәрбияләнүчеләр** беренче урын ала.

Буа: каһарманнар

105 ЯШЬ: УКЫДЫМ СУГЫШТЫМ ЯНДЫМ САВЫКТЫМ УКЫТТЫМ ҖИҢДЕМ ЯШИМ

Кызыл Йолдыз һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Германияне җиңгән өчен», «Сугыштагы казанышлары өчен», I дәрәҗә «Мактауга лаек хезмәт өчен», «Батырлык өчен», «Россиянең хезмәт ветераны», «Армия ветераны», «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре... Бөек Ватан сугышы ветераны Рәүф Ибраһим улы Төхфәтуллинның барлык бүләкләрен санап чыгу гына да бик күп вакытны алыр иде. Гыйнварда аңа 105 яшь тулган! Менә нинди озын гомерлеләр яши Буа районында!

Фото: Рәүф Төхфәтуллин архивыннан

Һәр кешенең гомере – сөенеч һәм көенечләрдән, уңыш һәм уңышсызлыклардан, шулай ук авырлыкларны җиңүдән, тормыш мәгънәсен һәм анда үз урыныңны эзләүдән гыйбарәт озын юл ул. Безнең геройга боларның барысын да кичерергә туры килгән.

Ул Буа районының Түбән Наратбаш авылында туып-үсә. Мәктәпне тәмамлагач ук, 1939 елда, Рәүфне Белоруссиянең Бобруйск шәһәрендәге хәрби училищега укырга җибәрәләр.

СУГЫШНЫҢ БИШЕНЧЕ КӨНЕНДӘ

1941 елның июнендә немецлар Белоруссиягә бәреп керә. Инде бишенче көнне үк фашистлар Бобруйскига килеп җитә. Яшь курсантлар Березина елгасы янында оборона тота, тиз арада хәрби укчыларга әйләнә.

Рәүф ага Белоруссиянең әлеге урман һәм сазлыкларын яхшы хәтерли – фашист танклары үтә алмый торган урыннар була ул.

– Мактаулы тимер машиналары баткак юлдан бара алмаганга, немецлар җәяүләп һөҗүм итте, – дип искә ала ветеран. – Аларның самолетлары һәр аланны, һәр чокырны туктаусыз бомбага тотты. Әмма алар бу участокны бер айга якын үтә алмады – курсантлар җаннарын кызганмыйча каршы торды.

СТАЛИНГРАДКА!

Июль уртасында курсантларны Сталинград янындагы хәрби лагерьга җибәрәләр. Һәм аларны танкка утырталар.

Сталинград янында нинди каты сугышлар баруын без китаплардан һәм тарих дәресләкләреннән укып беләбез, Рәүф ага исә үзенең танк экипажы өчен бик истәлекле бер көнне еш исенә төшерә. Әлеге сугыштан соң аларның дүртесенә дә «Батырлык өчен» медале бирелә, тик икесенә – үлгәннән соң...

– Без Т-34 танкында идек, – дип сөйли ветеран һәм кабат 1942 елның эссе июленә күчкәндәй була. – Фашистлар Сталинградка ыргыла. Әмма Калач шәһәре янында аларның юлына совет танклары чыкты. Ул чакта Сталинград язмышы безнең кулда иде. Без дүртәү: йөртүче механик, коручы, укчы һәм мин – экипаж командиры. Миңа ул чакта 22 яшь кенә әле. Мондый эсседә бронялы машинада бөтенләй һава юк, тир чиләкләп ага. Әмма моңа игътибар да итмисең. Безнең бурыч дошманны туктату, алга барырга ирек бирмәү, юк итү иде.

Тик менә кинәт коточкыч шартлау яңгырады – безгә туп тиде, ут чолгап алды, комбинезоныма да ут капты. Коручы һәм укчы шунда ук һәлак булды. Без механик белән көч-хәл танктан чыктык, җиргә тәгәрәп өстебездәге утны сүндердек. Шуннан соң гына икебезнең дә яраланган булуыбызны аңладык – аяклар да, арка да... Икәүләп госпитальгә барып җиттек, шунда дәваландык...

ТАНКИСТЛАР ӘЗЕРЛӘҮ

Госпитальдән соң Рәүфнең тагын фронтка китәсе килә, ул рапортлар яза. Әмма аңа, илгә танкистлар һәм механиклар кирәк, диләр. Кыю лейтенантны танк батальонына яшь солдатларны өйрәтергә җибәрәләр. Өйрәтәләр, фронтка җибәрәләр, тагын яңа солдатлар килә, тагын өйрәтәләр – һәм һәр көнне иртәдән төнгә кадәр шулай дәвам итә.

– Танклар һәрвакыт сугышка әзер булырга тиеш, – дип сөйли ветеран. – Әгәр кичтән ватылган Т-34 не паркка китереп куйсалар, иртән ул кабат сафта булырга тиеш. Фронт танклар һәм аларны йөртүчеләрне туктаусыз таләп итә. Бер ай эчендә танк экипажын өйрәтергә һәм фронтка җибәрергә кирәк. Безгә менә шундый бурыч куелган иде.

ГОМЕР ҮТӘ...

Бу моннан 83 ел элек булган. Аннары – Җиңү һәм тыныч күк йөзе. Әмма Рәүф Төхфәтуллин армиядә хезмәт итүен ташламый: 1965 елга кадәр танк взводы командиры була һәм ремонт остаханәләре белән җитәкчелек итә. Шуның 15 елы ГДР территориясендә уза.

Тыныч тормышта Рәүф Ибраһим улы Коммунарск тау-металлургия институтындагы металларны өйрәнү кафедрасында лаборатория мөдире була, бүлек җитәкле... Пенсиягә полковник дәрәҗәсендә чыга.

ГАЗИЗ ВАТАН ТАРТА

Аннары исә туган Буа районына әйләнеп кайта.

– Туган җиремдә үләчәкмен! – ди ул.

Әмма, җырда җырланганча, безгә яшисе дә әле яшисе...

Хәзер Рәүф Ибраһим улы яшь буынга патриотик тәрбия бирә – үз буыны каһарманнарының ничек яшәве, сугышуы, януы, исән калуы, җиңүләре хакында сөйли... Бу буынны беркем дә җиңә алмаячак, һәм 105 яшьлек ветеранның актив тормышы моңа дәлил булып тора.

Рәүф Төхфәтуллин һәм район башлыгы Ранис Камәртдинов.



ИКМӘКЛЕ, ШИКӘРЛЕ ТӨБӘК

…Гыйнвар азагы, ә бередә әле һаман урак өсте – шикәр чөгендерен «КАМАЗ» машиналарына төйиләр.

Руфия Фазылова

– Шикәр чөгендеренең уңышы бик яхшы. Соңгы егерме елда әле мондый күрсәткечләрнең булганы юк, – диде әңгәмәдәшем, Буа районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Ранис Габитов.

Буа кырлары ала-кола булып калган. Кар астыннан мамык кебек йомшак кара туфрак чыгып килә. Әйе, монда туфрак уңдырышлы, корыган чыбык төртсәң дә тишелер, билләһи.

РЕКОРДЛЫ ЧӨГЕНДЕР

Кыш уртасында кар астыннан шикәр чөгендере төяү беренче карашка гайре табигый хәл кебек. Тик авыл хуҗалыгында эшләүчеләр белә – монда гаҗәпләнерлек урын юк. Алдагы елларда да шулай кыш уртасына кадәр чөгендер алганнар. Әле быел җайлырак: кар көртләрен эттерәсе юк, зәмһәрир суыклар да эшләргә комачауламый.

– Чөгендерне көзен алып бетерергә җай булмадымы? – дим.

– Булды. Әмма районда шикәр заводы бер генә бит. Бер дәлил китерәм: Буа шикәр заводы яңа рекорд куйды: 900 мең тоннадан артык чөгендер кабул итте. Үз тарихында әле мондый сан булмаган. Бүгенге көнгә завод 140 мең тоннага якын шикәр җитештерде. Кырларда чөгендер һаман бар, димәк эш дәвам итә. Буа гына түгел, күрше-тирә районнардан да заводка чөгендер китерәләр. Завод көне-төне эшләсә дә, моның кадәр чөгендерне тиз арада эшкәртеп бетерә алмый.

Буалылар 500 мең тоннага якын шикәр чөгендере җыеп алган инде. Бу эшкә 29 августта керешкәннәр. Гектарыннан 460 центнер уңыш чыккан. Кыскасы, 2024 ел район өчен, ә юк, бөтен республика өчен шикәрле булган.

РЕСПУБЛИКАДА – БЕРЕНЧЕ!

Буалылар җыелган ашлыкның күләме буенча республикада беренче урында. Узган ел алар 185 мең тонна ашлык җыеп алганнар, гектарыннан 32,6 центнер иген чыккан. Хәер, алдагы елларда да Буа игенчеләре сынатмаган, бередә уңыш гел яхшы.

Районның чәчүлек мәйданы 100 мең гектар: якынча 60 мең гектарында – бөртекле, кузаклы культуралар, 10 мең гектардан артыгында – чөгендер, 6 мең гектарда – көнбагыш, калганында кукуруз, күпьеллык үлән үсә.

Буаның уңдырышлы туфрагы турында авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләр яхшы белә. Ләкин уңышның сере монда гына түгел: заманча технологияләр куллану, вакытында чәчү, ашлама кертү, җыю... Әлбәттә, һава торышының да уңай килүе шарт.

– Бүген авыл хуҗалыгын минераль ашламалардан башка күз алдына китереп булмый, – диде Ранис Габитов. – Узган ел бер гектарга 89 кг ашлама керттек. Шулай ук ел саен әче туфракка известь кертәбез. Быел 4468 гектар, ягъни бөтен мәйданнарда туфракны известьләдек.

Фото: Буа районы авыл хуҗалыгы идарәсе архивыннан

«БАШ САНЫ КИМЕСӘ ДӘ, САВЫЛГАН СӨТ КҮЛӘМЕ САКЛАНА»

Сөт саву, ит җитештерү буенча Буа районы алдынгы булмаса да, артта да түгел. Күрсәткечләрнең тотрыклылыгын сакларга тырыша алар. Район терлекчеләре узган ел 33 800 тонна сөт җитештергән. Бу 2023 ел белән чагыштырганда 100 тоннага кимрәк (33 900 тонна булган).

– Узган ел ике меңгә якын сыерны киметтек, – дип дәвам итте сүзен авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы. – Ни өчен киметтек, чөнки аз сөт бирә торган сыерларны иткә озаттык. Ләкин аңа карап савылган сөт күләменә әллә ни зур зыян килмәде. Агымдагы елда районга 600 баш МЭТ алып кайтуны планлаштырдык. «Заря» хуҗалыгына инде 81 баш сыер сатып алынды. Ә менә ит җитештерү буенча 2023 ел күрсәткечләрен арттырып үтәдек, барлыгы 24 мең тонна ит төяп озаттык. Шунысын да әйтим: бездә күбрәк дуңгыз ите җитештерелә.

Районда кошчылык тармагы да үстерелә. Исәк авылында яшәүче Илдар Гыймалов 2020 елда «Яңа эш башлаучы фермер» программасы ярдәмендә 3 миллион сум грант откан. Нәтиҗәдә, 10 мең баш кош сыйдырышлы ферма төзегән. Баш санын ел саен арттыра икән фермер. Узган ел Илдар Гыймалов 17,8 тонна күркә, тавык ите җитештергән.

ФЕРМЕРЛАРГА – АК ҖӘЙМӘ

Буада эре холдинглар белән фермерлар ярышып эшли. Араларында аеруча тәҗрибәле, абруйлылары бар. Мисал өчен Бик-Үти авылында яшәүче Дәүләтшиннар хуҗалыгы. Гаилә башлыгы Җәмил Дәүләтшин фермерлык эшенә егерме ел элек килгән. Башта ул пай җирләрен алып эшкәрткән. Техникасын юнәткән. Ныклап торып иген, печән, шикәр чөгендере үстерә башлаган. Тик тынгысыз фермер икенче юнәлешне дә өйрәнергә карар кылган. 2017 елда Бик-Үти авылыннан ерак булмаган ташландык алма бакчасын арендага алган. 2018 елда ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан җиләк-җимеш культураларын үстерү максатына 1,5 миллион сумлык грант алган.

– Әлбәттә, дәүләт биргән акча гына җитмәде, – дип елмайды Җәмил Дәүләтшин. – Моңа киткән акчалар... Әле үзләрен кайчан аклар. Тик үкенмим: алма бизнесы үзебезгә бик ошый. Бүген алмагач басуының мәйданын 40 гектар иттек. Әлегә 36 гектарына 60 мең алмагач утырттык. Алмагачларны ел саен утыртабыз. Ул бит карап торышка гына җиңел кебек, ә аның үз технологиясе бар: сортына, төренә карап эш итәбез. Трактор йөрсен өчен, агач араларын 4 метр калдырабыз. Бөтен мәйданда «автополив» тора. Алты ел эчендә ялгышлар да булды инде, шулай эшли-эшли өйрәнәбез.

Дәүләтшиннарны якын-тирә районнар да белә, алмаларын күпләп алып китәләр икән. Көзге ярминкәләрдә дә алмаларын чират торып алып бетергәннәр. Алга планнары зурдан: алма согы да ясап сатарга ниятлиләр.

«Исәнлек кенә булсын», – ди алар.

...Буа районы хуҗалыклары ел саен югары җитештерүчәнлекле техника сатып ала, авыл хуҗалыгы тармагына заманча технологияләр кертә. 2024 елда 628 миллион сумга 174 (!) берәмлек яңа авыл хуҗалыгы техникасы һәм җайланмалары сатып алынган. Бүген энергия белән тәэмин ителеш 100 гектар чәчүлек мәйданына 201 ат көчен тәшкил итә. (Чагыштыру өчен: республикада уртача күрсәткеч – 183 ат көче).

Яңа техниканы нәтиҗәле куллану хуҗалыкларга хезмәт җитештерүчәнлеген дә, башкарылган эшләрнең сыйфатын да күтәрергә мөмкинлек бирә. Ә шулай да буалыларның уңышы – аның тырыш халкында, җитәкчелек белән аңлашып эшләүдәдер.

2024 елгы кыр батырлары.

Буа районында:

125 **авыл хуҗалыгы оешмасы**,

шул исәптән:

6 **җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять**,

1 **авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы**,

1 **ААҖ** һәм

117 **крестьян-фермер хуҗалыгы** эшли.

ЯҢА ТИНЧӘЛЕНЕҢ ЯҢА СУЛЫШЫ...

ЯҢА ТИНЧӘЛЕ

Руфия Фазылова

Буа районының Яңа Тинчәле авылын җәен барып күргән идек. Ясалма күл, ял итү парклары, чын мәгънәсендә шаккатып, тел шартлатып кайттык. Һәм менә берничә елдан соң, кышкы Яңа Тинчәлене дә күрү насыйп булды. Санаулы вакыт эчендә авыл янә үзгәргән!

Фото: Лилиана Вәлитова

ПАРКЛЫ-КҮЛЛЕ АВЫЛ

Яңа Тинчәленең бөтен урамнарына асфальт түшәлгән. Юл кырыйларына куаклар утыртылган, шәһәр диярсең!

Авыл уртасына күл дә ясап куйганнар. Балык тотар, ял итәр өчен тимер беседкалар да бар. Авыл халкы суга карп, кызылканат балыклары да җибәргән.

– Элек монда кое булган, – диде авыл җирлеге башлыгы Радик Мадышев. – Әби-бабаларыбыз аннан су алган. Әмма ул кое ишелеп юкка чыккан. Без аны өлкәннәрдән сорашып, чыганагын таптык. Шуны казып, чишмә ясадык. Нәтиҗәдә, күл бүген – авылның күрке.

– Күлне үзсалым акчасына казыдыгызмы? – дим.

– Юк. Авылларны төзекләндерүгә юнәлтелгән махсус дәүләт программасы бар, без шуңа эләктек. Иганәчеләр дә булышты. Бу халыкның яраткан урыны. Җәен монда гел кеше: коймак пешереп концертлар куялар, биешәләр. Бала-чага да күп була.

Күлнең янәшәсендә үк ял паркы да эшләнгән: сәхнәсе, уен мәйданчыклары, фонтаны булган заманча урын бу! Декоратив агач-куаклар утыртылган.

– Ә паркны нинди акчага ясадыгыз? – дигән соравыбызга җавапны стендка язып куелган иганәчеләр исемлегендә табабыз: берничә кеше 250 шәр мең сум, кайсылары йөзәр мең сум, кайберләре утызар мең сум, бишәр мең сум... Тамчыдан күл җыелган. Иганәчеләр арасында Татарстанның элеккеге финанс министры Радик Гайзатуллин һәм аның бертуганының, «Серго исемендәге завод» ҖБ» ААҖ генераль директоры Радик Хәсәнов һ.б. ның исемнәрен күрәбез.

– Алар безнекеләр! Якташлар! – ди авыл җирлеге башлыгы. – Туган авылларына һәрвакыт булышалар.

ПАТША РӨХСӘТЕ БЕЛӘН АЧЫЛГАН МӘЧЕТ

Яңа Тинчәленең тагын бер матур, дөресрәге, изге урын бар – авылның беренче мәчете урыны ул. Баксаң, Татарстанда иң борынгы мәчет Яңа Тинчәледә салынган икән. 1753 елда Елизавета мәчет төзергә рөхсәт биргән. Ни аяныч, XVIII гасырда төзелгән мәчет совет чорында кадерсезләнеп юкка чыккан. Һәм менә ике гасырдан соң, аның урынын тимер рәшәткә белән уратып, өстенә гөмбәз ясап куйганнар. Юкка чыккан мәчетнең таш нигезен җир астыннан казып алып, пыяла астына урнаштырганнар. Яңгыр да, кар да тими. Киләчәк буыннар өчен чын мирас ул!

...ҺӘМ АВЫЛДАШЛАРЫ БҮЛӘГЕ

Бүген дә Яңа Тинчәледә бер түгел, ике мәчет эшли. Берсе аның 1991 елда салынган, икенчесе – 2008 елда. Соңгысы бигрәк заманча – ике катлы, бөтен җире каралган. Анысын авылдашлары Радик Гайзатуллин бүләк иткән.

– Яңасы «Рәүф» мәчете дип атала. Бу – Гайзатуллиннарның төп нигезе, – диде мәчет имамы Илдар Шәрифҗанов. – Бер мәчеткә сыймый башлагач, ярдәм сорап Радик Рәүф улына мөрәҗәгать иттек. Ул каршы килмәде. Алай гына да түгел, әнисе белән киңәшләшкәч, үзләренең төп нигезләренә мәчет салырга тәкъдим итте.

Ике мәчеттә дә җомга саен егерме-утыз ир-ат була икән. Хатын-кызлар исә «Рәүф» мәчете каршындагы мәдрәсәгә укырга йөри. Авылның йөздән артык кешесе Коръәнне гарәпчә укый белә.

ЯҢАРТЫЛГАН МӘДНИЯТ ЙОРТЫ

Узган ел азагында авыл өчен янә бер сөенечле вакыйга булган – мәдәният йортына капиталь ремонт ясалган. Аны дәүләт программасы ярдәмендә тормышка ашырганнар. Хәзер Яңа Тинчәле мәдәният үзәге эчтән дә, тыштан да балкып тора.

– Монда мин 1998 елдан бирле эшлим, – диде мәдәният йорты җитәкчесе Интал Шәйхаттаров. – Дөресен әйтим, мәдәният йорты болай



Ике гасырдан соң, борынгы мәчет урынын тимер рәшәткә белән уратып, өстенә гөмбәз ясап куйганнар.





1
«Рәүф» мәчете 2008 елда сафка баскан.

2
– Бу – Гайзатуллиннарның төп нигезе, – диде «Рәүф» мәчете имамы Илдар Шәрифҗанов.

ук матур булыр дип уйламаган идем. Җиде-сигез ай эчендә эшләп чыктылар. Монда хәзер бар да шәһәрчә, заманча. Ә болай мәдәният йорты 1972 елда төзелгән.

Ул да түгел Интал абый кулындагы тальянын сызып җибәрде. Профессионалларча уйный! Алты яшендә үк кулына гармун алган.

– Гармунда уйнарга әтием өйрәтте, ул бик оста иде, – диде ул. – Гармун эшебезгә дәрт өсти. Бер генә бәйрәмне дә игътибарсыз калдырмыйбыз. Хәзер бигрәк тә, бинабыз матур, заманча булгач, кайтучылар да чыга.

«ӘНИ, ДИМӘК, ШУЛАЙ КИРӘК!»

Мәдәният йортының икенче катында китапханә. Капиталь ремонт вакытында аны да үзгәрткәннәр. Фонд та яңарган, Мәскәү, Санкт-Петербургтан ук йөзгә якын яңа китап кайткан. Китапханәче Гөлгенә Әбҗәлилова алардан күргәзмәләр ясап куйган. Яңа проектор эшләп тора, балалар, өлкәннәр белән төрле чаралар үткәрәләр икән.

Китапханәдәге аерым бер почмакка күз төшә – махсус хәрби операция зонасындагы авылдашлары Ленар Әбҗәлиловка багышлап эшләнгән ул. Егетнең фронтта төшкән фотолары, бүләкләре...

– Бу минем улым. Яңа Тинчәледән мобилизацияләнгән бердәнбер егет ул безнең. Повестка килгәч, шунда ук китте: «Әни, димәк, шулай кирәк!» – диде, – дип сөйли Гөлгенә апа, күз яшьләрен сөртеп. – Ленарыбыз әле Казанда, хастаханәдә ята. Атна саен янына барып йөрибез. Бу инде икенче яралануы. Улыбыз өчен көн саен догада торабыз. Әле Казанда булганда күңел тыныч, тагын ничек озатырбыз...

Ленарга, калган меңләгән егетебезгә, саулык һәм иминлек белән тизрәк өенә әйләнеп кайтуларын телибез.

41 ЕЛ БАЛАЛАРЫ

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан, яңа проект башлыйбыз: «Кырык беренче ел балалары». Бөек Ватан сугышы башланган чорда туган, тәпи киткән сабыйларның язмышы ничек булып беткән? Нинди могҗиза белән исән калган алар? Яңа Тинчәледә яшәүче Дамил Җиһанша улы Фәтхуллин да сугыш башлангач туган. Башка меңләгән яшьтәшләре кебек үк, ул да әтисенең җылы карашын, акыллы киңәшләрен хәтерләми. Ләкин шунысына сөенә: сугышка киткәнче, әтисе аны кулына алып сөеп калган.

– Әтием Җиһанша тракторчылар бригадиры булган, – диде Дамил абый. – Сугыш башлангач, дүрт ай авылда торган әле, хезмәттә булган. Аннан соң барыбер фронтка чакырып повестка җибәргәннәр. Әти 20 октябрьдә сугышка киткән. Мин ике атналык булып калганмын...

Ни аяныч, Яңа Тинчәленең тракторчылар бригадиры Җиһанша шул китүдән башка туган ягына әйләнеп кайтмый. Берсеннән-берсе кечкенә биш баласы белән ялгыз калган тормыш иптәшенә: «Танкист булдым. Бар да тәртиптә. Исән-имин курешергә насыйп итсен», – дип сагынычлы кайнар хатлар язгалап тора. 1943 елның җәендә исә Фәтхуллиннар йортына кара мөһер сугылган хат килә. Танкист Җиһанша шулай итеп хәбәрсез югала.

– Сугышка киткәндә әтигә егерме сигез яшь була, – дип дәвам итте Дамил абый. – Юлга кузгалганчы һәр баласын кочагына алып сөйгән

ул. Бишектән мине дә кулына алган. Аннан әнигә әйткән: «Бу бала озак яшәмәс инде, бик кечкенә, җәннәт кошы булыр. Ничек тә тә олыракларын үстерергә тырыш, сакла аларны...» Әти сугыштан исән кайтса, минем нинди тере, үткен булып үсүемне күреп шаккатыр иде, юк бит, кайтмады.

Биш туганнан Дамил абый бүген берүзе исән. Төп нигездә калып, гаилә корып, әнисен тәрбияләп, балалар үстереп, бик матур тормыш кичергән. Иң сөенечлесе – бүген дә егетләр кебек йөри, көн дә рульгә утыра. Кирәк җиренә машинасы белән тиз генә барып кайта.

– Техниканы кечкенәдән яраттым, – ди ул. – Шуның өчен дә гомер буе колхозда баш механизатор булып эшләдем.

– Дамил абый, күңелегезгә тиясем килми, шулай да... Әтисез үсү авыр булдымы? – дидем.

– Авыр булды, кызым. Хәер, ул чорда кемгә җиңел булды икән? Үземне белгәннән бирле дуңгыз көтүе көттем. Яшәргә кирәк бит. Сугыш беткәннән соң, кайбер яшьтәшләрнең этиләре исән-имин өйләренә кайтты. И, алар горур йөрде инде. Аларның этиләренә ат бирделәр, алар шунда җилдерде. Һәм этиле балаларга сыер, ат көтүе бирәләр иде. Берсендә, сыер көтүе бирүләрен сорап, колхоз идарәсенә бардым. «Әнем, сиңа тагын дуңгызлар калды инде. Сыер көтүен Гали абыеңның балалары алды, этиләре белән бергә көтәләр», – диделәр. Менә шунда юл буе елап кайтканым истә. «Эх, минем дә эти булса, атта гына йөрер идем. Эти, ник син кайтмадың?» – дип өзгәләндем.

Дамил абый күз яшьләрен сөртте. Ничәмә дистә еллар узган, ә ятимлек ачысын һаман онытмаган ул. Хәер, аны ничек онытасың?!

АВЫЛНЫҢ БҮГЕНГЕСЕ

...Яңа Тинчәлегә ике ел эчендә дүрт гаилә күченеп кайткан. Шуның икесе яшь гаилә. Әлбәттә, авыл өчен бу зур сөенеч. Мәктәптә бала саны да, яңа эшче көчләр дә арткан. Җирле җитәкчеләр мондый гаиләләр тагын булыр, дип өметләнә.

Авылда бүген 356 кеше яши, 232 хуҗалык бар. Мал асраучылар күп, ике көтү чыга, хуҗалыкларда савым сыерлары 158 баш. Тагын монда крестьян-фермер хуҗалыклары киң җәелеп эшли, андыйлар унау. Нигездә алар игенчелек, үсемлекчелек белән шөгыльләнә. Яшелчә дә утырталар. Иң кечкенә фермерда 100 гектар җир булса, зурларында бер мең ярымлап гектарга җыела.

Яңа Тинчәленең җирләре «Заря» агрофирмасына карый. Биредә аларның зур, заманча фермалары бар, анда 400 баш нәселле савым сыеры тора. Авылның егерме биш кешесе шунда хезмәт куя.

– Үзебездә ягын сүндерү бүлекчәсе бар, – диде Радик Мадышев. – Аны быел дәүләт программасы ярдәмендә җылытыла торган итеп төзекләндердек. Авылыбызның өч ир-аты шунда эшли, хезмәт хакын иганәчеләр дә, үзсалым акчасыннан да түлибез. Янгын сүндерү машинасы авыл җирлегенеке.

Бер генә теләк – Яңа Тинчәледә халык саны кимемәсен, мәктәбе ябылмасын. Чынлап та, яшәр өчен биредә бөтен мөмкинлекләр бар. Т

3 2024 елның ноябрендә яңартылган авыл мәдәният йорты эчтән дә, тыштан да балкып тора.

4 Китапханәне дә яңартканнар: түшәмен, диварларын, китап фондын да.

5 Яңа Тинчәледә яшәүче Дамил Фәтхуллин сугыш башлангач туган. 84 яшендә әле машина йөртә, кирәк булса, үзе ремонтлый да.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Тинчәле – ак тәнле, укымышлы, зыялы кеше мәгънәсен белдерә, дип әти әйтә иде. Тинчәледә башка авылларга караганда гыйлем һәм мәгариф алда булып, күп авыллардан, күрше районнардан килеп шәкертләр укыган.
Авыл картлары, борынгы бабаларыбыз Татар Согыты авылыннан (хәзерге Чувашия Республикасы) күчеп килгән, дип сөйли иде. Казан ханлыгы алынгач, татарлар, яхшы җирләрен ташлап, бу якларга килеп урнашкан. Ул чакта бу җирләрдә чувашлар яшәгән. Ләкин алар татарларны яхшы кабул иткән һәм ике милләт, бик дус булып, бергә гомер сөрә башлаган. Соңрак монда татарлар гына калган.

Касыйм Бикколов, язучы

Буа: перспективалар

РАЙОН.
ҮСЕШ НОКТАЛАРЫ

Сәяхәтебез тәмам. Буа яклары белән танышып, шәһәрнең төрле предприятиеләрендә булып, фермерлар белән аралашып һәм заманча җәмәгать урыннарын, театр, мәдәният йортларын карап, табигатенә сокланып йөргәннән соң, мондый нәтиҗәгә килдек: әлеге үзенчәлекле район турында без инде шактый беләбез – тарихыннан алып киләчәккә корылган планнарына кадәр.

Безнең бу сүзләребезне ишеткәч, район башлыгы Ранис Камәртдинов бераз төзәтмә кертте: чынлыкта Буа шәһәре, район җирләре һәм аның тырыш хезмәтчәннәре белән танышу өчен бер ай да җитми. Яңа үсеш нокталары да без күргәннәргә караганда күпкә күбрәк.

– Үсешнең иң мөһим нокталарының берсе – «Буа» сәнәгать паркы, – диде Ранис Рафис улы. – Биредәге 26,7 гектар мәйданда кече һәм урта бизнесны үстерү өчен барлык шартлар да тудырылган. Бүген җиде компания сәнәгать паркы резиденты булып тора, әмма 19 гектар мәйдан әлегә буш. Бурыч – бирегә бизнесны активрак җәлеп итү, алар ярдәмендә район-

Фотолар Буа администрациясеннән алынды

 га файда китерерлек проектларны гамәлгә ашыру, яңа эш урыннары ачу.

Аңлашыла ки, яңа проектларны гамәлгә ашыру һәрвакытта да җиңел бармый. 2019 елда район бер инвесторны тапкан иде. Ул сәнәгать паркында балык эшкәртү заводы төзи башлады. Әмма соңрак проект тукталды. Ләкин без өметсезлеккә бирелмәдек. Районның чимал белән тәэмин итәрлек ресурслары бар. Балык эшкәртүне башка мәйданчыкта җайга салдык. Шуңа күрә әлеге марка инде эшли, әзер продукция үз сатып алучысын тапты, шул исәптән Казанда да. Буа районында балык эшкәртүне арттыру өчен 250 миллион сум инвестиция таләп ителә.

Перспективалы башка проектлар арасында – көнбагыш мае ясау, җитештерүчәнлеге тәүлегенә 150 тонна булырга тиеш. Буада, Татарстанның күрше районнарында һәм Чувашиядә көнбагыш үстерү күләмнәре 50 эш урыны ачылачак предприятиене чимал белән тулысынча тәэмин итеп булачагында шик уятмый.

Төзелеш һәм инерт материалларны, сыек һәм каты ашламаларны, авыл хуҗалыгы продукциясен тимер юлга күчереп төяү хаблары төзү проекты да районда кече эшкуарлыкны үстерүгә этәргеч бирәчәк. Куелган бурычларны үтәү өчен махсуслаштырылган «Мостопоезд-33» ҖЧҖ базасында компетентлы команда бар.

Тагын бер мөһим нәрсә: биредә икътисадның яңа үсеш нокталарын социаль һәм торак төзелеше тармакларын үстерү белән турыдан-туры бәйлиләр. Бүген яшәү өчен уңайлы шартлар тудырмыйча, хезмәт ресурсларын җәлеп итү мөмкин түгел, дип фикер йөртәләр монда. Аерым алганда, 23 гектар мәйданда «Якты Алан» торак комплексы да әлеге максатны күздә тотып төзелә. Биредә биш һәм тугыз катлы 19 күпфатирлы торак йорт төзеләчәк, мәктәп, бассейн, балалар бакчасы, мәдәният йорты, ФАП һәм 7 сәүдә объекты ачылачак. Инвестицияләр күләме 6,5 миллиард сумнан артып китәчәк.

Туризмны да онытмыйлар Буада. Районның бай тарихы, күркәм бүгенгесе, матур табигате һәм күңелле ял итү урыннары бар дигән сокланууларыбыз раслана: ТР шәһәрләрен үстерү институты районда глэмпинглар проектлау эшен башлаган. Күргәнебезчә, үсеш нокталары аз түгел. Әмма аларны тормышка ашыру да җиңел булмаячак. Хәер, бу бит Буа. Монда сүзләрен эш белән расларга күнеккән халык яши.

– Бер елдан тагын килегез, – дип чакырып калдылар администрациядә. – Күрерсез, безнең күп кенә планнарыбыз инде чынга ашкан булачак.

Һичшиксез барып күрербез!

Муниципалитетлар үсешенең төрледән-төрле мәсьәләләрен хәл итүдә, авыл кешеләренең тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүдә ярдәмнәре, барлык федераль һәм республика проектларында катнашу мөмкинлеге тудырылганы өчен, Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнехановка, республика Хөкүмәтенә һәм Дәүләт Советына ихлас рәхмәтемне белдерәм.
Якташларыбызга, барыннан да элек Ирек Мөнир улы Закиров җитәкләгән Казандагы Буа якташлык җәмгыятенә рәхмәтемне җиткерәм. Шулай ук ТР төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Мансур улы Айзатуллинга, «ТАИФ» АҖ Директорлар советы рәисе Рөстәм Нургасыйм улы Сүлтиевкә, ТРның элекке финанс министры Радик Рәүф улы Гайзатуллинга, ТР Дәүләт Советы депутаты Ринат Рәүф улы Гайзатуллинга һәм башка якташларыма туган як тормышы белән гел кызыксынып торулары, аны үстерүдә катнашулары, үзләреннән өлеш кертүләре өчен бик зур рәхмәт әйтәм.

«Якты Алан» торак комплексы, өстән күренеше.

AGRATOR DISK

AGRATOR DISK 9000
AGRATOR DISK 12000

ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЛАРЫ

РЕКЛАМА

AGROMASTER

www.pk-agromaster.ru

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы, Тукай ур., 33 а, e-mail: agromaster@mail.ru
тел: 8 (85556) 2-39-08, 2-43-59, сот.: 8-939-396-83-44

САБА ТӨБӘГЕ «УМЫРЗАЯ»СЫ

Дмитрий Сивков

Узган ел ахырында Казанның «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексында «Ел җитәкчесе – 2024» республикакүләм иҗтимагый конкурсы лауреатларын бүләкләү тантанасы узды. «Кече – урта бизнес предприятиесе белән уңышлы идарә итү» номинациясендә «Умырзая» авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы рәисе Рамил Рәшит улы Гарипов лауреат исемен яулады. Аның белән уңышлы бизнес серләре турында әңгәмә кордык.

– Рамил әфәнде, 15 ел эшләү дәверендә предприятиегез Саба районының күп кенә хуҗалыкларына ит сату проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирде һәм, ирешелгәннәрдә туктап калмыйча, сыйфат ягыннан яңа үрләргә күтәрелде. Мондый нәтиҗәләргә нәрсә хисабына ирештегез?

– «Умырзая» кооперативы 2009 елда төзелде. Сигез ел ит әзерләү һәм аны үз кибетебез аша сату белән шөгыльләндек. 2017 ел безнең өчен борылыш елы булды. Ул вакытта без, республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы грантын отып, «2015–2017 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» программасына кушылдык. Тәүлегенә 24 баш терлеккә исәпләнгән терлек чалу пункты шул грант хисабына төзелде. Соңрак сөякләрне иттән аеру цехын төзеп, аны кирәкле җиһазлар белән тәэмин иттек, бу да үз чиратында җитештерүчәнлеккә йогынты ясады.

– Кооперативта җитештерү күләме биш ел эчендә 85%тан артыкка үскән. Мөгаен, ит җитештерүчеләр белән ныклы хезмәттәшлек урнаштырылмаса, мондый нәтиҗәләргә ирешеп булмас иде. Сез аларга нинди таләпләр куясыз һәм нәрсә белән кызыксындырасыз?

– Без хезмәттәшләрнең терлекләрне график буенча гына түгел, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, шалтырату белән үк китерергә әзер булуын телибез. Ашыгыч заказлар да була бит. Әлбәттә, терлекләр барлык ветеринария таләпләренә туры килергә тиеш. Үгезләрне иткә тапшыру авырлыгының нормасы – 450+ килограмм. Яхшы симертелгән хайваннарга өстенлек бирелә, аларның ите деликатес ризыкларга китә. Ә җәлеп итүгә килгәндә, бездә бәяләр читтән килгән алыпсатарларныкына караганда югарырак. Өстәвенә, ит тапшыручылар үлчәгәндә бернинди алдау-йолдау булмаячагын белеп тора.

– Әгәр аныграк итеп әйтсәк, бүген сезнең бизнес...

– Җитештерүдән тыш, Саба һәм күрше-тирә районнарда җиде фирма кибете ул. Төп сату базарлары исә – Казан, Ижевск һәм Әгерҗе, шулай ук Мәскәү өлкәсе. Кооперативта 51 кеше эшли, бер ел элек 47 иде.

– Узган елга күз салсак, кооперативның җитештерү эшчәнлеге планы нигезендә сез аны ничегрәк бәяләр идегез?

– 2024 елда гомуми авырлыгы 4646 тонна булган 1021 баш терлек сатып алынды. 2271,7 тонна ит җитештерелде һәм сатылды. Продукция сатудан кергән гомуми керем күләме 802 млн сум тәшкил итте. Ел дәвамында Саба, Кукмара һәм Теләче районнары мәктәпләрен, балалар бакчаларын да югары сыйфатлы ит белән тәэмин иттек. Терлек чалу цехын төзекләндердек, административ бина төзедек.

– Бу елга нинди планнар? Мөгаен, сез ирешелгәннәрдә тукталып калырга җыенмыйсыздыр.

– Производствоны киңәйтү планнарына килгәндә, 720 квадрат метр мәйданлы яңа эшкәртү цехын төзеп бетерүне күздә тотабыз. Анда сигез суыткыч камера урнаштырырга ниятлибез. Шунда ук итне эшкәртеп ярымфабрикатлар, пилмән, төрле казылыклар җитештерәчәк цех та булырга тиеш.

Билгеле бер кыенлыкларга карамастан, «Умырзая» кооперативының планнары тормышка ашачагына ышаныч бар. Аңа юкка гына «Умырзая» дип исем кушылмаган. Кар көртләре эреп беткәнче, ара-тирә җир ачылу белән үк чәчәк ата бит умырзая.

Фото Рамил Гариповтан алынды. РЕКЛАМА

ЭМИЗ гастромәйданы – **традицияләрне саклыйбыз һәм мәдәниятләрне берләштерәбез**

ЭМИЗ

Банкетлар
Китерү
Кейтеринг

8 (843) 245 00 55 | Татарстан Республикасы, Казан ш., Сафиуллин ур., 29

*Тәкъдим 2025 елның 1 мартыннан гамәлгә керә

ЭМИЗ: йөземнең бар көче һәм файдасы – һәр йотымда

Премиаль сыйфат һәм кабатланмас тәм

ЛАУРЕАТ 2023 СТО ЛУЧШИХ ТОВАРОВ РОССИИ КОНКУРСА
2023 ЛУЧШИЕ ТОВАРЫ И УСЛУГИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
100% ECO PRODUCT
NATURAL 100%
HALAL

emiz.ru
8 800 444 09 37

РЕКЛАМА

ИҢ МӨҺИМЕ – СӘЛАМӘТЛЕККӘ ФАЙДАСЫ БУЛСЫН

Яшьлек һәм сәламәтлек эликсиры. ЭМИЗ компаниясенең табигый эчемлекләрен әнә шулай атыйлар. Юкка гына түгел: алар җитештерелә башлаган алты ел эчендә оешма «Хәләл» сертификатын алуга ирешә, «Россиянең иң яхшы 100 товары» бәйгесендә җиңү яулады, полифеноллар булган файдалы эчемлекләр арасында чемпион дәрәҗәсенә ия дип табылды. Сихәтле эчемлекнең серләрен безгә дә ачуын үтенеп, ЭМИЗ компанияләре төркеменә нигез салучы һәм аның җитәкчесе, Татарстанда гына түгел, ә Россия күләмендә дә иң эре хәләл-үзәкләрнең хуҗасы Раил Фазылҗановка мөрәҗәгать иттек.

– Раил Наилович, ЭМИЗ идеясе каян барлыкка килде? Мондый эчемлекне сезгә кадәр җир йөзендә берәү дә җитештермәгән бит...

– Беләсезме, шундый бер мәзәк бар. Бервакыт арыслан үзенең патшалыгында яшәүче җан ияләрен тирән чокыр янына җыеп алган, ди. Һәм вәгъдә иткән: кем чокырны сикереп уза ала, шуңа ярты патшалыгын бирәчәк, теләсә нинди хыялын үтәячәк. Ике көн буена берәү дә сикерергә җөрьәт итмичә таптанган, ә өченче көнгә бер тәвәккәле табылган. Кем дисезме? Керпе икән! Сикереп чыккан бит бу керпе! Барысы да шаккаткан! Арыслан моңа ярты патшалыгын биргән дә сорый, ди: «Йә, хыялың нинди, керпе?» «Туктале, – дигән моңа җавапка керпе, – әйдә, башта мине тибеп очырган җанварны табабыз!»

Минем белән дә хәлләр шушы керпенекедәй килеп чыкты. Җиде ел элек безне Кырымга чакырдылар – мин ул чакта төзелеш тармагында эшли идем. Партнёрыбыз эш тә вәгъдә итте, яхшы акчалар да. Тегесен дә, монысын да күрмәдек, ахыр чиктә. Югыйсә, үз акчаларыбызны ул проектка керткән идек. Әмма ул безне Кырымның икенче бер кешесе белән таныштырды, әйтүе буенча, ул гаҗәеп эчемлек уйлап тапкан. Безгә бу идея бик ошады. Аңа җитештерүне эшләтеп җибәрү өчен алты миллион акча кучердек. Тик ул акчаны алды да юкка чыкты! Озакламый без бу «новатор»ның тагын бер корбаны белән очраштык. Әлеге дә баягы зыян күрүчебез рецепт буенча эчемлекне ясап караганын әйтте. Теләсәгез, ди, сезгә аны миллион ярымга сата алам. Инде чигенергә юл калмады, акчалар бу проектка кертелгән бит: кул бирештек тә тәвәккәлләдек. Моның белән генә бетмәде әле кыенлыклар, ләкин шунысы хак: өч айдан соң без буяулар, шикәр, лимон кислотасы кушмыйча гына йөзем төшләреннән һәм җимешнең итләч тышчасыннан 100 процентлы табигый продукт җитештерә башладык. Хәзер инде мин моны Аллаһның безгә бүләге итеп кабул итәм – чигенмәдек, эшне җиренә җиткердек бит барыбер.

– Ни өчен ЭМИЗны яшьлек һәм матурлык эликсиры дип атыйсыз?

– Аның сере бик гади: без йөзем төшеннән һәм тышчасыннан барлык файдалы элементларны суырып алабыз. Алар йөрәк-кан тамырлары системасын нормальләштерә, кешенең оргнизмына тулаем бик уңай йогынты ясый. ЭМИЗ өчен бары тик Кырым йөземе генә туры килә, аның да – сайлап алынган сортлары. ЭМИЗ бары тик табигый составтан гына тора: йөзем төше, тышчасы, итләч эчлеге һәм согы. Без йөземнең төрле өлешләрен кушып, аннан соң артып калган суны парга әйләндерәбез. Полифеноллар – ЭМИЗ ның иң зур кыйммәте. Аңарда 360 төре бар!

– Сез конкуренция сизәсезме?

– Безнең төп принцип – кешеләргә файда китерү. ЭМИЗның һәр шешәсендә – өч-дүрт килограмм йөзем! Сәламәтлек өчен файдасы булу – беренче урында. Тагын әле без үз алдыбызга бик әһәмиятле, югары максат куябыз – җир шарында яшәгән бер миллиард кешегә файда китерү. Бүгенге базарда баллы эчемлекләр хәйран күп. «Шикәрсез» дигән маркировкага карамастан, күбесе җитештерү вакытында шикәр куллана. Ә бит андый эчемлекләрне белмичә куллану алга таба сәламәтлек белән һәртөрле проблемаларга китереп чыгарырга мөмкин.

– «ЭМИЗ» гастрономия мәйданын ни өчен һәм кем өчен ачтыгыз?

– Гастрономия мәйданы – хатыным Рамиләнең идеясе. Ул күптәннән клиентлар белән кунакларны тәмле итеп сыйлый торган ресторан хакында хыяллана иде. 1 500 квадрат метр, ике банкет залы. Бүгенге көндә бу – Татарстандагы иң эре хәләл-үзәк. Банкет залында без, 400 кешене тәэмин итеп, күпсанлы чаралар, хәтта конференцияләр дә уздырабыз. Һәр өстәлдә – бүләккә ЭМИЗ.

Беренче катта – 70 урын, озакламый VIP-зал ачарга ниятләп торабыз. Бу мәйданда без шулай ук ЭМИЗны дөрес итеп кулланырга да өйрәтәбез. Ул ашкайнату системасына бик яхшы тәэсир итә. Омтылышларыбыз үз нәтиҗәсен дә бирә – берничә ай эчендә кунакларның кире элемтәсе буенча бик югары рейтингка ирешә алдык.

Сүз уңаеннан, безнең командада Жизель Мәһдиева эшли. Ул – бренд-шеф, «Сәнгать – десертка» китабының авторы. Мишлен рестораннарында эшләү тәҗрибәсе бар. Әгәр сез аның берәр десертын татып карасагыз, башка төрләреннән бөтенләйгә баш тартачаксыз. Асылда, безнең ризык-нигъмәтләребез Казанның теләсә кайсы башка кыйммәтле рестораннарныкы белән «бил тота алырдай». «Хәләл» дигән сүз әле ул өчпочмак, бәлеш һәм токмач ашы белән генә төгәлләнми бит. Бездә тәмле дә, ризык ягыннан төрлелек тә хөкем сөрә, матур-ямьле дә!

Күптән түгел генә кейтеринг хезмәтен ачтык. Бер кешегә 600 сум исәбеннән бренд-шеф әзерләгән кабымлыкларны тәкъдим итәбез. Барысы да – Европа стандартына тәңгәл. Әле тагын шуңа өстәп, ЭМИЗ да биреп җибәрәбез. Монысы инде – традиция.

Заказларны кабул итү телефоннары:
8 800 444 09 37
8 9872 90 60 40 – банкетлар
8 843 245 00 55 – кейтеринг

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Рек

WWW.PROTATARSTAN.RU

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Төрле чорларда солдатлар туган илне **ничек** саклаган

Махсус хәрби операциядәге сугышчылар **нинди** җырларны яратып тыңлый

Фән безне **нәрсә** белән шаккатырырга сәләтле

«Татарстан» журналының махсус проекты

ҺӘР ЗАМАННЫҢ ҮЗ ГЕРОЕ

Ватан, ил, туган як – әлеге төшенчәләрнең мәгънәләре бик тирән, һәм ул ниндидер территорияләрне генә күздә тотмый. Бу – безнең якын кешеләребез дә. Ата-бабаларыбыз безгә мирас итеп тапшырган һәм без балаларыбызга тапшырырга тиешле белемнәр дә. Безнең традицияләр һәм мәдәни кыйммәтләр дә. Вакыт-вакыт боларның барысын да дошманнардан, дөрес булмаган уйдырмалардан, тарихыбызны яңадан күчереп язарга теләүчеләрдән яисә хәтеребезне саектырырга омтылучылардан сакларга туры килә.

«Татарстан» журналының махсус проекты – Ватанны саклаган һәм саклаучы кешеләр турында. Төрле заманнарда безне саклаучылар һәм яклаучылар турында. Кайберләре инде арабызда күптәннән юк. Әмма алар күрсәткән батырлык үрнәкләре, аларның куркусызлыгы, кыюлыгы һәм тәвәккәллеге һәрвакыт безнең хәтердә һәм «Татарстан» журналы битләрендә дә сакланачак.

Фото: tatar-inform

Бүгенге тарихлар:

1. **2022 ел.** Кече сержант Павленков баштанаяк коралланган 58 кешене ничек туктаткан.

2. **2016 ел.** Капитан Әхмәтшин ничек берүзе дошманга каршы торган.

3. **1979–1989 еллар.** Рядовой Ишмөхәммәтов, лейтенант Степанов һәм сержант Кондратьев ничек... бакыр сынга әверелгән.

4. **1942 ел.** Семён Коноваловның «КВ-1» экипажы ничек берүзе 16 фашист танкын юкка чыгарган.

5. **1807 ел.** Кавалерист кыз Надежда Дурова ничек «Батырлык өчен» бүләгенә лаек булган.

редакция кухнясы

РЕДАКЦИЯ РӘХМӘТЕН БЕЛДЕРӘ:

«БЕСЕДКА» ИҖАТ СТУДИЯСЕ
@STUDIO_BESEDKA
Әпсәләмов ур., 19
+7 (843) 221-03-73
www.studiobesedka.ru

«ВОЕНТОРГ КАЗАНЬ» КИБЕТЕ
Мы работаем для Вас!!!
@VOENTORG_KZN
Мәскәү ур., 23/24
+7 (917) 268-06-77
Пн – Пт 9:00–18:00.Сб 9:00 – 17:00. Вс 9:00 – 15:00

«ЦЕНИМ ЖИЗНЬ» АКБХО
Консолидация групп для поддержки военнослужащих, находящихся в зоне проведения СВО
@CENIM_ZHIZN
Мәскәү ур., 15, оф. 223
+7 (927) 481-90-37
+7 (939) 365-07-19

Фото: Ната Смирнова. РЕКЛАМА

ВАТАННЫ САКЛАУЧЫДАН ТӘМЛЕ АШ

Татьяна Вафина

Бүген «Татарстан»ның редакция кухнясы» хәзерге вакытта Ватанны саклаучылар һәм киләчәктә сакларга җыенучылардан гөрләп тора. Сугышчы Владимир Павленков хатыны Чулпан, шулай ук булачак суворовчылар Константин һәм Кирилл белән бергә тайча том-ям әзерли. Чөнки алар аны бик ярата икән.

ГЕРОЙ ГАИЛӘСЕ

– Мин гомумән ашарга пешерергә бик яратам, – ди, махсус хәрби операциядә катнашып, каты яраланудан соң өенә кайткан Владимир Павленков. – Костя – пилмән, ә Кирюня, әнисе кебек үк, балык ярата. Пилмәнне үзебез ясыйбыз, балыкны да үзем тотам.

– Ул безнең һәвәскәр балыкчы, – дип аңлата Чулпан. – Татарстанга – Атабайга, Кама Тамагына – балык тотарга әле бирегә күченгәнче үк килә торган булган. Ә үзе Мәскәүдән ул.

Махсус хәрби операция героеның бөтен гаиләсе, алъяпкычларын ябып, эшкә керешә: малайлар гөмбә, черри помидорларын турый, Владимир әче чили борычын ваклый, Чулпан инде кәстрүл янында мәш килә... Шундый газиз гаилә идиллиясе.

СОЛДАТ АЧТАН ҮЛМӘС!

Үзенең нәрсә ашарга яратуын сорагач, Владимир сугыштан соң бөтен нәрсәне ашый алуын яшерми. Ә сугышта…

– Фронтта солдатлар нәрсә ашыймы? – дип башлый ул сүзен. – Тушенка, дөге, карабодай. Дөге салынган капчыкны тычкан теткәләвен күрсәк тә, нишлисең, юдык һәм ашадык инде. Күлләвектән су да эчәргә туры килде: камалышта яки ут астында калганда, миномет туктамыйча эшли, су юк, шешәле суны ташырга бернинди мөмкинлек юк, ә эчәсе килә. Кыскасы, җырда җырланганча, «Солдат ачтан үлмәс!»

ЯУДА ДЕСАНТЧЫГА ТАЯНЫРГА БУЛА

Махсус хәрби операциягә Владимир мобилизациянең беренче көнендә эләккән. Үзе килгән, үзе язылган, үзе сугышка киткән – һәм бернәрсәгә

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

Тавык шулпасы – 1,6 л;
Креветка – 400 г;
Лемонграсс сабагы – 6 данә;
Шалот суганы – 12 данә;
Черри помидоры – 2 ботак;
Чили борычы – тәменчә;
Шампиньон гөмбәсе – 6 данә;
Каффир-лайм яфрагы – 2 данә;
Тоз – тәменчә;
Кинза – 5-6 ботак;
Лайм согы – 6 аш кашыгы;
Дөге – 400 г.

дә үкенми. Чөнки ул – десантчы. Ә десантчылар үз илен бәладә ташламый.

Тыныч тормышта десантчының һөнәре шулай ук куркыныч була – ул сәнәгать альпинизмы белән шөгыльләнә, бик биектә кондиционерлар урнаштыра.

– Сез буйсындырган иң биек кат?

– 58 нче кебек истә калган... Алай санаганым булмады да кебек, – ди безнең альпинист.

– Кыю, куркусыз кеше сез!

– Куркусыз кеше бернәрсәдән дә курыкмый торган түгел, бәлки үз куркуын җиңә торган кеше ул. Бу безнең десанттагы командирыбыз Василий Филиппович Маркелов сүзләре. Мин аларны һәрвакыт исемдә тотам, – ди Владимир. – Ахмак кына бернидән дә курыкмый бит.

ТИМЕРМЕ, МОДМЫ?

– Ә сезнең позывноегыз нинди?

– Мод.

– Мод нәрсәне аңлата?

– Бөтенләй диярлек тимердән мин – җәрәхәтләрдән соң тәнемдә тимер бик күп, – дип көлә Мод.

– Андыйларны безнең Татарстанда тимер дип атыйлар.

– Мод – модернизацияләнгән дигән сүз ул! – дип, малайлар икесе бергә аңлатырга ашыга.

– Алар яхшырак белә шул, – ди сугышчы, үсеп килүче буынга ымлап.

БАТЫРЛЫК ӨЧЕН

Үсеп килүче буын инде, ихластан горурланып, безгә «Батырлык өчен» медален күрсәтә. Медальне күргәннән һәм Владимирның сугыш турында

Владимир күрсәткән батырлыкка килсәк, алар иптәше белән икәү баштанаяк коралланган 58 кешене туктаткан.

хикәятләрен тыңлаганнан соң, Костя һәм Кирилл үзләренең булачак һөнәрен сайлаган – алар әтиләре кебек хәрби булырга тели һәм Суворов училищесына укырга керергә җыена. Документларын тапшырганнар да инде.

Ә Владимир күрсәткән батырлыкка килсәк, алар иптәше белән икәү баштанаяк коралланган 58 кешене туктаткан. Туктатып кына калмаганнар, ярдәм килеп җиткәнче үк икәүләп бөтен колоннаны коралсызландырганнар да.

Медаль үз героен соңрак, сугыш кырында тапкан дияргә була – аны Луганск Халык Республикасы авылларының берсендә бүләкләгәннәр.

Аннары спецназга ярдәм өчен бүләк килеп җиткән – Владимир аларны хәрби бурычларын үтәгән вакытта ут яудырып каплап торган. Ә гомумән, МХОда хезмәт иткән вакытта ул мотоукчылар дивизиясендә дә, диңгез пехотасында да, спецназда да булырга өлгергән...

ГЕНЕРАЛ БУЛАЧАКБЫЗ!

– Балалар компьютерда гына атышкан һәм шуңа бернинди физик активлык калмаган заманда сез улларыгызны хәрби һөнәр белән ничек мавыктыра алдыгыз?

– Без үзебез телибез! – дип, икәү бергә аваз сала малайлар.

– Бу аларның үзләренең теләге. Алар спорт белән көн саен шөгыльләнә: турникта тартылалар, планкада торалар, стадионда йөгерәләр, җиңел атлетика белән шөгыльләнәләр... Мәктәптә яхшы укыйлар – күп кенә олимпиадада җиңүче һәм призёрлар. Югары состав офицерлары булырга хыялланалар.

– Генерал булачакбыз! – дип, тагын икәү бергә җавапка төгәллек кертә Кирилл белән Константин.

– Ә сез үзегез балачакта нәрсә белән шөгыльләндегез?

– Спорт бал биюләре белән, – дип гаҗәпләндерә Владимир. – Әйе! Бервакыт Саклык банкы кубогында өченче урын алдым. Тагын кёкусинкай

– Шул кичне үк видеоэлемтә аша Чулпанның әнисенә шалтыраттык, – дип дәвам итә Володя. – Һәм мин әйтәм: «Әни, мин сезнең кызыгызга өйләнәм!» – дим.

карате белән дә шөгыльләндем һәм һава десанты гаскәрләрендә хезмәт итәргә әзерләндем, чөнки тренерым Владимир Германович Володин десантчы иде. Ул физик әзерлеккә, патриотик тәрбиягә зур игътибар бирде. Мин аңа моның өчен бик рәхмәтлемен.

ТЫНЫЧ ТОРМЫШТА

Яу кырында авыр яраланганнан соң тернәкләнү тыныч тормышта барырга тиеш. Вакытны әрәм итмәс өчен, Владимир пединститутка укырга кергән. Укытучы белгечлеге ала. Дистанцион рәвештә. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга мондый мөмкинлекне «Ватанны саклаучылар фонды» белән берлектә «Синергия» институты бирә.

Костя белән Кириллның безнең бүгенге ашчыбызга ничек сокланып каравын, аның «кулинария командаларын» бик тырышып үтәвен күреп, гереобызның педагогикада да һичшиксез уңышка ирешәчәгенә шигебез калмый.

ИҢ КУРКЫНЫЧЫ

– Сугышта иң куркынычы нәрсә?

– Дусларны югалту, – ди Владимир. – Иң якын ике кешемне югалттым – алар белән мин баштан үк, мобилизациянең беренче көненнән үк, дус идем.

Без легендар Кантемиров дивизиясенә эләктек. Анда бер яхшы кеше – Малой позывнойлы егет белән дуслаштым. Ул 2023 елда һәлак булды. Һәм тагын минем якын дустым Буня бар иде – ул башта «Вагнер»да, аннары «Невский»да хезмәт итте. Буня биш тапкыр яраланды, дәвалангач, тагын кире кайта иде. Әмма, кызганыч, ул да 2023 елда һәлак булды...

Ә болай кеше бөтен нәрсәгә ияләшә. Һәм син кая барганыңны, анда сине нәрсә көткәнен беләсең икән, инде моңа әзер буласың.

«ПОГОНЛЫ АПА БУЛАСЫМ КИЛӘ!»

– Чулпан, гаиләдәге шулкадәр хәрби ир-ат белән кыенмы сиңа?

– Бик җиңел. Мин үзем дә элек эчке эшләр хезмәтенең өлкән сержанты идем. Хәрби һөнәргә балачактан ук кызыктым. Минем бабам Хәрби Һава Көчләре капитаны бит. Хәтерлим әле, без аның белән хәрби госпитальгә барган идек. Анда мин полковник погоннары таккан зифа буйлы матур бер апаны күрдем. Һәм үземнең дә шундый буласым килде. Махсус белем алгач, дүрт ел диярлек погон тагып йөрдем. Башта хәрби частьта идем, ә аннары Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтендә – Түбән Камада ирләр колониясен сакладым, автомат белән вышкада басып тордым.

2006 елда үз бизнесыма киттем. Хәзер безнең гаиләнең Мәскәүдә һәм Казанда кунак апартаментлары челтәре бар. Һәм тагын «Чулпан Павленкованың хәйрия фонды». Волонтерлар буларак, Володяның фронттан кайткан иптәшләренә ярдәм итәргә тырышабыз. Гуманитар ярдәм илтәбез, инвалидлыкны рәсмиләштерергә, социаль яклау пакетына документлар тупларга булышабыз. Мин үзем белемем буенча юрист, һәм сугышчыларга түләүсез ярдәм итәм.

Шушы көннәрдә Санкт-Петербургка госпитальгә бардык, анда Владимирның дуслары ята.

– Һәм тагын: гаиләдәге һәр кешенең хыялы тормышка ашсын өчен, барысын да эшләргә кирәк, – ди Чулпан.

Кирәкле әйберләрен илттек, чөнки аларның анда элементар киемнәре дә юк бит. Яраланганнан соң канлы һәм ертык кием кеше өстендә килеш кисеп алына һәм ташлана. Ә монда Ерак Көнчыгыштан килгән егетләр ята, туганнары андый еракка барып җитмәячәк. Кемнеңдер туганнары да юк. Шуңа күрә ярдәм итәргә кирәк.

ТУГАН КӨН БҮЛӘГЕ

Башкаларга булышканда, Чулпан үзенең мәхәббәтен тапкан. Бу чын әкияти тарих, ул бары тик игелекле һәм ярдәмчел кешеләр белән генә була ала.

– Ә тагын матур татар хатын-кызлары белән, – дип өсти Владимир.

– Бервакыт Костя минем яныма килде дә кочаклап елап җибәрде: «Әни, безне яратачак чын әтиебез кайчан табылыр инде?» – дип сорады.

– Минем үземнең дә күзләрем яшьләнде, – дип башлады әкиятен Чулпан. – Бу октябрь ае иде. Ә өченче декабрьдә без Екатеринбургтагы госпитальдә Вова белән таныштык. Минем улларымның туган көне исә дүртенче декабрьдә. Өйгә кайткач: «Балалар, сезнең әтиегез табылды!» – дип сөендердем.

Туган көнгә менә шундый бүләк булды.

Хастаханәдә үк каршыма тезләнеп, кияүгә чыгуымны сорады. Әкияттәгедәй рәхәт булды.

– Шул кичне үк видеоэлемтә аша Чулпанның әнисенә шалтыраттык, – дип дәвам итә Володя. – Һәм мин әйтәм: «Әни, мин сезнең кызыгызга өйләнәм!» – дим.

– Ә үзенең күз төбе күгәргән! – дип көлә Чулпан. – Ул госпитальдә шәфкать туташларын рәнҗеткән ниндидер наркоман белән сугышкан иде. Әмма әни бу турыда белми бит, мондый кыяфәттәге кияүне күреп гаҗәпкә калды.

Никах укыганда, бу «матурлыкка» тональ крем ягарга туры килде...

АЛЫРГА КИРӘК!

– Ә сез, Владимир, бу шаян кызга ничек гашыйк булдыгыз?

– Шаян, сөйкемле, намуслы, – дип санап китә Владимир үз хатынының күркәм сыйфатларын. – Аңардан яхшылык бөркелә. Ул чын. Аралашуда гади.

Мин аны күрүгә, телсез калдым – шундый чибәр! Алырга кирәк! Өстәвенә, гомерем буе тормышымны Казан белән бәйләргә хыялландым – бу шәһәр миңа бик ошый иде. Без егетләр белән бергә еш килә, Кама Тамагында икешәр атна яши, балык тота идек. Ягъни мин җирле флора-фауна белән таныш идем инде, һәм ул миңа бик ошый иде. Әйтсәм әйтим инде – мин татар кызына өйләнү турында хыялландым...

Чулпан дәвам итә:

– Танышып, исемемне әйткәч, ул шундук: «Татар кызымы әллә?» – дип сорады. «Әйе!» – дидем. Ә ул: «Кит аннан! Син минеке булачаксың!» – димәсенме?! Бөтен госпитальгә, күз алдына китерәсезме?!

Кыскасы, чибәр Мәскәү егете чибәр Казан кызына гашыйк та була, өйләнә дә, ислам диненә дә кабул итә, Казанга да күченә. Авыр яраланудан соң сихәтләнә дә башлый. Кыскасы, исән кала. «Как я выжил, будем знать только мы с тобой...» дигән юллар Владимир белән Чулпан турында да.

Менә бит тормышта ничек тә була!

БЕРГӘ БУЛУ БӘХЕТЕ

– Сез инде икенче ел бергә. Сезнең гаилә бәхетенең ниндидер шәхси сере бармы?

– Намуслылык, ачыклык, үзара аңлашу. Үткәндәге хаталар тәҗрибәсе дә – аларны ясарга ярамавын инде яхшы беләбез, – ди Чулпан.

– Зур гаилә булуы инде үзе бәхет. Минем һәрвакыт зур гаиләле буласым килә иде, – дип өсти Владимир.

«Герой гаиләсе» һәм «Батырлык өчен» медальләрен Чулпанга Мәскәүдә тапшыралар.

– Һәм тагын: гаиләдәге һәр кешенең хыялы тормышка ашсын өчен, барысын да эшләргә кирәк, – ди Чулпан. – Вованың дустының көймәсе бар иде – алар бергәләп балык тотарга йөрделәр. Хәзер исә аңа көймәсез бик кыен. Шуңа без аның хыялын тормышка ашырырга булдык – акча тупладык та катер сатып алдык. Дөрес, әлегә моторсыз – анисына акча җитмәде.

– Чулпан бу катерны Питердагы заводтан прицепка төяп үзе алып кайтты! Күз алдына китерәсезме?! – дип сокланып сөйли Владимир.

– Балыкчы хыялын тормышка ашырдым, – дип елмая Чулпан. – Ул бит сугышка кадәр балаларны балык тотарга өйрәткән. Аның дустының әнисе, ул күлләвектән дә балык тота ала, ди.

– Күлләвектә аңа катер нигә кирәк соң?

– Атабайда, Кама Тамагында, Куйбышев сусаклагычында һәм Иделдә катер белән тотарбыз, – дип көлә Владимир. – Мавыгуым һөнәргә дә әйләнер әле. Мин 2017 елда Атабайда 7 килограммлы сыла балыгы – судак тоттым! Уылдыклыны! Көймәдә гаиләбез белән сәяхәт итәчәкбез – Татарстан буенча, ил буенча. Яшьләрне балык тотарга да, туган иленне яратырга да өйрәтергә кирәк, – дип, ул булачак генераллар Кирилл белән Константинны иңнәреннән кочып ала.

– Әти, ашыйсы килә! – ди генераллар.

Һәм бөтен гаилә зур табын тирәли утыра, ә анда инде Ватанны саклаучы рецепты буенча әзерләнгән тәмле тайча том-ям ашы салынган тәлинкәләр, хуш ис бөркеп, тизрәк авыз итүне көтә.

1 Агызабыз

2 Турыйбыз

3 Ваклыйбыз

4 Ваклыйбыз

5 Кисәбез

6 Чистартабыз

7 Салабыз

8 Өстибез

9 Пешерәбез

– Яшьләрне балык тотарга да, туган иленне яратырга да өйрәтергә кирәк, – дип, ул булачак генераллар Кирилл белән Константинны иңнәреннән кочып ала.

ГЕРОЙЛАР ҮЛМИ!

Руфия Фазылова

Сүрия. Сугыш кыры. Җирдән пыскып кара төтен күтәрелә. Һавада дары исе генә... Капитан Марат Әхмәтшин яу кырында берүзе кан эчендә ята. Ул җитәкләгән полк солдатлары, дошманнан куркып, артка чигенә. Ә тәҗрибәле капитан соңгы сулышына кадәр үз-үзенә, биргән антына хыянәт итми.

КУЛДА ГРАНАТА...

Сүриядә капитан Әхмәтшин җитәкләгән полкка экстремистлар һөҗүм итә. Бу урында шунысын да әйтим: Маратның үлеме турында шактый яздылар. Әлбәттә, Сүриянең Пальмира шәһәре янында барган ул яуданиләр булганын хәзер төгәл генә берәү дә әйтә алмый. Хәрби сер дигән әйбер дә бар бит. Әмма, шунысы хак – капитан Әхмәтшин ДАИШның (Россиядә тыелган террорчылар оешмасы) 200 сугышчысына каршы берүзе тора. Аның полкындагы Сүрия солдатлары һөҗүмнән куркып артка чигенә. Гади генә итеп әйткәндә, качалар. Ә полк командиры артка чигенми: соңгы чиккә кадәр дошманына ата. Нәтиҗәдә, үзе дә каты итеп яралана. Иптәшләре атыш тавышына килеп җиткәндә, капитан Әхмәтшин кан эчендә ята. Ә кулында – чекасы алынган граната. Әхмәтшин, бернигә дә карамастан, дошманга бирелергә уйламаган...

Ни аяныч, Марат һөҗүм вакытында өч литрлап канын югалта, хәрбинең гомерен саклап кала алмыйлар. Шулай итеп 36 яшен генә тутырып килгән геройны бик зурлап туган ягы – Татарстанга алып кайтып җирлиләр.

АРТИЛЛЕРИСТ. ӨЧЕНЧЕ БУЫН ХӘРБИ

Марат Әхмәтшин мәктәптә дә, артиллерия училищесында да яхшы укый. Шуннан юллама белән Төньяк Кавказга китә. Кайткач, йөргән кызы Гүзәл белән гөрләтеп туй итәләр. Гаилә башлыгын Кабарда-Балкар Республикасындагы Прохладный шәһәренә җибәрәләр. Ике балалары туа. Ул арада Марат Әхмәтшин кайнар нокталарга да барып кайтырга өлгерә...

Капитан дәрәҗәсенә ирешкән Маратның хезмәт иткән полкы таркала. Һәм ир белән хатын туган ягына – Казанга күченеп кайта. Марат транспорт оешмасына инженер булып урнаша, аннары йөк машиналары ширкәтенә күчә. Тагын бер кызлары туа. Тик хәрби кеше «тыныч» тормышка ияләнә алмый, гарнизонда яшәгән вакытларын сагына. Һәм... якыннары белән киңәшләшкәннән соң, яңадан хәрби хезмәткә әйләнеп кайта. (Лаеклы ялга китәргә өч ел вакыт калган була.) Барып гариза яза, медицина тикшерүе уза. Капитан Әхмәтшинны Түбән Новгородка билгелиләр. Берничә ай хезмәт иткәннән соң, Марат гаиләсен дә алып китәргә тиеш була. Тик...

– Улыбыз 2016 елның апрель уртасында Сүриягә китте, – дип, ул вакытларны искә алды Россия Героеның әтисе Радик Әхмәтшин. – Дөрес, безгә дә, хатынына да бу хакта башта әйтмәде. Шомлы командировка турында соңрак кына белдек. Разведка җитәкчесе итеп җибәргәннәр үзен. «Әти, син мине аңларга тиеш. Хәрби заданиене үтәмәскә хакым юк», – диде ул. Марат беренче июнь көнне гаиләсенә шалтыраткан. Кешеләр аң-

Фотолар гаилә архивыннан алынды

ламасын, дип, хатыны белән татарча сөйләшкән. Кайтырга күп калмады, борчылмагыз, дигән. Ә инде өченче июньдә аның гомере өзелгән...

ОЧУЧЫ. ИКЕНЧЕ БУЫН ХӘРБИ

Марат Әхмәтшин артиллерия училищесын юкка гына сайламаган. Әтисе Радик, бабасы Вәгыйзь Әхмәтшин да ил сагында торган кешеләр. Шуның өчен егетнең хәрби һөнәр сайлавы атаана өчен гаҗәп булмаган. Алай гына да түгел, улының ни сәбәпле Сүриягә киткәнен ата кеше ихластан аңлый һәм хуплый. Дөрес, геройның әнисе Римма ханым һаман да улын югалту белән килешә алмый. Еламаган бер көне юк икән...

Радик абый – очучы, Ставрополь хәрби училищесын тәмамлаган. Бу хакта сөйләргә ярата ул:

– Безнең әти диңгез флотында хезмәт иткән. Шуңа да минем диңгезче булуымны теләде. Ә мин кечкенәдән очкычлар белән җенләндем. Хәтерлим, бакчага шома таяк утыртып куеп, шуңа кул белән тотынып, уң якка йөз, сул якка йөз тапкыр әйләнә идем. Шул рәвешле үземне очучы булырга әзерләдем. Турникта тартылу, йөгерү, йөзү – барысы да булды.

Радик абыйның балачак хыялы тормышка ашкан: очучы-истребитель булып хезмәт иткән. СССРның чик буйларын саклаган. Күктә бер кош та очырмый, диләр бит, бу нәкъ менә шул очрак. Җирдәге локаторлар чик буенда нинди дер ят әйбер, техника күреп алса, очучыга команда җибәрә. Хәрби очучы, дүрт минут эчендә җыенып, самолетына утырып, күккә күтәрелергә тиеш.

– Дөнья буйлап күп йөрелде, – дип дәвам итте Радик Әхмәтшин. – Хатыныма рәхмәт, гел миңа терәк булды. Приморье краеның Владивосток шәһәре, Камчатка, Ленинград... Кайда гына яшәмәдек. Әллә ни күп тә хезмәт итмәдем кебек – 1972 елда училище тәмамлап, очкычка утырдым. Һәм 1986 елга кадәр хезмәттә булдым. Аннан лаеклы ялга киттем. Без эшләгән чорда гади очучылар 25 ел эшләде. Ә хәрби очучылар аерым статуста йөрде, бер елыбыз икегә исәпләнде. Шуңа да 36 яшемдә инде лаеклы ялга киттем. Аннан соң гаиләм белән Казанга күченеп кайттык. Акрынлап туган авылым Атабайда зур йорт төзедек. Балалар да булышты.

– Радик абый, тормышыгызны куркыныч астына куйган чакларыгыз булдымы? – дим.

– Техник сәбәпләр аркасында, берничә тапкыр гадәттән тыш хәл килеп чыкты – андый чакта тиз генә җиргә төшү ягын карыйсың. Мәҗбүри рәвештә шулай очкычны җиргә утырттым. Ә болай, Аллага шөкер, мин хезмәт иткән чорда сугышлар булмады. Тыныч чакка туры килдек без.

Очучы булудан туктагач та, Радик Әхмәтшин самолетлар тирәсендә эшләгән – 26 ел Казан аэропортында диспетчер булып хезмәт куйган.

ДИҢГЕЗ ОФИЦЕРЫ. ДИНАСТИЯДӘ ИҢ ӨЛКӘНЕ

Вәгыйзь Әхмәтшин исә диңгез офицеры булган. Бөек Ватан сугышы барганда диңгезче булып хезмәт иткән. Аннан соң аларны япон сугышына җибәргәннәр.

– Әтием күптән мәрхүм инде, – диде Радик абый. – Аз сүзле кеше иде ул. Аеруча сугыш темасына кагылырга яратмады. Шулай да аерым очраклар турында беләм: 1947 елда, сугыш вакытындагы миналарны юк итеп йөргәндә, мина кыйпылчыклары эләгеп, аларның корабльләре икегә аерыла. Әти шунда контузия ала. Исән калган хәрбиләр су өстенә йөзеп чыга. Океан уртасы. Контузияле килеш әти өч сәгатьләп йөзеп йөри. Арттан йөзеп килгән корабль аларны коткара. Контузия алу сәбәпле, Вәгыйзь Әхмәтшинны туган ягына кайтарып җибәрәләр. Биш еллап диңгез, океаннарда йөзгән егет Атабайга кайтып гаилә кора. Ир белән хатынның бер-бер артлы балалары туа.

– Әти батыр булган, – дип сүзен дәвам итте Радик абый. – Хезмәттән кайткач та, Иделдә суга бата башлаган берничә кешене коткарган. «Синең әтиең мине судан алып чыкты», – диләр иде.

Батыр нәселнең тарихы дәвам итә: Марат Әхмәтшинның олы кызы Зәринә Мәскәүдә Президент кадет корпусында белем алып, КФУның юридик факультетына кергән. Ә уртанчы улы Әмир Казан Суворов училищесын тәмамлый. Әтисеннән дүрт яшьлек булып калган Ралинә бишенче сыйныфта укый. Ул да хәрби һөнәр үзләштерергә хыяллана...

Аралаша торгач, тагын шунысы ачыкланды: Маратның әтисе кебек хәрби очучы буласы килгән икән. Тик Радик абый улын ул юлдан китмәскә күндергән. Радик абый бу сорауга җавапны төгәл белә:

– Куркыныч һөнәр дип санадым. Илдә чуалышлар башланган чак иде. Үзең өчен курыкмыйсың икән, ә менә бала өчен йөрәк өзелә. Тик улыбызны барыбер югалттык...

Башкаланың Осиново бистәсендә Марат Әхмәтшин урамы бар. Казанның ул укыган 113 нче татар-рус мәктәбе дә герой исемен йөртә. Лаеш районы Атабай урта мәктәбенә дә Марат Әхмәтшин исеме бирелгән.

Димәк, Геройның исеме мәңгелек!

Марат Әхмәтшин.

Отставкадагы хәрби очучы Радик Әхмәтшин.



Әнгам Ишмөхәммәтов.
«Урал»375Д машинасы.


Лейтенант Олег Степанов.
Шинданд шәһәре янында, 1980 ел.

Чик буе гаскәрләре сержанты
Вениамин Кондратьев. 1986 ел.

ҺӘЙКӘЛ БУЛЫП КАЛЫККАН ӘФГАНЧЫЛАР

Дмитрий Сивков

«Хәзер сине кем утыртсын? Һәйкәл ич син!» – дип шаярта дуслары һәм танышлары, Олег Степанов, Әнгам Ишмөхәммәтов һәм Вениамин Кондратьев белән сөйләшкәндә. Әфган сугышында катнашкан татарстанлыларга багышланган «Яудан соң» монументындагы командир, укчы һәм радист нәкъ менә аларга охшатып ясалган бит.

ТАТАРСТАННАН ӘФГАН СУГЫШЫНДА КАТНАШУЧЫЛАРГА БАГЫШЛАНГАН «ЯУДАН СОҢ» СКУЛЬПТУРА КОМПОЗИЦИЯСЕ ҖИҢҮ ПАРКЫНДА 2021 ЕЛНЫҢ 12 ИЮНЕНДӘ АЧЫЛДЫ. ПРОЕКТ АВТОРЫ – РОССИЯ ҺӘМ ТАТАРСТАН РӘССАМНАР БЕРЛЕКЛӘРЕ ӘГЪЗАСЫ АЛЕКСАНДР КИСЛОВ, АРХИТЕКТОРЛАРЫ ҺӘМ СКУЛЬПТОРЛАРЫ – ГЕРМАН БАКУЛИН ҺӘМ НИКИТА МАЗАЕВ.

КОМАНДИР, УКЧЫ ҺӘМ РАДИСТ СЫННАРЫННАН ГЫЙБАРӘТ БРОНЗА МОНУМЕНТНЫҢ БИЕКЛЕГЕ – 3,2 МЕТР (Ә АСТАГЫ ГРАНИТ ПЬЕДЕСТАЛЫ БЕЛӘН БЕРГӘ 4,5 МЕТР). СКУЛЬПТУРА ТӨРКЕМЕНӘ ДЕКАБРИСТЛАР УРАМЫННАН КҮЧЕРЕЛГӘН «СУГЫШ ҖИЛЕ» РЕКОНСТРУКЦИЯЛӘНГӘН ҺӘЙКӘЛЕ ҺӘМ ҺӘЛАК БУЛГАН 282 ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТ СУГЫШЧЫНЫҢ ИСЕМЕ ЯЗЫЛГАН 22 ГРАНИТ ПЛИТӘДӘН ТОРГАН МЕМОРИАЛЬ ГАЛЕРЕЯ ДА КЕРӘ.

Фото: vuslon.ru, автор фотолары, taradmin.ru

УКЧЫ

1984 елның 15 апреле. Бу көн Әнгам Ишмөхәммәтов хәтеренә гомерлеккә уелган. Беренчедән, бу аның туган көне, икенчедән, ул аның гомеренең соңгы көне дә була язып кала. Фейерверк урынына мөҗәһидләр ягыннан аңа таба утлы трассерлар оча, ә ул кузовында 80 әрҗә снаряд булган «Урал» машинасы астына яшеренеп атуын дәвам итә. Бер очраклы ядрә детонация китереп чыгарырга мөмкин, һәм ул чагында егеттән хәтта табутка салырлык көл дә калмас иде...

Башкортстандагы Октябрьский шәһәрендә туган бала бик иртә ятим кала. Аның тормыш мәктәбе интернат һәм балалар йортыннан башлана. Ятимлек сабакларын Әнгам яхшы үзләштерә – 18 яшенә инде Бөгелмәдә төзелеш техникумын тәмамлый һәм бокс буенча спорт мастерлыгына кандидат була. Мондый күрсәткечләр белән хәрби хезмәткә чакырылучыга СССР Хәрби Һава Көчләренең элитасы – һава-десант гаскәрләренә дә исәп тотарга мөмкин була, тик ДОСААФта укып, машина йөртү хокукы алгач, ул хәрби машина йөртүче итеп билгеләнә.

– 1982 елның апрелендә чакырылдык, яшь сугышчы курсын Тимертауда (Төньяк Казахстан) үттек, – дип сөйли Әнгам. – Анда безне Әфганстанга җибәрәчәкләрен ишеттек. Әфган икән, Әфган инде, башта әллә ни хафаланмадык та. Поезд белән Ташкентка барганда, безне озата баручы майор, бәлки, барыбыз да кире әйләнеп кайтмаячакбыз, диде. Менә шул вакытта эчкә курку керде. Хәтерлим әле, карантинда дуслашкан һәм бер купеда барган Александр Логинов белән күзгә-күз карашып алдык. Ул кайта алмады шул. Дембельгә ярты ел кала һәлак булды. Сугыш вакытында Саня, граната ыргытыр өчен, торып баса, шул вакытта иңбашына пуля тия, гранатасы кулыннан төшеп китә... Янәшәдәге командиры белән икесе дә һәлак була...

Әнгам 201 нче мотоукчылар дивизиясенең 395 нче полкындагы матди тәэминат һәм сугыш кирәк-яраклары ташу ротасында хезмәт итә. Дислокация урыны – Әфганстанның төньягындагы Пули-Хумри шәһәре. «Урал» 375Д машинасын йөртә, һәм аның номеры әлегә кадәр хәтерендә – 34-74 КХ. Баштарак операциягә чykканда артдивизионны озата бара, соңгы ярты елда исә разведрота белән йөри, аларга патроннар, гранаталар, БМП өчен снарядлар ташый. Ике ел һәм бер ай эчендә бөтен Төньяк Әфганстанны иңли – Кондыз, Фәйзабад, Мазари-Шәриф...

Шул вакыт эчендә, полкка килгәннең икенче көненнән башлап, әллә ничә тапкыр ут астына эләгә. Әмма үзенә 20 яшь тулган көн – аерым исәптә.

– 14 апрельдә Панджшер операциясе башланды, икенче көнне иртән, нәкъ минем туган көнемдә, без сугышка кердек. Засадага эләктек – дошман колонна башындагы техник хезмәт күрсәтү машинасына ут төртте, ә арттан газүткәргечне шартлатты. Без ике ут арасында калдык. Мин бер яшь егетне, хәзер исемен хәтерләмим инде, үземә алмашка әзерли идем. Машинадан сикереп төштек тә, кузов астына чумдык, мин аңа корырга дип патроннар һәм магазиннар тутырылган капчыкны ыргыттым да үзем дошманга ата башладым. Аннары: «Патрон бир!» – дип аңа таба борылган идем, аның кулы калтырый, магазинга патроннарны кертә алмый.

Әбиемнең, кеше туган көненә якынрак көндә үлә, дип әйткәне исемә төште, инде беттем, дип уйладым. Бервакыт сугыш кирәк-яраклары тутырылган машинаны шартлатканнар иде, аның кайбер кисәкләрен 300 метр ераклыктан таптылар – шул да күз алдымнан үтте... Әмма без засададан чыга алдык, – дип искә ала ветеран.

– 14 апрельдә Панджшер операциясе башланды, икенче көнне иртән, нәкъ минем туган көнемдә, без сугышка кердек, – дип искә ала Әнгам Ишмөхәммәтов.

Совет хәрби колоннасы таулар арасын кичә.

КОМАНДИР

Чәчәкләр. Әфганстанда сугыш башлану турында сүз чыкканда Олег Степановта нәкъ менә шундый ассоциация пәйда була. 1979 елның җәендә ул туган шәһәре Казанда танк училищесын тәмамлый. Аны Советлар Союзы картасындагы иң көньяк ноктада – Төрекмәнстан ССРның Кушка шәһәрендә урнашкан 371 нче гвардия мотоукчылар полкына танк взводы командиры итеп билгелиләр.

– 24 декабрьдә безне тревога буенча кузгаттылар һәм сугыш чоры штаты буенча тулыландыру өчен запас районга алып чыктылар. Сугышчылар санын да арттырдылар, матди-техник базаны да ныгыттылар: матрас, юрган, мендәрләр, ризык паеклары, патрон, граната, автоматлар... Танк чегән кибиткасын хәтерләтә иде. Чикне 28 декабрьдән 29 декабрьгә каршы төндә кичтек. Иртән инде Гератка кердек. Урамнарда халык күп иде, безне елмаеп сәламләделәр, танкка чәчәкләр ыргыттылар, бәйрәм кебек булды, – дип хатирәләре белән уртаклаша запастагы майор.

Бу таңда совет хәрбиләре өчен генә түгел, ә тулы бер ил өчен дә тормышның яңа этабы башлана.

– Безнең белән бергә әфганлылар да керде. УАЗикларда, барысы да битлектән, без аңлаганча, алар арасында Әфганстанның булачак җитәкчесе Бабрак Кармаль (без аны үзара Коля Бабраков дип йөртә идек) да бар иде, – дип елмая Олег Степанов.

Полк Герат провинциясенең Шинданд шәһәрендә урнаша, лейтенант Степанов Союзга кайтканчы ике ел чамасы вакытын шунда уздыра. Аның танк взводының төп бурычы СССРдан йөк төягән автомобиль колонналарын Әфганстанның үзәк өлешендәге Чагчаран шәһәренә кадәр озату була – бу 400 чакрым диярлек. Командирның күкрәгендәге Кызыл Йолдыз ордены танкистларның куелган бурычларны уңышлы үтәвенә дәлил булып тора.

– Минем Т-64 гадәттә колонна алдыннан бара, тагын берсе – уртада, өченчесе – артта. Миңа әле «сапёр» булырга да туры килде, өч тапкыр минада шартладым. Ярый әле сугыш башланганда мөҗәһидләрдә көнбатыш коралы юк иде. Миналар нигездә кулдан ясалган, шулай булгач, зур зыян китерми – чылбырны өзә, күчәрне кәкрәйтә... Ремонт күп вакыт алмый, тиз генә төзәтәсең дә – алга! – дип сөйли әңгәмәдәшебез.

Бервакыт танк сүнгән машинаны сакларга туктый. Аны ремонтлаган арада, колонна ераклаша. Йөк машинасы, төзәтелгәннән соң, үзенекеләрне куып тотарга ашыга. Танк артка кала. Елга буендагы кечкенә тарлавыктан су алырга туктыйлар. Моторны сүндермиләр. Командир белән төзәүче инде танкка кереп җитә язганда, аларга тау башыннан ут ачалар. Степанов машина йөртүче механикка: «Куала!» – ди, ә тегесе куркуыннан движокны сүндерә һәм кабыза алмый. Люклар ачык, ябарга дип башны чыгарып булмый – туктаусыз аталар. Ярый әле, дошманда ул чакта автоматлар юк, мылтыктан (кеше буеннан озынрак эре калибрлы винтовка) аталар. Аларны яхшы төзәп була, әмма пулялары – кургаш, йомшак, броняга үтеп керә алмый. Дөрес, бакларга да төзәп карыйлар, ярый әле, 15 минуттан моторны кабызып, кузгалып китәләр. Анда калу куркынычы да зур була. Мәңгегә.

Әмма хәтердә бары тик үлем куркынычы мизгелләре генә сакланмый, башка истәлекләр дә шактый.

– Гади әфганлыларның хәерчелеге таң калдыра иде. Бервакыт юлда бер картны узып киттек. Нindidер сәләмә киемнәрдән, яланаяк. Кире кайтканда, каршыбызга килә. Бардачокта яңа солдат ботинкалары ятуын исемә төшерәм. Тукгарга боерам. Танктан чыгам да, картка ботинкаларымны сузам. Сез аның күзләрен күрсәгез иде... Ул минем кулымны үбәргә әзер иде. Минем үземә дә уңайсыз булып китте, тиз генә танкка кереп утырдым да, китеп бардык, – дип сөйли элеккеге взвод командиры.

– Минем Т-64 гадәттә колонна алдыннан бара, тагын берсе – уртада, өченчесе – артта. Миңа әле «сапёр» булырга да туры килде, өч тапкыр минада шартладым, – дип сөйләде Олег Степанов.

Т-64 танкы блокпостта.

РАДИСТ

Сирәк чик сакчысы ЦРУ агентын әсирлеккә алуы белән мактана аладыр. Ә менә Балтач районының Дорга авылында туып-үскән Вениамин Кондратьевның рәхәтләнеп мактанырлыгы бар. Өстәвенә, американы сугыш барганда кулга төшергәннәр. Мондыйлар аеруча кыйммәт санала. Дөрес, чик сакчыларына вәгъдә ителгән медальләрне ни өчендер барыбер бирмәгәннәр.

Вениамин, күп кенә авылдашлары кебек үк, балачактан яшел кырпулы фуражка киеп йөрергә хыяллана. Ләкин 3 нче шәһәр урта һөнәри-техник училищесын күптән түгел генә тәмамлап, авиация заводында слесарь-җыючы булып эшләүче тәбәнәк буйлы егеттән военкоматта көләләр генә. Беренче тапкырында чиккә үз этләре белән генә алуларын әйтәләр, икенче тапкыр баргач исә үзе белән этиәнисен алып килергә киңәш итәләр, өченче тапкырында инде, егетнең үҗәтлеген бәяләп, «300» командасына язалар – СССР Дәүләт иминлеге комитеты (КГБ) чик буе гаскәрләре шулай билгеләнә. Повестканы 1985 елның апрелендә ала.

Ә менә хезмәт итү урынында – Ерак Көнчыгыш хәрби округының Райчихинск чик буе отрядында – яшь солдатның потенциалын шунда ук дөрес чамалыйлар һәм сержантлар мәктәбенә җибәрәләр. Ярты елдан соң Кондратьев аны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый, сержант дәрәҗәсе һәм ике вазыйфаны – отделение командиры һәм БМП-1 командиры булу хокукы ала. Тик менә бу күнекмәләрен советкытай чигендә түгел, ә моторлаштырылган маневр төркемендә – Әфганстанның Шибарган шәһәрендә урнашкан Чик буе гаскәрләренең махсус билгеләнештәге резерв бүлекчәсендә кулланырга насыйп була.

БМП командирының бурычлары бихисап: дошман һаман шартлатырга омтылган газүткәргечне саклау, автоколонналарны озата бару, корал төялгән кәрваннарга засадаларда катнашу. Һәм шулай ел ярым вакыт үтеп тә китә.

– Бервакыт засадада Америка махсус хезмәтләре агентын кулга төшерү насыйп булды. Кая тиеш, шунда илтеп тапшырдык. Безне бүләкләргә тиешләр иде. «Сугыштагы казанышлары өчен» медаленә тәкъдим итәләр, дип сөйләделәр. Ләкин барыбер насыйп булмады. Бу агент әфган кыр командирларына бүләкләр – япон фотоаппаратлары, алтын сәгатьләр, тагын нәрсәдер алып барган икән. Ә безнекеләрнең берсе кызыккан һәм бер фотокамераны үзенә алган. Моны белеп алгач, бүләкләү документларын кире борганнар, – дип сөйли Вениамин Кондратьев.

Шулай да Татарстан АССРда туган батыр башка – «Дәүләт чиген саклаудагы батырлыгы өчен» медале белән бүләкләнә.

– Снайпер безнекеләргә бер дә тынгы бирмәде. Аның кайда утырганын ачыклый алмадылар. Ерактагы киң ябалдашлы зур агач миңа бик шикле тоелды. Шуңа турылап туптан аттым да ектым, аннары пулеметтан да аттым. Һәм снайпер нәкъ шунда утырган булып чыкты, – дип горурланып искә ала чик сакчысы.

Вениамин Кондратьев: элеккеге чик сакчылары булмый. 2024 елның 28 мае.

Элеккеге танк командиры Евгений Кабыш үзенең взвод командиры Олег Степанов белән.

Әфганны кичкән егетләр гәпләшә.

ПОСТАМЕНТТА ОЧРАШКАННАР

Бу тарихтагы өч геройның да Әфганстаннан соңгы тормышы уңышлы була. Әнгам Ишмөхәммәтов демобилизациядән соң Башкортстаннан Казан инженерлык-төзелеш институтына укырга керергә китә. Югары уку йортын тәмамлагач, муниципаль һәм дәүләт хакимияте органнарында, югары белем бирү һәм сәнәгать системасында эшли. Хәзер Россия Социаль фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсендә иминиятләштерүчеләргә консультация бирү үзәгеннән җитәкли. Әфганчыларның иҗтимагый хәрәкәтенә башлангыч этапта кушыла, хәзер «Әфганстан ветераннары Россия берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Вахитов районы бүлеге идарәсе рәисе булып тора.

Әфганнан соң Олег Степановка Ковровта, Курскида хезмәт итәргә туры килә, АЭСтагы авариядән соң өч тапкыр Чернобыльгә бара, аннары атаклы Тамань дивизиясенең разведка батальонында хезмәт итә. 1990 елда Кызыл мәйдан буйлап Җиңү парады бронеколоннасында уза. 1991 елның августындагы һәм 1993 елның октябрендәге вакыйгалар вакытында үз танкында ике тапкыр Мәскәүгә керә.

1995 елда дивизиядә кыскарту башлангач, майор Степановка Таҗикстандагы 201 нче дивизиягә күчәргә тәкъдим итәләр.

«Җитте инде, күп сугыштым», – дип карар кыла офицер һәм запаска чыга. Казанга кайта. Бүген ул – сәүдә үзәкләренең берсендә сак хезмәте башлыгы.

Ә менә Вениамин Кондратьевны язмыш Татарстаннан дөнья читенә алып китә. Дембельдән соң авиазаводка кайта, ел ярымнан соң исә дусты Владивостокка акча эшләргә барырга кызыктыра. Нәтиҗәдә, әллә ни байый алмаса да, Ерак Көнчыгышка ияләшә – хатынын гына Татарстаннан алып китә. 15 ел Дәүләт автоинспекциясендә хезмәт итә, инкассациядә эшли.

Өчәү бергә постаментта калыкканчы алар бер-берсен белми. Ничек эләккән соң алар анда? Бу хакта монументны булдыру инициаторларыннан берсе, «Әфганстан ветераннарының Россия берле-

ге»нең Татарстан Республикасы төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе Евгений Кабыш сөйли:

– Һәйкәлнең иң яхшы макетына иҗтимагый конкурста тугыз проект катнашты. Скульптор Александр Кислов проекты җиңде. Дөрес, башта аның композициясендә ике генә кеше иде, ләкин без картинаның тулылыгы өчен радист җитмәвен әйттек.

Сугышчыларның йөзләренә килгәндә, алар башта нindидер бик чит тоелды. Мин, чын кешеләргә охшатып ясасаң иде бу батырларны, дип уйладым. Әфганчылардан, нигездә шәхсән белгән кешеләрдән, миңа сугыш чоры фотосурәтләрен җибәрүләрен сорадым. Нигә икәнен әйтмәдем. Аннары аларны Кисловка җибәрдем. Ул үзе сайлап алды. Аның минем взвод командирын сайлавы сөендерде. Олег, Әнгам һәм Вениаминга килгәндә исә, алар өчен үзләренең бронза һәйкәл булып калкуы турындагы хәбәр сюрприз булды.

Дүрт елга якын вакыт эчендә ир-атлар үзләрен пьедесталда яшь итеп күрергә күнеккән инде, аларның балаларына да бу гайре табигый тоелмый. Ә менә оныклары яу кырыннан мәңгелеккә атлаган әлеге монументаль сугышчы-алыпларның үз бабайлары булуына ышанып бетә алмый.

Вениамин, Олег һәм Әнгам үзләренең яшьлек төсе сеңеп калган бакыр һәйкәл каршында.



ҖИҢЕЛМӘС ЭКИПАЖ

Әскәр Сабиров

Разведчиклар Нижнемитякин хуторы янындагы Девяткин үзәнендә яндырылган, җимерелгән «КВ» танкын табып ала. Аның янында – сафтан чыгарылган 16 немец танкы, яндырылган бронялы машиналар, йөк автомобильләре, немец мәетләре, бик күп мәет... «КВ-1» танкы командиры Семен Коноваловның туган ягы Татарстанга үлеме турында кара кәгазь килә. «СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ» исеме белән бергә Ленин ордены һәм «Алтын Йолдыз» медаленә лаек (үлгәннән соң)» дип язылган була бүләкләү кәгазенә дә. Ә бүләкне 1943 елда тапшыралар – Коноваловның шәхсән үзенә...

1942 елның 13 июле. Ростов өлкәсе. Безнекеләр чигенә. Кичәге сугыштан соң лейтенант Семён Коновалов танкы туктап калган. Танк бригадасы сафтан чыгарылган «КВ»ны калдырып китә. Фәрман катгый – танкны төзәтергә һәм үзебезнекеләрне куып тотарга. Немецлар янәшәдә генә, шуңа уяу булырга. Экипажга булышырга дип тагын бер лейтенант – техника буенча рота командиры ярдәмчесе калдырыла, үзләре дә төшеп калганнардан түгел, шуңа күрә «КВ» тиз арада төзәтелә дә.

Үзләренекен куып тоту өчен, танк үзән буйлап бара, әмма шулчакта калкулыкта ике броневик – немецларның разведкасы пәйда була. Алар чокырдагы танкны күрми, үзләре исә уч төбендәгедәй яхшы күренә. Танк атуга, бер броневикка ут каба, икенчесе борылып кача...

ФӘРМАН – СУГЫШЫРГА!

Шуннан соң нәрсә буласы билгеле инде. Коновалов, дошман якынлашуын хәбәр итү өчен, радистка үзебезнекеләр белән элемтә урнаштырырга боера – тик элемтә юк... Аның каравы... 35 немец танкы каршыга килә. «КВ» аларга һаман күренми әле, мөгаен, качып өлгереп тә буладыр. Тик Коновалов сугышырга карар кыла!

Лейтенант Коноваловның тәҗрибәсе җитәрлек: беренче тапкыр танкта 41 елның августында ук янган кеше инде ул. Кыюлыгы турында әйтеп тә торасы түгел: каты яраланганнан соң, тылда яшь сугышчыларны гына өйрәтергә тиеш була, әмма үз теләге белән тагын фронтка китә. Сабырлыгы исә күпләрне сокландырырлык. Менә хәзер дә – үзен күрмәгән дошманнарын бик якын китерә, аннары гына броня җимергеч снаряд белән ата башлый!

Беренче танк – яна! Икенчесенә дә тия! Өченчесе туктап кала... Сугыш тиз арада төгәлләнә дә: броняларына тәре төшерелгән дүрт машина янып кала, калганнары борылып кача.

Немецлар, Нижнемитякин хуторын танк ротасы (бәлки әле батальоны да!) саклый,

Фото: vuslon.ru, гаилә архивыннан, taradmin.ru

дип уйлый, күрәсең. Лейтенант Коноваловның озын чокырда яшеренгән «КВ» танкы, оста хәрәкәт итеп һәм гел позициясен үзгәртеп, аларның шушы фикерен ныгыта.

ИЛЛЕ БИШ ТАНККА КАРШЫ БЕРҮЗЕ

Дошман бөтен хәрби кагыйдәләрне төгәл үтәп һөҗүмгә күтәрелә. Безнең «КВ» янына хәзер инде 55 танк якынлаша, алар колонна белән түгел, таралып бара! Әмма «КВ» чигенергә уйламый да. Ата да – урынын үзгәртә. Тагын ата – тагын үзгәртә… Девяткин үзәнендә танк һаман күренми әле, шуңа дошманнар аның берүзе икәнен аңламый. Тирән чокыр безнең флангларны да саклап тора.

Маңгайга маңгай бәрелешү немецлар өчен начар төгәлләнә. Сугыш кырында тагын алты танк дөрләп яна – безнекеләр бик төз ата шул. Калган танклар тагын чигенә. Борылып кача.

Иң куркыныч мизгел җитә. Яңа һөҗүм. Хәзер немец танкларына ярдәмгә пехота да кушыла. Безнең танк тагын алты машинаны яндыра әле. Тагын бер броневик һәм пехота утырган тагын берничә машина юк ителә… Әмма немецлар хәзер белә инде: аларга каршы нибары бер танк кына сугыша. «КВ» үзенә тагын берничә снаряд тиюгә чыдый, хәрәкәтләнә алмаса да, атуын дәвам итә.

Әмма хәрәкәтсез калган танк дошман өчен менә дигән мишеньгә әйләнә. Немецлар 105 миллиметрлы туп алып килә һәм 75 метр ераклыктан гына совет танкына төзәп ата…

СОҢГЫ СНАРЯД ҺӘМ СОҢГЫ МӨМКИНЛЕК

Әлеге куркыныч сугыш барышын Семён Коноваловның бүләкләү кәгазендә язылганнар буенча күз алдына китереп була. Документны тутыручы комбат Васильков бернәрсәне дә уйлап чыгармаган, бары тик фактларга гына таянган. Бригададан артта калган экипажның язмышын ачыклау өчен, 14 июльдә шул яу урынына разведка төркеме җибәрелә. Алар каршында коточкыч манзара ачыла. Сугыш кырында – яндырылган, җимерелгән «КВ» танкы, аның янында – сафтан чыгарылган 16 немец танкы, яндырылган броняли машиналар, йөк автомобильләре, дошман мәетләре, бик күп мәет…

Разведчиклар танкның эчендә янып үлгән сугышчыларның сөякләрен генә таба. Әлеге каты сугышның шаһиты булган җирле халыкны сораштыргач, бернинди шик тә калмый: экипаж геройларча һәлак булган…

Алар берсе дә лейтенант Коноваловның соңгы фәрманын биреpгә өлгерүен белми шул: ул исә соңгы снарядны атканнан соң аскы люк аша танктан чыгып качарга боера…

ДОШМАН ТАНКЫНДА – ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘР ЯНЫНА

«КВ»ның соңгы атуы немец тубының хәлиткеч атуы белән тәңгәл килә диярлек: янган машинадан җиде кешенең өчесе генә чыгып өлгерә – танк командиры Коновалов, корал төзәүче Дементьев, техник Серебряков. Караңгы булганга, аларның котылып чыгып китүен беркем дә күрми кала.

Комбат Васильков каһарманга бүләкләү кәгазе, писарьлар исә кара кәгазь тутырган чакта Семён Коновалов иптәшләре белән дошман тылында үзебезнекеләр янына чыгу юлын эзли. Шул көннәрнең берсендә алар үз танклары янында ял итүче немецларны күреп ала. Язмышның мондый бүләген кулдан ычкындырамы соң инде алар? Һөҗүм итәләр. Танк сакчысын Серебряков мылтык түтәсе белән бәреп ега, Дементьев тагын берсен юк итә, лейтенант Коновалов исә дошман машинасының командиры белән йөртүче механигын юк итә.

Танкистлар трофей танкта фронт ягына юл тота.

Дошман колоннасын очраталар. Якын ук килеп, ата, таптый башлыйлар… Шулай итеп дошман танкында үзебезнекеләр ягына чыгалар. Фронт сызыгын чыкканда, Коновалов экипажы инде үзебезнекеләр уты астында могҗиза белән исән кала.

КАРА КӘГАЗЬГӘ ЫШАНМАГЫЗ!

Немец танкын кулга төшереп кайту тагын бер бүләккә тартыр иде, әмма каһарманнарга әле үзләренең хыянәтче булмауларын дәлилләргә туры килә. Бәхеткә, тикшерү озакка сузылмый, һәм Семён Коновалов сугышуын дәвам итә: беренче айларда – үзе алып кайткан трофей танкта.

Семён Коноваловка Герой Алтын Йолдызын бер елдан соң диярлек, 1943 елда тапшыралар. Шул уңайдан өч көнлек ял да бирәләр. Хәзер Татарстанның Югары Ослан районына кергән Ямбулат авылына көч-хәл белән кайтып җитеп, туган йортының ишеген шакыгач, әнисе: «Йөрмәгез монда, китегез, минем улым һәлак булды, кара кәгазь килде…» – дип, башта аны өенә дә кертергә теләми әле…

Семён Коновалов ул сугышта исән кала. Җиңү көнен инде батальон командиры сыйфатында Германиядә каршылый. Аннары Казандагы ЭВМ заводында утыз ел эшли. Ә 75 елдан соң, 2018 елда, ил экраннарында баш геройның прообразы танк командиры Семён Коновалов булган «Несокрушимый» фильмы күрсәтелә. Тагын бер елдан соң Казанның Кирпичников урамындагы каһарман яшәгән йорт фасадына истәлек тактасы куела.

P.S. РОСТОВ ӨЛКӘСЕНДӘ, СЕМЁН КОНОВАЛОВНЫҢ «КВ-1» ЭКИПАЖЫ БЕРҮЗЕ 16 НЕМЕЦ ТАНКЫН ЮК ИТКӘН ҖИРДӘ, БҮГЕН ИСТӘЛЕК ТАШЫ ТОРА. ЯНЫНДА ҖИДЕ ЯШЬ НАРАТ ҮСӘ. ЛЕГЕНДАР ЭКИПАЖНЫҢ ҖИДЕ КАҺАРМАНЫ ХӨРМӘТЕНӘ УТЫРТЫЛГАН АЛАР. МЕНӘ АЛАРНЫҢ ФАМИЛИЯЛӘРЕ: ТАНК КОМАНДИРЫ КОНОВАЛОВ, ӨЛКӘН МЕХАНИК-ЙӨРТҮЧЕ КОЗЫРЕНЦЕВ, КОРАЛ ТӨЗӘҮЧЕ ДЕМЕНТЬЕВ, КОРУЧЫ ГЕРАСИМЛЮК, КЕЧЕ МЕХАНИК-ЙӨРТҮЧЕ АКИНИН, РАДИОТЕЛЕГРАФИСТ ЧЕРВИНСКИЙ, ТАНК БРИГАДАСЫ ТЕХНИК-ЛЕЙТЕНАНТЫ СЕРЕБРЯКОВ.

* «Климент Ворошилов» – танк «КВ».

КАВАЛЕРИСТ СОКОЛОВ СЕРЕ

Әскәр Сабиров

1807 елның 5 июне. Көнчыгыш Пруссия. Рус гаскәрләре Гутштадт шәһәре янында француз маршалы Ней корпусына каршы сугыша. Яу кызган чакта офицер Панинны пистолеттан атып атыннан төшерәләр. Яралыны үтерү өчен французлар урап ала. Көтмәгәндә шул төркемгә сөңгесен болгап бер ялгыз җайдак бәреп керә. Мондый акылсыз һөҗүмнән куркып калган французлар нәрсәдер аңлап өлгергәнче, кавалерист чапкан мәлгә Панинны ияренә күтәреп сала һәм үзенекеләр ягына җилдерә...

Яралы офицерны коткарган батыр сугышчы турында шунда ук югары даирәләргә хәбәр итәләр. Каһарман җайдак уланнар полкыннан дворян Александр Соколов булып чыга. Сугышчыны кыюлыгы өчен бүләклиләр һәм беренче офицер дәрәҗәсе бирәләр. Янәшәдәгеләрнең берсе дә Соколовның чынлыкта кем булуын белми. Ә каһарманның чын исеме исә – Надежда Дурова.

«ГАЗАПЛАРНЫ ТӘВӘККӘЛЛЕК БЕЛӘН КИЧЕРҮ, ҮЛЕМНЕ КУРЫКМЫЙ КАРШЫЛАУ...»

Әгәр дошман үзенең ир-ат булып киенгән хатын-кыздан куркып чигенүен белсә, оятыннан җир тишегенә кереп китәр иде. Тик, бәхеткә, дошманнар бу турыда белми. Хәер, кая инде ул французларга, мондый уй хәтта Гейльсберг, Гудштадт, Фридланд янындагы каты сугышлар-

Фото: Айдар Мөшәрәпов, ru.wikipedia.org, history.milportal.ru

да Дурова белән иңгә-иң торып сугышкан полкташларының да башына килә алмый. Соколов кыю, кызу, ярсу – яуда иптәшләре җилкәсенә посып калу түгел, кая ул, иң куркыныч урынга ыргыла. Кавалерия һөҗүмнәрендә ике тапкыр яралануы да моны раслап тора.

Шушы чандыр гына хатын-кызга олы батырлык һәм кыюлык каян килгән соң? Хәрби яшьлегеннән соң дистәләрчә ел үткәч язылган мемуарларында Надежда Дурова: «Мин үтерелгән һәм каты яраланганнарны бик күп күрдем инде! Гади солдатлардан аермалы буларак, укымышлы затларга намуслылык, каһарманлык хас: патшага тугрылык, ватан каршындагы изге бурыч аларны газапларны тәвәккәллек белән кичерергә, үлемне курыкмый каршыларга өнди», – дип үз фикерен белдерәчәк.

«СУГЫШЧЫ БУЛУ, МУНДИР КИЮ!»

Иртәме-соңмы, дөреслек барыбер өскә чыкмый калмаячак иде, билгеле. Кавалерист Соколовның сере ниһаять ачыла. Моңа чираттагы яралануы сәбәп булган, диләр: лазаретта, сугышчының җәрәхәтен бәйләү өчен, мундирын салдырырга туры килә... Хәер, тагын шундый төгәл факт та мәгълүм: этисенең энесе император Александр I гә үтенеч язуы тапшыра, анда патша хәзрәтләре гаскәрендә Соколов фамилиясе астында хатын-кыз яшеренүен хәбәр итә һәм императордан «әлеге бәхетсезне» өйгә кайтаруда булышуын үтенә.

Патша «бәхетсезне» Санкт-Петербургка чакыртып кайтарырга боера. Алар 1807 елның декабрендә Кышкы сарайда очраша. Әмма бу туганнары өметләнгән нәтиҗәне бирми...

Александр I Дуровага Георгий тәресен тапшыра, кыюлыгы өчен мактый, ә аннары, кырыс кыяфәткә кереп: «Кадерлем, булды, сугыштыгыз, хәзер инде ата-анагыз йортына кайтыгыз», – дип боера. Моны ишеткәч, Георгий тәресе кавалеры елап җибәрә һәм, өенә кайтармауларын үтенеп, патшаның аягына егыла.

«Нәрсә кирәк соң сезгә?» – «Сугышчы булу, мундир кию!» Император кавалерист кызга армиядә калырга рөхсәт итә. Ул Надежда Дурованы элиталы Мариуполь гусарлар полкына билгели һәм үзе хөрмәтенә Александров фамилиясен алырга боера. Бу көнне рус армиясендә беренче тапкыр корнет Александр Александров пәйда була – ул әле тагын дистә ел буе «мундирдан йөриячәк», Бородино сугышында яраланачак, 1812 елгы Ватан сугышын башыннан азагына кадәр үтәчәк һәм кампанияне җиңелгән Франциядә төгәлләячәк, штабс-ротмистр дәрәҗәсендә отставкага чыгачак.

«МИНЕМ БЕРЕНЧЕ БИШЕГЕМ ИЯР БУЛДЫ...»

Ул заманда гади кыз бала берничек тә сугышчы, бигрәк тә кавалерист була алмас иде. Надежда «гади» булмый шул. Киевта гусар ротмистры Дуров гаиләсендә туган кызны тәрбияләү гусар Астаховка йөкләнә.

«Минем беренче бишегем – ияр; корал һәм полк музыкасы – беренче уенчыкларым һәм мавыгуларым булды», – дип яза Надежда Дурова.

Гаилә Сарапулга күченгәч, этисе кызга Алкид кушаматлы черкес аргамагын бүләк итә. Тиздән атта йөрү Надежда Дурованың яраткан шөгыленә әйләнә. Ул хәрби хезмәт турында хыялллана.

1806 елда Сарапулдагы казаклар отряды походка җыена. Надежда, ирләр киеме киеп, яраткан Алкидына атланып, отрядны куып тота һәм үзен хезмәткә алуларын үтенә. Алпавыт улы Александр Соколов дип таныштыра. Аны отрядка алмыйлар, әмма Гродногa кадәр үзләре белән барырга рөхсәт итәләр. Анда «алпавыт Соколов» уланнар полкына урнаша. 1807 елның язы була бу. Коалиция гаскәрләре Наполеонга каршы сугыша...

«ИКЕ ЯКЛАП УЛАГАН АРТИЛЛЕРИЯ ШАВЫННАН МИН ЧУКРАКЛАНА ЯЗДЫМ...»

Биш елдан соң, куәтләнгән Бонапартның күпсанлы гаскәрләре Россиягә бәреп кергәндә, Александр Александров инде Литва уланнар полкы подпоручигы була.

Французлар белән Мир, Романов, Салтановка янындагы бәрелешләр... Генерал Багратионның 2 нче Көнбатыш армиясе составындагы полк, һөҗүм итүче дошманга каршы сугыша-сугыша, әкренләп Мәскәүгә таба чигенә. Гжатск тирәсендәге, Колоцкий монастыре янындагы яулар – бөтен җирдә кан, югалтулар һәм сугышчыларның дошман һөҗүмен туктата алмауга ачынулары.

Әмма шундый шартларда да Дурова бер мизгелгә дә рухын төшерми һәм батырлык могҗизалары күрсәтә. «Юк, куркакның җаны юк аның! Шулай булмаса, боларның барысын да күрү-ишетүдән соң аңа гайрәт ялкыны капмый калмас иде!» – дип язачак ул соңыннан үзенең хатирәләрендә.

Бородино сугышы. Дурова үзенең полкы белән бергә Семёновское флешларын саклый. Үзе әйтүенчә, бу «тәмуг көне» була. «Ике яклап улаган артиллерия шавыннан мин чукраклана яздым... Җанымда курку булмаса да, йөземнең төсе бер тапкыр үзгәрмәсә дә, тыныч булсам да, сугышудан туктасалар, мин бик сөенер идем», – дип яза ул.

Надежда Дурова – яшьлек елларында.

«МИНЕМ БЕРЕНЧЕ БИШЕГЕМ – ИЯР; КОРАЛ ҺӘМ ПОЛК МУЗЫКАСЫ – БЕРЕНЧЕ УЕНЧЫКЛАРЫМ ҺӘМ МАВЫГУЛАРЫМ БУЛДЫ», – ДИП ЯЗА НАДЕЖДА ДУРОВА.

Сарапулда Надежда Дуровага һәйкәл.

Надежда Дурова. А. П. Брюллов портреты, 1839 ел.

Атаклы сугыш аннан башка гына төгәлләнә – батыр сугышчы башта яралана, аннары ядрә белән контузияләнә… Мондый каты яудан соң отставкага чыгу хәрби карьераны лаеклы төгәлләү булыр иде. Тик Дурова өчен түгел шул.

Берничә ай дәваланганнан соң ул – кабат сафта. Хәзер инде поручик Кутузовта ординарец булып хезмәт итә: генерал әйтүенчә, аның әле беркайчан да Дурова кебек өлгер һәм төпле ярдәмчесе булмый.

Надежда Дурова Европаны Наполеоннан азат итә, Модлин, Гамбург, Гарбургны камауда катнаша. Штабс-ротмистр Александров, әтисенең үтенечен тыңлап, 1816 елда отставкага чыга. Хәрби җиңүләр артта кала, Дурованы алда әдәбият фронтында җиңүләр көтә.

«УҢЫШЫ – ШИКСЕЗ!»

Алабугада төпләнеп, Надежда Дурова мемуарлар язарга керешә. Александр Пушкин аларны укыгач таң кала һәм «Современник» журналында (1836, №2) бастыра, әдәби эшчәнлеген туктатмаска киңәш итә. Шул ук елда аның «Записки кавалерист-девицы» әсәре басыла. Пушкин аңа бик югары бәя бирә: «…искиткеч, тере, оригиналь, теле шәп. Уңышы – шиксез!» – дип яза.

Алабугада Дурова солдатларча яши: иртән салкын су белән коена, трубка тарта, кайчагында гусар вакыттагы кебек карта уйный. Мундирдан йөри һәм үзен штабс-ротмистр Александров дип атауларын таләп итә, әмма өлкәнәя төшкәч, кул эшләре белән мавыга башлый… Ул 1866 елның апрелендә бакыйлыкка күчә. Отставкадагы штабс-ротмистр һәм Георгий тәресе кавалеры белән хушлашырга бөтен шәһәр җыела, Ватанга каһарманнарча хезмәтенә ихтирам йөзеннән аны залп белән озаталар…

«ҖИБӘРМӘГӘН ҖИРГӘ БАРМА; ҖИБӘРГӘН ҖИРДӘН БАШ ТАРТМА!»

Алабуга, Мәскәү урамы, Надежда Андреевна Дурова үз гомеренең соңгы чирек гасырын үткәргән кечкенә генә агач йорт. Биредә, музей-йортта, гомерен Ватанга хезмәт итүгә багышлаган кавалерист кыз турында хатирәләр саклана. Легендар штабс-ротмистрның шәхси әйберләре саклануын сакланмаган, әмма музей хезмәткәрләре, бөртекләп җыеп, архив материаллары һәм Дурованың замандашлары истәлекләре буенча йортта шул заман мохитен тудырырга ирешкән. Биредә Наполеонга каршы сугыш чоры коралларын һәм хәрби мундирларның күчермәләрен күрергә була. Шулай ук биредә XIX гасыр уртасы җиһазлары һәм предметлары да шактый тупланган.

Ил үзенең каһарманын хәтерли. Аның тормыш юлы, армия хезмәте турындагы сүзләре варисларга васыять буларак кабул ителә. Бүгенге һәм киләчәктәге сугышчыларга. «Җибәрмәгән җиргә барма; җибәргән җирдән баш тартма! Кыюлык белән сыналганнар шул кагыйдә буенча яши».

Алабугада Надежда Дуровага куелган таш.

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН TATARSTAN

vk.com/protatarstann

t.me/protatarstan

ok.ru/tatarstan.zhurnal

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Реклама 16+

АЛИНӘ ШӘРИПҖАНОВА: «УЛ СОЛДАТНЫҢ ЕЛМАЮЫ КҮЗ АЛДЫМДА ТОРА...»

Руфия Фазылова

Татар эстрадасының иң үзенчәлекле җырчыларының берсе ул. Инструменталь ансамбльгә кушылып, татар, инглиз, рус, француз, итальян телләрендә җырлар башкара. Заманында Саратовтан Казанны яуларга килгән кыз үз теләгенә ирешә. Сүзебез – Татарстанның халык артисты Алинә Шәрипҗанова турында.

Җырчы узган елның көзендә бер төркем артистлар белән Луганск һәм Донецк шәһәрләрендә концертлар белән йөреп кайтты. Алинә безгә шул сәяхәте, үзенең иҗаты, гаиләсе турында сөйләде.

Фото: Александр Ефремов; гаилә архивыннан

– Алинә, сез күпләргә үрнәк: катнаш гаиләдә үсеп тә татарчагыз әйбәт. Өйдә әниегез сезнең белән рус телендә, этиегез татарча сөйләштеме?

– Әйе, катнаш гаиләдә туган бала мин. Саратов өлкәсенең Ершов шәһәрендә яшәдек. Әти-әнием анда билгеле кешеләр дисәм дә арттыру булмас. Икесе дә шәһәрнең Эчке эшләр идарәсе каршында оешкан вокаль-инструменталь ансамбльдә җырладылар. Әтинең үзе оештырган ансамбле иде ул. Әни белән танышу, кавышулары да шунда булган. Кызганыч, гаиләбездә үзара аралашу күбрәк рус телендә булды. Татар теленә мине этиемнең әнисе Камилә дәү әнием өйрәтте. Җәйләрен озаклап аның янында яшәдем. Ул шулкадәрле кызыклы кеше иде. Өздереп җырлый, бии, тормышны яратып яшәде. Татар җырларына нәкъ менә ул гашыйк итте мине. Җырлау сәләте, тавышым Камилә әбиемнән күчкән, диләр.

– Зур сәхнәгә килүегез шактый урау юллар аша булган. Сез югары белемле юрист. Бер ел укыганнан соң, Казан дәүләт мәдәният институтын ташлагансыз. Шулай да еллар узгач янәдән шушы югары уку йортына кайткансыз. Моңа нәрсә этәрде?

– Чынлап та, андый хәл булды. Тик бу сәнгатьтән китү түгел иде. Якыннар киңәше буенча, юридик белем дә алыйм дидем, В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновацион университетына укырга кердем. Анда сәнгатькә бик зур игътибар бирделәр. Профессиональ тавыш яздыру студиясенә кадәр бар иде. Биредә белем алганда нинди генә бәйгеләрдә катнашмадым, җиңүләр яуладым. Тик, күргәнегезчә, югары белемле юрист булсам да, тормышымны бары бер җыр сәнгате белән бәйләдем. Ә Казан дәүләт мәдәният институтын аннан соң барыбер тәмамладым. Бер бәйгедә Венера Ганиева белән таныштык. Ул мине үзенә укырга чакырды. Мин аңа бик рәхмәтлемен. Аның студентлары бик күп, әмма Венера Әхәтовна бөтенесенең тормышын да, хәлен дә белеп тора. Аны үземнең икенче әнием, иҗади әнием, дип саныйм.

– Сез опера арияләрен дә, эстрада җырларын да башкара ала торган җырчы. Чит телдә дә җырлыйсыз. Чит илгә эшкә чакырулар булмадымы? Китәр идегезме?

– Татар конгрессы эшчәнлегенә бәйле, чит илләрдә күп чыгышлар ясарга туры килә. Әмма Татарстанда яисә Россиядә генә яши алам. Биредә энергетика башка, суларга рәхәт. Мин бик ватанпәрвәр кеше. Туган илемне бик яратам һәм балаларны да шулай итеп үстерәм. Чит илдә бар нәрсә дә икенче төрле. Төркиягә барып, тәмле пешерәләр дип бер көн сыйланасың, ике көн. Ә аннан соң үзебезнең пәрәмәчләрне сагына башлыйсың. Шуңа чит илгә эшкә дә барасы килми. Монда гына «сайрый» алам.

– Алинә, нәкъ менә шул ватанпәрвәрлек турында сөйләшәсе килә. Сез хәрби зонада хезмәт итүче егетләребез алдында берничә тапкыр чыгыш ясаган җырчыларның берсе. Узган ел көзен Луганск белән Донецкига кадәр бардыгыз. Шул уңайдан сораулар күп: мондый сәфәргә чыгарга нәрсә этәрде? Егетләребез белән аралаштыгызмы?

– Татарстан Рәисе Аппараты үзебезнең «Алга» һәм «Тимер» полкларында хезмәт итүче егетләребез янына барып чыгыш ясап кайтырга тәкъдим итте. Берәүне дә мәҗ-

бүр итмәделәр. «Бара аласызмы, теләгегез бармы?» – дип кенә сорадылар. Тынгысыз кеше буларак, йөрәгем шунда ашкынды. Ни өчен дигәндә, бу тема миңа якын: махсус хәрби операциядә катнашучы егетләр белән беренче генә очрашуым түгел. 2022 елның октябрендә Казан ЭКСПОда беренче полкны җырлап озатып калдык. Иң гаҗәбе, шул егетләр белән инде хәрби операция зонасында күрешү насыйп булды. Аларның исәнлеген күреп сөенгәнемне белсәгез! Кочаклашып елаштык. Егетләр киләсебезне алдан белгән, алар да безне бик көткән.

– Ашау, яшәү шартлары ничек булды?

– Ростов өлкәсенә кадәр юл сизелмәде дә. Гадәти гастрольгә чыккан кебек кенә булды. Аны үткәч, Каменск-Шахтинск шәһәрендә кундык та таможняны үттек. Икенче көнне генерал Владимир Майстренко каршы алды, аннан соң юлга кузгалдык. Луганск шәһәрендә кунакханәдә яшәдек, дөресрәге төнгә кунарга кайттык. Хәрби зонада 10 көн булдык.

Луганск белән Донецк – икесе дә бик матур шәһәр. Күренеп тора: Россия бик нык булыша. Мариупольгә кадәр өр-яңа юллар төзелгән. Хәрби бәрелешләр барган урынга якынлашкан саен куркынычрак. Нindидер бер көтелмәгән хәл булыр дип тә борчылмыйсың. Янган, шартлаган йортларны, кара күмергә калган авылларны, шәһәрләрне күреп, йөрәк өзгәләнде. Урманнар, кырлар да кап-кара. Хәтта агачлар да калмаган. Әлегә кадәр мондый хәлләрне бары тик китаплардан укып, кинолардан гына күргән идек бит.

Без блиндажларда җырлап йөрдек. Фронтка кадәр биш, ун чакрым гына ара, туктаусыз шартлау тавышлары ишетелә. Ләкин син аңа ияләнәсең икән. Адәм баласы барысына да яраклаша. Егетләребезгә зур рәхмәт, алар безнең күңелне җылытты. Шундый яхшы каршы алдылар, чыгышларыбызны яратып тыңладылар, көчле алкышларга күмделәр. Иң мөһиме: алар анда берсе дә төшенкелеккә бирелмәгән. «Туган якка сәлам әйтегез», – дип калдылар.

– Татарча, русча җырладыгызмы?

– Татарча да, русча да. Аларның теләкләре буенча да җыр башкардым. Бер хәрби килеп Виктор Цой репертуарыннан «Кукушка» җырын бүләк итүемне сорады. Бу җырны беркайчан да җырлаганым юк иде. Тиз генә интернеттан табып, телефонга карап җырладым. Хәрбиләр елаштылар да, кушылып җырладылар да. Ул арада хәбәр бөтен җиргә таралып өлгергән. Кая барсак та, «Кукушка»ны җырлагыз әле, дип үтенделәр. Тагын Фирзәр абый Мортазинның «Сәлам әйт, җил» җырын да бик яратып кабул иттеләр. Татарча аңламаган егетләр дә безнең татар көйләренә биеде.

– Аеруча күңелгә кереп калган берәр очрашу булмадымы?

– Булды. Госпитальдә Татарстаннан булган 21 яшьлек егет белән таныштык. Яраланган иде. Ул мине таныды. Татарча матур иттереп: «Алинә апа, сезнең белән фотога төшик әле, әнигә җибәрер идем»,-диде. Фотога төштек. Шуннан әнисенә видео аша сәлам юллавымны үтенде. Әлбәттә, мин каршы килмәдем. «Зөлфия ханым, сезгә улыгыз сәламнәр җибәрә, мин дә кушылам. Сөенечле очрашулар теләп калам», – дидем. Аралаша торгач шул ачыкланды: исеме Максим Хуҗин, Мөслим районыннан. Тәрбиягә алынган бала икән. Кисәк кенә аннан соң исемә төште: ул гаилә турында телевизордан бер тапшыру караган идем. Мөслим районында яшәүче күп балалы Хуҗиннар иде алар. Тәртипле, тырыш гаилә дип, сокланганым истә калган. Максим әнә шул гаиләдән булып чыкты. Ул йөрткән квадроцикл минага эләгеп шартлаган. Яраланган килеш эвакуацияне көтеп, өч көн кырда яткан, бичаракай. Алланың рәхмәте белән исән калган. Әле дә Максимны еш искә алам. Елмаюы күңелдән китми. Исән-имин туган җиренә әйләнеп кайтырга насыйп булсын, дип теләкләр телим. Аның белән янә очрашасым килә. Гаиләсенә әйләнеп кайткач, бүләкләр алып, Мөслимгә барып килермен, дип ниятләп торам.

– Җирле халык белән дә очрашу мөмкинлеге булдымы? Безнең солдатларга мөнәсәбәт ничек анда?

– Җирле халык безне бик җылы кабул итте. Бер начар сүз дә ишетмәдек. Киресенчә, алар безнең солдатларга бик рәхмәтле. Тыныч, имин тормыш кайчан башланыр, дип көтеп яталар. Ләкин озаклап халык белән аралашырга әллә ни җай да чыкмады.

– Сугыш барган җиргә сезне чыгарып җибәрергә якыннарыгыз каршы килмәдеме?

– Каршы килмәделәр, юкса бармас та идем. Иң беренче булып ирем Айдарга шалтыраттым. Ул исә бер дә аптырап калмады. «Балаларны карарга әни, мин бар. Икәүләшеп ничек тә булса ерып чыгарбыз, теләгең булса, бар», – диде. Әле бит ничә көнгә барасы да билгеле түгел иде. Шөкер, гаиләм – иң зур терәгем.

– Алинә, гаиләгез турында күбрәк беләсе иде. Җәмәгатегез Айдар белән бер ул, бер кыз үстерәсез. Балаларга нинди тәрбия бирәсез?

– Айдар – төп таянычым. Мин аңа гел рәхмәтлемен, ул бик ярдәмчел. Сабырлыгыннан кайчагында үзем дә көнләшәм. Аның үз эше бар, гаиләбез өчен тырыша. Айдарыма бик күп җырлар багышлап җырлыйм. Айдар бик җитез, мин уйлаганчы ул эшләп куя. Әлбәттә, мондый ир белән яшәү рәхәт. Шундый ул тәрбияләгәне өчен каенанама рәхмәт укыйм. Каенатам да шундый җитез, Татарстанның атказанган энергетигы ул.

Айдар белән бер ул, бер кыз үстерәбез. Үз йортыбыз белән Биектауның Калинино бистәсендә яшибез. Мин шофер булып эшлим дип көләм: көне буе балаларны тегендә, монда йөртәм. Хәзер бит балаларның һәр сәгате бүленгән. Кызыбыз Әлмирә фигуралы шуу белән, улыбыз Әмир катнаш көрәш белән шөгыльләнә. Икесе дә музыка мәктәбендә дә белем ала.

– Гадәттә, үз йортында тавык та чүпләп бетермәслек эш. Барысына да ничек җитешәсез?

– Үземнең әнием безнең белән яши, ул бик булыша. Бакча эшләре тулысынча аның өстендә дияргә мөмкин. Ике теплицабыз бар. Бакчада нинди генә чәчәкләр үстерми ул. Аларны почта аша да кайтарта, кыскасы, фанат инде. Әнигә 66 тула, Аллага шөкер, әле кызлар кебек. Һаман да эшләп тә йөри.

– Озын чәчләрегезне имиджыгыз дип кабул итәбез. Аны тәрбияләүнең берәр сере бармы?

– Алай зур сере юк: башта шампунь, аннан бальзам белән юам. Тарарга җайлы булсын өчен махсус май сөртәм. Шуның белән шул. Гомергә озын чәч яраттым, өйдә дә рәхәт, җыеп куясың да, коелмый. Кызымның да чәчләре озын, килешле, матур толымнар ясыйбыз. Концертлар вакытында чәчне үземә үзем дә ясыйм, зуррак чараларга оста да чакыртам. Хатын-кызны озын чәчләр тагын да гүзәл итә, дип саныйм.

– Алинә, бүген нинди максат, теләкләр белән янасыз?

– Беренчедән, бер буш көнем юк, репетицияләр, дәүләт чараларындагы чыгышлар. Шуның өчен аерым концертлар куярга бик җай да юк. Һәм төп эш урыннарым бар: Казан дәүләт мәдәният институтының Югары сәнгать мәктәбе факультетында, соло халык җыры кафедрасында студентларга белем бирәм. Татар дәүләт опера һәм балет театрында чакырылган солист буларак та чыгыш ясыйм.

Күптән түгел зур вакыйга булды – Камал театрының яңа бинасы ачылды. Тәүге концертым Камал театрында узган иде. Театрның элеккеге директоры Шамил Закиров ул чакта үзе чакырды. Аңа карата хөрмәтем бик зур. Инде хәзер яңа бинада да концерт кую теләге бар. Эльмир Низамов белән бер программа әзерләгән идек, фортепианадо үзем уйнап, тере тавышка җырладык. Әнә шундыйрак юнәлештә, моноспектакль форматында концерт әзерлисем килә. Кыскасы, планнар, идеяләр күп. Шуларны тормышка ашырырга исәнлек, тынычлык булсын.

КӨНДӘЛЕК ТОРМЫШЫБЫЗДА ФИЗИКА

Евгения Чеснокова

Кешелекне алга этәрү, тормышыбызны уңайлырак итү өчен фән нинди юнәлешләрне сайлый? Бүгенге язмабызда «РФА Казан фәнни үзәге» Федераль тикшеренү үзәгенең Завойский исемендәге Казан физика-техника институты галимнәренең кайбер эшләнмәләре турында сөйләрбез. Алар ирешкән нәтиҗәләр якын киләчәктә безнең әйләнә-тирәбезне нык үзгәртергә сәләтле.

Завойский исемендәге КФТИның медицина физикасы методлары лабораториясендә магнит-резонанс томографиясе өчен заманча җиһазлар уйлап табу белән шөгыльләнәләр. Үпкә магнит-резонанс томографиясен гиперполяризацияләнгән ксенон кулланып үкәрү технологиясен эшләү – бүген иң яңа һәм актуаль проектларның берсе.

ГАЗ ТОМОГРАФНЫ НИ РӘВЕШЛЕ ЯХШЫРТА

Башта ни өчен моның бик мөһим булуы турында. Бер мәзәкне хәтерлисезме: «Еллар узар, ләкин сез 2020 елның язында көн саен кайда булуыгызны төгәл әйтә алырсыз»? Әйе, күбебез ковид-19 пандемиясе аркасында көннәр буе өйдә утырырга мәҗбүр булды. Бик күпләргә вирус белән күзгә-күз очрашырга туры килде. Аларның авырып киткән бер өлеше, мөгаен, компьютер томографында үпкәләрен тикшерткәндер. Әле бер генә мәртәбә дә түгел.

Компьютер рентген томографиясе – бүген ковид белән авырганда кулланыла торган стандарт метод. Ул шактый мәгълүмат бирергә сәләтле, әмма аның кайбер зыянлы яклары да бар. Әйтик, Колумбия университеты (АКШ) галимнәренең тикшеренүләре шуны күрсәткән: КТ үткән һәр 10 мең кешенең сигезе рак белән авырый башлаган, сәбәбен әлеге процедурага бәйлиләр. Ни дисәң дә, компьютер томографы – ул нурланыш, гәрчә бик көчле булмаса да.

– МРТ методы исә организмга нурланыш бирми, өстәвенә, КТга караганда мәгълүматны да күбрәк алырга була, – дип сөйли медицина физикасы лабораториясе мөдире Яхъя Фәттахов. – Әмма магнит-резонанс томографы кешене тикшергәндә аның үпкәләрен «күрми», чөнки алар һава белән тулган була. Анда томограф теркәргә тиешле протоннар аз. Нәтиҗәдә магнит-резонанс томографында тикшергәндә үпкәләр кара тишек булып күренә.

Шул ук вакытта гиперполяризацияләнгән газ – гелий яисә ксенон – контраст матдә булып хезмәт итә алыр иде, нәтиҗәдә томограф үпкәләрне «күрергә» сәләтле булып чыгачак. Яхъя Фәттахов шуны да искә төшерә: КФТИның Казан университеты белән бергәләп поляризацияләнгән газ – ул чакта ксенон түгел, гелий кулланып, экспериментлар үткәреп караганы булган. Әлеге эксперимент зур кызыксыну уяткан, чөнки нәтиҗәсен медицина белгечләре генә түгел, геологлар да көткән: шундый газ ярдәмендә нефтьле токымнарны да тикшерергә мөмкин булыр иде. Принцибы да шул ук – газны нindидер эчке куышларны күрергә мөмкинлек бирә торган контраст матдә сыйфатында куллану.

Гелий урынына гиперполяризацияләнгән ксенон кулланып экспериментны медицина өлкәсенә күчерергә 2022 елда Казан физикларына «Росатом» системасындагы бер институт тәкъдим итә.

Медицина физикасы методлары лабораториясенең томографлар эшләү юнәлешендә шактый бай тәҗрибәсе була. Зур булмаган коллектив, башка Татарстан институтлары

Кече фәнни хезмәткәр Әлфис Баязитов томограф аппаратын көйли.

Фото: Булат Фәррахов

һәм предприятиеләре белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, кешенең бөтен гәүдәсен тикшерә торган дүрт томограф ясаган, 30 меңнән артык пациент тикшеренү үткән. Ә ун еллап элек лабораториядә портатив магнит-резонанс томографын ясаганнар – суставларны тикшерү өчен. Ихтимал, әлеге уңышлар «Росатом»ның игътибарын җәлеп тә иткәндер. Бөтен Россия буйлап фәнни партнёрлар эзләгән «Росатом» яңа эшне башкарып чыгу өчен нәкъ менә Завойский исемендәге КФТИга мөрәҗәгать итә.

Физиклар үз томографларын үзгәртәләр, яхшырталар, ксенон кулланып эшләргә мөмкинлек бирә торган программасын уйлап табалар. Алар РФА Федераль тикшеренү үзәгенең башка институтлары, КФУ галимнәре, шулай ук КДМУ һәм медицина академиясе белгечләре белән хезмәттәшлектә эшлиләр.

Газ белән экспериментларны күселәрдә үткәрәләр. Әлбәттә, аларны газ сулап, берничә секунд сулышны кысып торырга мәҗбүр итү мөмкин хәл түгел, шуңа күрә наркоз кулланалар, ә күселәрнең үпкәләренә ксенон ИВЛ аша бирелә.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: экспериментлар РФА Казан фәнни үзәге Федераль тикшеренү үзәге каршында эшләп килгән биоэтика комиссиясе ризалыгы белән үткәрелә һәм бөтен җәнлекләр исән кала.

Тикшеренү нәтиҗәләре бик шатландыра.

– Гиперполяризацияләнгән газ кулланып үткәрелгән мондый инвазив булмаган тикшеренүләребез үпкәләрнең структурасын һәм эшләү процессын җентекләп күрсәтә. Гадәти МРТ һәм башка төрле методлар ярдәмендә моңа ирешү мөмкин түгел иде, – ди Яхъя Фәттахов. – Һәм бу методика буенча ковид белән авырган пациентларны гына түгел, астма, үпкәләрендә обструктив үзгәрешләр булган авыруларны да тикшерергә мөмкинлек туды. Бу вакытта кеше нурланышка дучар ителми. Моннан тыш, әлеге методның сизгерлеге МРТ-сканерның магнит кыры көченә бәйле түгел, ә бу зур булмаган магнит кырына ия арзанлы томографларны кулланырга мөмкинлек бирә. Димәк, МРТ процедурасы сизелерлек арзаная.

Хәзер экспериментта катнашучылар тикшеренүләрне дәвам итәрбез, перспективада Россия пациентлары кирәк булганда зыянлы йогынтысы булмаган диагностиканы үтә алырлар, дип өметләнәләр.

КАТЛЫ-КАТЛЫ КАМЫР РЕЦЕПТЫ БУЕНЧА

Без барыбыз да электрон приборлар кулланабыз. Алар елдан-ел камилләшә бара. Бу бигрәк тә компьютер техникасында чагыла – ноутбук һәм смартфоннарыбыз җиңеләя, компактлырак була барсалар да, тизрәк эшлиләр, функцияләре дә арта бара. Мөгаен, аларны гел яхшыртып булмыйдыр?

– Заманча ярымүткәргечле электроника чипларына урнаштырылган транзисторлар саны ел саен бермә-бер арта бара, – дип сөйли Завойский исемендәге КФТИның гадәттән тыш үткәрүчәнлек һәм спинтроника проблемалары кафедрасы мөдире Андрей Камашев. – Әмма әлеге процессның да чиге бар, һәм без аңа якынаябыз. Димәк, тиздән аларның тизлекле йогынтысы үсүеннән туктаячак.

Заманча электроникага бер альтернатива – гадәттән тыш үткәрүчәнлекле спинтроника, гадәттән тыш үткәрүчән материаллар куллануга нигезләнгән технология. Гадәттән тыш үткәрүчән приборлар күпкә тизрәк эшләргә сәләтле һәм энергия куллану ягыннан да нәтиҗәлерәк.

– Әле узган гасырның 90 нчы еллары ахырында АКШта гадәттән тыш үткәрүчән спин клапаны – хәзергеләрне алыштырырлык яңа төр транзистор моделе тәкъдим ителә, – дип аңлата Андрей Камашев. – Ләкин мондый клапанның беренче экспериментал үрнәген 2010 елда нәкъ менә безнең лабораториядә ясадылар. Физиклар берничә ел дәвамында материаллар сайладылар, система конструкциясенең оптималь параметрларын эзләделәр.

Сүз ниндидер принципиаль яңа гадәттән тыш үткәрүчән материаллар турында бармый, дип аңлата Андрей Камашев, алар барысы электән үк билгеле иде. Эш аларны бер-берсенә ялгауның, кушуның элек кулланылмаган яңа системасында, конструкцион үзенчәлекләрдә. Спин клапаны – үзенчәлекле катлы-катлы «пирог», юка элпәле структура, һәр катның калынлыгы берничә нанометр. Казан физиклары менә шушы катларны ничек кушу, аларның оптималь размерын ничек сайлау юнәлешендә эшли дә.

Беренче үрнәк ясалганнан соң, гадәттән тыш үткәрүчәнлек һәм спинтроника проблемалары лабораториясе галимнәре үзләренең экспериментларында шактый алга китә. Узган елны югары рейтингка ия фәнни журналларның берсендә алар үзләре эшләгән система нәтиҗәлелегенең беренче сынаулар белән чагыштырганда 60 тапкырга артуын күрсәткән мәкалә бастырдылар.

– Без тәкъдим иткән конфигурация кайбер уникаль үзенчәлекләргә ия, – ди Андрей Камашев. – Алга таба безнең эшләнмәләр күп баскычлы исәпләүләрне, зур системаларны модельләштерүне таләп итә торган катлаулы математик, криптографик мәсьәләләрне чишкәндә кулланыла ала.

Зур тизлекле йогынтыга ия гадәттән тыш үткәрүчәнлекле спин клапаннары көндәлек тормышыбызга турыдан-туры көчле тәэсир итмәстер – кешегә, әйтик, смартфонының тизлеге һәм функцияләре әлегә бик җитә. Тик әйдәгез искә төшерик: әле 50 ел элек кенә беркем дә, өйдә, эштә персональ компьютер кирәк булыр дип, башына да китереп карамый иде. Шуңа күрә вакыт узган саен югары тизлекле һәм энергия куллану ягыннан файдалы спиннар да көндәлек тормышта кирәкле электрониканың бер өлешенә әйләнмәс, дип әйтеп булмый.

– Гадәттән тыш үткәрүчәнлекле спин клапанының беренче экспериментал үрнәген 2010 елда нәкъ менә безнең лабораториядә ясадылар, – дип сөйли Завойский исемендәге КФТИның гадәттән тыш үткәрүчәнлек һәм спинтроника проблемалары кафедрасы мөдире Андрей Камашев.

ИНКЛЮЗИЯДӘН IT-СТАРТАПЛАРГА КАДӘР. ТИСБИ: ЦИФРЛЫ ЗАМАНА ПРОФЕССИОНАЛЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮ СЕРЛӘРЕ

Олеся Бондаревская

Диджитал чорында идарәчеләрне нәрсәгә өйрәтәләр? Студентларга эшмәкәрлек күнекмәләрен үстерү ник кирәк? Ни өчен инклюзия чикләүләр түгел, ә яңа мөмкинлекләр дигән сүз? Болар хакында югары уку йорты ректоры Дмитрий Поляков белән сөйләшәбез.

– Дмитрий Владимирович, ТИСБИның иң кызыклы проектларыннан берсе – инвалидлыгы булган һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле студентлар өчен белем бирү программалары. Дәүләтнеке булмаган югары уку йорты бу юнәлешкә ни өчен өстенлек бирде? Әлеге омтылышның нәтиҗәләре нинди?

– Беренче ректорыбыз Нэлла Матвеевна (Нэлла Прусс, ТИСБИга нигез салучы, хәзер аның президенты – *ред. иск.*) иң башта ук барлык категория студентлар өчен белем алу мөмкинлеген университет үсешендә төп принципларының берсе итеп билгеләде. Илдә беренчеләр арасында һәм Татарстанда беренче булып, инклюзив белем бирү системасын эшләдек һәм 90 нчы елларда халыкара программага кушылдык. Ул программа безгә саңгырау балалар белән эшләү методикасын үзләштерергә ярдәм итте. Тора-бара югары уку йорты структурасында инклюзив белем бирү институты ачылды. Анда инвалидлыгы булган һәм сәламәтлеге чикләнгән балаларга көндезге уку өчен шартлар тудырылды. Хәзер бездә 74 инвалид студент укый, ә белем алып чыкканнарның гомуми саны меңнән артып китә.

МЕНЕДЖМЕНТ ҺӘМ «ЦИФР»: БЕРГӘМЕ ӘЛЛӘ БЕР-БЕРСЕ УРЫНЫНАМЫ?

– Алар эш таба аламы?

– Эш бирүчеләрнең күбесе без укытып чыгарган инвалид белгечләрне аларның көчле яклары – бер урында утырып эшләүдә сабырлыгы, бертөрле эшне ахыргача җентекләп башкарып чыгу сәләте, предметларны энәсеннән җебенә кадәр белүе, документлар белән дөрес эшләү күнекмәсе өчен югары бәяли. Шуңа күрә бездә укыганнан соң эшкә урнашу проценты шактый югары (80-85%).

– Миссия темасын дәвам итик. Илнең техник югары уку йортлары алдында бүген технологик суверенитет формалаштыру һәм цифрлы трансформация проектларында катнашу бурычы тора. ТИСБИның төп юнә-

Фотолар ТИСБИ дан алынды. РЕКЛАМА

леше – идарәчеләр, икътисадчылар һәм юристлар әзерләү һәм, беренче карашка, ул югары технологияләр белән әллә ни бәйләнештә дә түгел кебек. Шуңа да карамастан, университет IT-кластерны үстерүгә күп өлеш кертә. Бу тактикамы яки стратегиями?

– Цифрлаштыруга йөз тотуыбызда ике фактор роль уйнады: инвалид студентлар өчен программалар эшләү белән бәйле технологияләр һәм инфраструктураны вуз эчендә үстерү, шулай ук уку-укытуда гадәттәгечә дисциплинаара ысулга өстенлек бирү. Мәсәлән, егет-кызларның тормышта кирәкле белем базасы баерак булсын өчен, без юриспруденция модульләрен – икътисадчылар программасына, икътисад модульләрен идарәчеләр программасына һәм башкаларга һәрвакыт кертеп килдек. Бу алымны камилләштереп, диджитал-компетенцияләрне дә өсти башладык. Хәзер бакалавриат, магистратура һәм аспирантураның 50 гә якын программасына цифрлы дисциплиналар кертелгән.

МИЛЛИОН ТӘҢКӘЛЕК ТОЗ

– ТИСБИ программаларына хас булган гамәли якка өстенлек IT-компетенциягә дә кагыламы? Нәтиҗәләрне санап-үлчәп буламы?

– Финанслар ягыннан әйтергә була: 11 студентыбыз Инновацияләргә ярдәм фондының «Студентлар стартабы» конкурсында җиңде һәм үз проектларын гамәлгә ашыру өчен берәр миллион сум акча алды. Ә 2023 елда безнең яшь хезмәткәребез Роман Старостин Татарстанда беренче булып «Сколково» фонды шәхси инвесторларның (бизнес-фәрештәләрнең) инвестиция чыгымнарын каплау программасына керде. Эш шунда ки, бизнес-партнерларыбызның проект командаларында реаль кейсларны хәл итү юнәлешендә эшләгәндә, студентлар цифрлы технологияләрне актив куллана. Студент проект командаларын кызыксындыру һәм инициативаларын үстереп җибәрү өчен, без инде өч ел акселерация программаларын уздырабыз. Моннан тыш, бу өлкәдә без берничә ел «Илкүләм технологик инициатива платформасы» (НТИ) Автоном коммерциячел булмаган оешмасы белән хезмәттәшлек итәбез.

– Студентлар стартаплар өчен хәзер нинди юнәлешләрне сайлый?

– Сәламәтлек, мәгариф, сәнгать, IT, җитештерү мәсьәләләрен хәл итү. Конкурста җиңгән проектлар арасында, мәсәлән, сәнгать предметлары аукционнары өчен Digital Art Auction электрон мәйданчыгы, чүп-чарны эшкәртү өчен төрләргә аеру һәм тапшыру өчен EcoKazan экокушымтасы, төзелеш-техник экспертиза сметасын эшләүне автоматлаштыру өчен Otmetka-X сервисы, «Тәменчә тоз» дип аталган дөрес туклану трекеры һәм башкалар бар.

– Базар потенциаль инвестиция проектларына да, яшь белгечләргә дә югары таләпләр куя. ТИСБИда уку-укыту һәм студентларның ният-тәкъдимнәрен тормышка ашыру арасында бәйләнеш ничек корыла?

– Моның өчен без «Кайнау нокталары» («Точки кипения») федераль проектына кердек һәм 2023 елның ахырында югары уку йорты базасында шундый мәйданчык ачтык. Мәйданчыкның төп өч юнәлеше – инклюзив белем бирү, яңа белем бирү технологияләре (педагогик дизайн) һәм технологик эшкуарлык. «Кайнау ноктaлары»ның бер бурычы – компанияләр һәм эшмәкәрләр («Идея» инновацион технопаркы, Бизнес-инкубатор, «ИТ-парк» Югары технологияләр өлкәсе технопаркы» ДАУ, Татарстан Республикасының кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе) соравы нигезендә студентлар эшләгән проектларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру.

МӨГАЛЛИМЛЕКТӘН ЭШМӘКӘРЛЕККӘ – БЕР АДЫМ

– Компанияләр һәм эшмәкәрләр югары уку йортына еш мөрәҗәгать итәме?

«ТИСБИ» идарә университеты

– Татарстанның дәүләт аккредитациясенә ия дәүләтнеке булмаган беренче университеты

Нигез салыну елы: 1992

Белем бирүнең төп юнәлешләре: юриспруденция, мәгълүмати технологияләр, икътисад, халыкара мөнәсәбәтләр, менеджмент, педагогика, сервис, кунакханә эше, туризм

Югары уку йортын тәмамлаучыларның мәшгульлек өлкәләре: бизнес; дәүләт хезмәте, банк эше, сәнәгать өлкәсендә менеджмент; халыкара оешмалар

Студентларның гомуми саны: 10 мең

Бюджет урыннары саны: 700 дән артык

ТИСБИда белем алган инвалидлар һәм сәламәтлеге чикле кешеләр саны: 1 меңнән артык

Югары уку йортын тәмамлаучылар эшли торган компанияләр: Саклык банкы, ВТБ, Ак Барс Банк, Т-Банк, Альфа-Банк, ТР Арбитраж суды, Казан вертолёт заводы, С. П. Горбунов исемендәге КАЗ, «Татнефтехим», Иннополис Университеты, «ВКонтакте» һәм башка бик күпләр

* «Россия Федерациясенең фәнни-технологик үсеше» дәүләт программасының «Университетта технологик эшкуарлык платформасы» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында.

– Без даими элемтәдә торабыз. Әйтик, «Кайнау нокталары» проекты безгә «Түбәтәй» татар ризыклары ресторанын алып килде. Нәтиҗәдә алар өчен махсус кадрлар әзерләү программасын эшләдек. Бу юнәлешкә Россиянең теләсә кайсы төбәгеннән укырга керергә мөмкин. Әңгәмә үткәреп, тиешле таләпләргә туры килгән очракта, «Түбәтәй» студентларның укуы өчен түли. Шундый ук партнёрлык турында хәзер «Синнабон» кондитер ризыклар челтәре белән сөйләшүләр алып барыла.

– Белем бирү программаларына заказ бирүчеләр сыйфатында сез нинди компанияләрнең мөрәҗәгатен көтәсез?

– Банклар. Без инде максатчан төркемнәр әзерләү турында сөйләшүләр алып барабыз. Әлбәттә, хокук саклау органнары да күз уңында тотыла, чөнки юридик мәктәбебез бик көчле – бездә белем алганнарның бик күбе прокуратурада, судларда, тикшерү органнарында, көч структураларында эшли. Нигездә, без айти-белгечләр, икътисадчылар, идарәчеләр, администраторлар кирәк булган теләсә нинди юнәлеш вәкилләре белән эшләргә әзер.

– Яңа уку-укыту программаларын әзерләгәндә, җәмгыятьтәге ихтыяҗларны исәпкә аласызмы?

– Хезмәт базары торышын җентекләп тикшереп торабыз. Мәсәлән, хәзер педагогларга, шул исәптән мәгариф өлкәсендә идарәчеләргә кытлык арта. Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы мөрәҗәгатен һәм киңәшләрен күздә тотып, программа эшләдек, хәзер укытучылар әзерлибез. Без шәхси мәктәпләрдә дә, өстәмә белем бирү өлкәсендә дә ихтыяҗ барлыгын аңлыйбыз, шуңа күрә педагогик юнәлештәге студентларны безнең Студентлар эшмәкәрлек үзәге проектларына да җәлеп итәбез.

ЯШЬЛӘР ИШЕТСӘ ДӘ, ХӘТЕРЛӘМИ

– Трендлар темасын дәвам итик. Бөтен дөнья хәзер ясалма интеллект казанышлары турындагы яңалыклар белән тулган. Ясалма интеллект белем бирү процессларын үзгәртерме?

– Сентябрьдә без бу мәсьәләгә багышланган бик зур конференция уздырдык. Ясалма интеллектның укытучыны алыштырмаячагы шик уятмый, әмма ул студентлар белән эшләгәндә яхшы ярдәмче булырга мөмкин. ТИСБИ бу технологияне актив куллана. Без «Яндекс»тан грант алуга ирештек һәм безнең «ИСУ-вуз» идарә итү мәгълүмат системасында егерме елдан артык туплана килгән мәгълүматлар нигезендә, хәзер студентларыбызның карьера траекторияләре аналитикасы белән шөгыльләнәчәк нейрочелтәрне өйрәтәбез. ТИСБИны тәмамлаучылар да шәхси кабинетларыннан файдалануны дәвам итәр, дип өметләнәбез. Бу әнә шундый персонификацияләнгән ясалма интеллект – карьера буенча консультант булачак.

– Мәктәп укучылары һәм студентларның бик күбесе бүген нейрочелтәрләрне өй эшләре һәм проектлар эшләү өчен актив куллана. Моңа карашыгыз нindирәк? Бу күренеш белем бирү сыйфатына йогынты ясыймы?

– Ясалма интеллектны уку-укыту өчен куллану – табигый процесс. Прогресска каршы тору мәгънәсез. Мине моның белән бәйле башка күренеш күбрәк борчый. Технологияләр, акрынлап, күп ишетеп, белемне яхшылап үзләштермичә, ишеткәнгә генә таяну белән алышынуына китерә. Яшьләр мәгълүматны бик яхшы эзли, ләкин аны истә калдырмый. Тирәнлек юк. Математика, физика, химия законнарының чынлыкта ничек эшләгәнен яшьләр начар күзаллый.

Безнең бурыч – егет һәм кызларның бу белемнәрне күңеле аша үткәрүенә, акылы белән кабул итеп үзләштерүенә кире кайту. Бу фундаментка таянып, киләчәктә яңа белемнәрне төшенә алсыннар, күбрәк укысыннар-өйрәнсеннәр яки уйлап тапсыннар өчен. Безгә, мәгариф системасы вәкилләренә, бу кризисны узып, яшьләрне кабат китап укырга өйрәтергә кирәк. Әмма моның өчен даими рәвештә камилләшү таләп ителә. Бу бүген бөтен кешегә кирәкле төп күнекмә.

БАРЫСЫН ДА КАДРЛАР ХӘЛ ИТӘ

ПЕРСОНАЛ САЙЛАУ ҺӘМ ЯЛЛАУ ӨЛКӘСЕНӘ ФӘН ҺӘМ ЦИФРЛАШТЫРУ НИЧЕК ҮТЕП КЕРДЕ

Ясалма интеллект (AI) һәм автоматлаштыру предприятиедә персонал белән идарә итү эшен үзгәртеп коруны дәвам итә. AI хезмәткәрләрнең мәгълүматларын анализлау, аларны өстәмә укыту кирәклеген фаразлау һәм хәтта әңгәмәләр уздыру өчен дә кулланылырга мөмкин. AI-системалар резюмеларны карау-тикшерү процессын автоматлаштыра, тиешле шартлар буенча сайлап алынган кандидатлар санын арттырып, эшкә яллауның нәтиҗәлелеген үстерә.

HR эшендә чат бот куллануның төп өстенлеге – бертөрле ялыктыргыч операцияләрне автоматлаштыру һәм мәгълүматны бердәм системага җыю. Программа эш эзләүчеләрне барлау, вакансияләр урнаштыру, эш бирүче компания турында мәгълүмат тарату кебек процессларны тизләтә. Автоматлаштыру кеше факторы белән бәйле хаталар санын киметә. AI шулай ук хезмәткәрләрнең җитештерүчәнлеге һәм мотивациясе турындагы мәгълүматларны анализлау өчен дә кулланылырга мөмкин. Бу компанияләргә үз хезмәткәрләрен яхшырак аңлап идарә итәргә булыша. Якындагы елларда предприятиеләр уку-укыту, HR-аналитика, адаптация, эшкә яллау, компенсация һәм ташламалар кебек HR-процессларны цифрлаштырырга планлаштыра.

– Персонал белән идарә итүнең киләчәге мәшгульлекнең тиз үзгәрүчән формалары үсеш алу белән бәйле – бу көннән-көн ачыграк күренә. Читтән торып эшләү, иректә, җайга салынган график һәм проектлы эш рәвеше популярлаша бара. Бу җитәкчеләрдән төрле шартларда эшләүче хезмәткәрләр белән идарә итүдә һәм аларның хезмәтен бәяләүдә яңа алымнар куллануны таләп итә. Предприятиеләр хезмәткәрләргә читтән торып һәм үзгәрүчән, җайга салынган график белән эшләргә мөмкинлек бирә торган технологияләр һәм процессларны гамәлгә кертә башлады. Мондый үзенчәлек эшне һәм шәхси тормышны балансга тотарга һәм хезмәткәрләрдә канәгатьлек хисен арттырырга ярдәм итә, – дип аңлата **икътисад фәннәре кандидаты, доцент, КИТТУ-КАИ ның икътисад теориясе һәм ресурслар белән идарә итү кафедрасы мөдире Гөлнара Мостафина**. Кафедра күп төрле белем бирү программаларын уңышлы тормышка ашыра. Алар арасында «Персонал белән идарә итү 38.04.03» юнәлеше кысаларында «HR: оештыру үсеше һәм стратегик идарә» дип аталган магистратура программасы да бар. Программа илебез предприятиеләре һәм халыкара базарлар өчен идарәчеләр әзерләүне күздә тота.

КИТТУ-КАИның «HR: оештыру үсеше һәм стратегик идарә» магистратура программасында белем алучы икенче курс студенты, «Казан моторлар җитештерү берләшмәсе» АҖнең мәгълүмати технологияләр департаменты бюросы башлыгы Артур Богданов үз фикере белән уртаклашты: «Сәнәгать предприятиесендә персонал белән идарә итү – предприятие эшчәнлегенең төрле якларын колачлаган катлаулы процесс. Бу эшчәнлек кеше ресурсларын планлаштыру, персоналны сайлап алу һәм яллау процессыннан башлап, аларның эш урынында иләшүен, вазыйфага керешеп китүен, шулай ук өйрәтү һәм үстерүне, кызыксындыру һәм социаль сәясәтне, хезмәт мөнәсәбәтләрен үз эченә ала. Сәнәгать предприятиесендә персонал белән идарә итүне цифрлаштыру бик мөһим. Цифрлаштыру нигезендә HR-бүлекнең нәтиҗәлелеге сизелерлек артырга мөмкин, аерым алганда, идарә эшенә чыгымнарны киметеп, хезмәткәрләр арасындагы үзара элемтәне яхшыртып, кеше ресурсларын төгәлрәк планлаштырырга юл ачыла. HR-бүлек эшендә типик документларны автоматлаштыру да бу эшнең нәтиҗәсе булып тора. Шул рәвешле бүлекнең ялыктыргыч бертөрле бурычлары юкка чыгачак һәм җитәкче үз кул астындагыларның көчен предприятиенең мөһимрәк мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлтә алачак, предприятиенең гомуми икътисадый нәтиҗәлелеген арттыру турында әйтеп тә торасы юк».

– Персонал белән идарә итүнең төгәл системага салынган булуы предприятие үсеше өчен бик мөһим. Еш кына әлеге юнәлеш әллә ни хезмәт чыгымнары һәм ресурслар таләп итмәгән, табигый юл белән формалашып, үз көенә бара торган өлкә дип кабул ителә, ләкин бу – ялгыш фикер. Җитәкчесе персонал белән идарә итү системасын үстерүгә аерым игътибар биргән предприятие хезмәт базарында уңышлы көндәшлеккә сәләтле, – ди «Казан» халыкара аэропорты» АҖнең персонал белән идарә итү хезмәте башлыгы Дарья Осенкова.

+ 8 (917) 920-81-85
GGMustafina@kai.ru

Фотография КИТТУ-КАИ тарафыннан тәкъдим ителде. РЕКЛАМА

ЦИФРЛЫ ФОРМАТТАГЫ ЫШАНЫЧЛЫЛЫК

Инновацияле технологияләр, идарә итүнең бердәм цифрлы мохите һәм үзебездә җитештерелгән сыйфатлы җиһазлар. Боларның барысына да Казандагы «Водозабор» подстанциясе киңкүләм реконструкция вакытында ия була. Реконструкцияне «Челтәр компаниясе» узган ел ахырында төгәлли.

Әлекке подстанциядән исеме генә калган дияргә була – асылда бу күп мөмкинлекләр бирелгән яңа, кулланучылар өчен бигрәк тә мөһим сыйфат – иң югары дәрәҗәдәге ышанычлылыкка ия объект. Хәер, атамасы да үзгәрә. Яңартканнан соң республикабыз башкаласында 110 кВ көчәнешкә ия өченче цифрлы подстанция саналган «Водозабор» бүген чирек гасырга якын Казан электр челтәрләрен җитәкләгән легендар шәхес Марс Баязитов исемен йөртә башлый. Объектларны энергетика тармагын оештыруга һәм аның үсешенә зур өлеш керткән шәхесләрнең исемнәре белән атау – «Челтәр компаниясе» АҖ нең күркәм традициясе. Аның мәгънәсе дә тирән: цифрлы технологияләр һәм инновацияле карарлар – замана таләбе, ләкин теләсә кайсы яңалыкны тормышка ашыручылар – кешеләр. Иң күркәм казанышлар нигезендә аларның профессиональ осталыгы, идарә итү таланты, үз эшләренә тугрылыгы ята. Ә иң фидакарьләрнең исемнәре – алга баручылар, булдырылганны камилләштерүчеләр өчен якты маяк.

Моңа бәйле рәвештә Марс Баязитов Казан электр челтәрләре директоры булып эшләгән заманда подстанциягә беренче (1937 елда кулланышка тапшырылганнан соң) җитди реконструкция үткәрелүе һәм 35 кВ лы подстанциянең көчәнеше 110 кВка кадәр арттырылуы да аерым мәгънәгә ия. Подстанцияне тагын бер мәртәбә яңарту чагыштырмача күптән түгел – 2008 елда уздырыла...

ЯҢАРТУ ҺӘМ ИМПОРТНЫ АЛЫШТЫРУ

Һәр заманның үз таләбе. Әһәмияте, куелган максат һәм бурычлары буенча бүгенге реконструкция – сыйфат ягыннан яңа этап. Өстәвенә, аны кулланучылар өчен бернинди дә чикләүләр кертмичә генә уздырырга кирәк була. Моның өчен проектлаштыру стадиясендә үк яңа җиһазларны җыюны һәм кулланышка кертүне этаплап, гамәлдәге куәтләрнең эшенә зыян китермичә башкарып чыгарга кирәк, дип билгеләнә. Әлеге бурыч җиңелләрдән түгел, әмма энергетика предприятиеләренең (генераль подрядчы оешма – «КЭР-Холдинг» ИК» ҖЧҖ), «СтройИнвест» ПСК» ҖЧҖ һәм «Челтәр компаниясе» АҖ хезмәткәрләреннән торган бердәм команданың көйләнгән эше нәтиҗәсендә моны башкарып чыгу мөмкин була.

Төзелеш вакытында объектта импортны алыштыру программасы да алып барыла. Подстанциягә трансформаторлар Екатеринбургтан, кайбер җиһазлар Великие Луки

Фото «Челтәр компаниясе» АҖ нән алынды

шәһәреннән кайтартыла, Татарстан җитештерүчеләре продукцияләренә дә ихтыяҗ була. Үзебездә ясалган сыйфатлы җиһазларны куллану туры килү-килмәү проблемасыннан котылырга булыша.

ОНЛАЙН-МОНИТОРИНГ БУЛЫШЫР

Марс Баязитов исемендәге яңа, 100 кВлы «Водозабор» подстанциясенең көчле яклары арасында – югары ышанычлылык, янгын һәм экология куркынычсызлыгының иң катгый таләпләренә туры килү. Мәсәлән, подстанциядән кулланучыга кадәр сузылган электр схемасының тотрыклы һәм ышанычлы эшләвен өч линиядән «туклануны» һәм резервны автомат рәвештә кушу мөмкинлеген күз уңында тоткан схема тәэмин итә. Шунысын да билгеләп үтик: инновацияле технологияләрне куллану 70 км дан артык бакыр кабельне экономияләргә булыша, алай гына да түгел, бу вакытта җиһазларның ышанычлылыгы да арта төшә.

Подстанция концепциясе иске системалардан баш тартуны һәм күп кенә җитештерү процессларын онлайн-мониторинглау кертелгән бердәм цифрлы идарә итү мохитен булдыруны күз уңында тота.

110 кВлы «Водозабор» подстанциясе, исегезгә төшерик, – Казанда әлеге көчәнеш классына караган өченче цифрлы подстанция: аңа кадәр 110 кВлы «Портовая» (2019) һәм «Азино» (2023) подстанцияләре файдалануга тапшырыла. Аларны төзегәндә тупланган

ТАТАРСТАНДА БЕРЕНЧЕ ИСЕМЛЕ ПОДСТАНЦИЯ 2014 ЕЛДА ПӘЙДА БУЛА: АЛАБУГАДА 500 КВЛЫ ПОДСТАНЦИЯГӘ РФ ЯГУЛЫК-ЭНЕРГЕТИКА МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ АТКАЗАНГАН ХЕЗМӘТКӘРЕ ЮРИЙ ЩЕЛОКОВ ИСЕМЕ БИРЕЛӘ. 2023 ЕЛДА 110 КВЛЫ «АЗИНО» ПОДСТАНЦИЯСЕ КАЗАН ЭНЕРГЕТИКА УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ЭЛЕККЕГЕ РЕКТОРЫ ФОРЕЛЬ ТИНЧУРИН ХӨРМӘТЕНӘ АТАЛА БАШЛЫЙ. УЗГАН ЕЛ АХЫРЫНДА ТАТАРСТАННЫҢ ЭНЕРГЕТИКА КАРТАСЫНДА МАРС БАЯЗИТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ 110 КВЛЫ «ВОДОЗАБОР» ҺӘМ ФЕДОР КАЗАЙКИН ИСЕМЕНДӘГЕ 110 КВЛЫ «СОКУРЫ» ПОДСТАНЦИЯЛӘРЕ БАРЛЫККА КИЛӘ.

тиңдәшсез тәҗрибә объектны сәнәгый кулланышка уңышлы кертүгә бик зур этәргеч бирә. Бүген Татарстанда әлеге типтагы объектларны төзегәндә куллану өчен типлаштырылган карарлар эшләнгән.

«Водозабор» подстанциясе белән беррәттән, ТРның Лаеш районында 110 кВлы яңа «Сокуры» подстанциясе дә эшли башлый. Бу – заманча, югары технологияле подстанция, аның белән шулай ук читтән торып идарә итеп була. «Опора плюс» ҖЧҖ генераль подрядчы булып тора.

«Сокуры» подстанциясенә Татарстанның тагын бер легендар энергетигы Федор Казайкин исемен биреләр. Ул чирек гасыр дәвамында Идел буе электр челтәрен җитәкли. Предприятиедә барган колачлы үзгәреш-үсеш тә әлеге исем белән бәйләнгән, аның җитәкчелегендә 35-110 кВлы 44 подстанция, 12 электр бүлү пункты һәм җиде мең километрдан артык һава электр линиясе төзелә. Кызганыч, гыйнвар башында 95 яшьлеген билгеләп үткән Федор Иванович үзе генә әлеге подстанция ачылышында катнаша алмый. Шулай да ул бераз соңрак үз исемендәге подстанциягә килә һәм, филиал җитәкчеләре белән бергә объектны карап йөргәндә, үзе җитәкчелек иткән елларда ук бу урында шундый энергообъект төзү идеясе булуын искә ала...

ИСЕМЛЕ ПОДСТАНЦИЯЛӘР – ХӨРМӘТ БИЛГЕСЕ

Эшләнгәннәрдән ул канәгать кала. Тулысынча үзебездә ясалган җиһазлардан торган «Сокуры» подстанциясе Сокуры, Олы Кабан, Обухово, Кызыл Ил, Зимняя Горка, Бима кебек торак пунктларны, шулай ук эре сәнәгать кулланучыларын электр энергиясе белән ышанычлы һәм сыйфатлы тәэмин итү мөмкинлеген бирәчәк.

– «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең энергетика кластерларын үстерү һәм кирәкле җиһазларны заманча, югары технологияле итеп җитештерүне җайга салган республика предприятиеләре белән тыгыз хезмәттәшлек итү юнәлешендәге сәясәте Татарстанның электр челтәрләре комплексының ышанычлы һәм тотрыклы эшләвенең нигезе булып кала, – диде подстанция ачылышында ТР Премьер-министры Алексей Песошин. Ул шулай ук «Челтәр компаниясе»нең 2024 елда Татарстанда узган кайбер эре халыкара чараларны электр энергиясе белән өзеклекләрсез тәэмин итүен дә билгеләп үтте.

– Һичшиксез, «Челтәр компаниясе» ирешкән уңышлар, ул туплаган тәҗрибә һәм куәт республика икътисадының һәм социаль өлкәләренең үсешен тәэмин итү бурычларын уңышлы үтәү нигезе булып тора! – дип йомгак ясады Премьер-министр.

Бүген Татарстанда энергетика системасының тотрыклы һәм ышанычлы эшләве – күп очракта тармак ветераннарының, берничә буын энергетикларның, беренче чиратта «Челтәр компаниясе» АҖ генераль директоры Илшат Фәрдиевнең тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Подстанцияләргә легендар энергетикларның исемнәрен бирү исә – аларга карата булган хөрмәтебезне һәм рәхмәтебезне белдерү билгесе.

ХАЛЫК ПРЕДПРИЯТИЕСЕНЕҢ ХАЛЫК ДИРЕКТОРЫ

Сәгать алтыда ул инде эштә. Көн саен предприятиене урап чыгу – мәҗбүри. Үзендә эшләгән 1650 кешенең һәркайсын таный, һәрвакыт ягымлы һәм ачык. Эшкә урнашучының һәрберсе белән шәхсән үзе сөйләшә.
Таныш булыгыз: халык предприятиесе – С.П. Титов исемендәге Яр Чаллы картон-кәгазь комбинатының генераль директоры Андрей Фомичёв.

Россиянең иң зур халык предприятиесен Андрей Геннадьевич 10 ел элек җитәкли башлый. Предприятие күп яктан уникаль. Ихтыяҗ зур булган продукция җитештергән өчен генә дә түгел. Аның хезмәткәрләренең икътисадый һәм социаль иминлегенең нигезе – хуҗалык итүнең коллектив формасында, ягъни комбинатның 100% акциясе дә шунда эшләгән хезмәткәрләрнеке.

Яр Чаллы картон-кәгазь комбинаты Россия целлюлоза-кәгазь сәнәгатенең ун иң зур предприятиесе арасына керә. Комбинатны 1981 елның гыйнварында төзи башлыйлар, ә предприятиенең беренче чираты – картон фабрикасы – 1986 елның декабрендә кулланышка тапшырыла. Комбинатта җитештерүне төптән модернизацияләү бара, һәм картон-кәгазь комбинаты хаклы рәвештә инновацияле технологияләр һәм җиһазларны кертү буенча тармак лидеры санала.

Бүген комбинат – Яр Чаллыда «КАМАЗ» ГАҖ дан кала, бюджет оештыру буенча икенче предприятие. Хәер, аны инде гади предприятие дип тә атап булмый. Картон-кәгазь комбинаты – үз санаторие-профилакторие, ял базасы, теплица хуҗалыгы, үз янгын часте, заманча ашханәсе, «Бумажник» Балалар мәдәният сарае булган кечкенә шәһәрчек.

ТРАДИЦИЯ ҺӘМ ПРОФСОЮЗГА ТАЯНУ

Комбинат турында сөйләгәндә, Андрей Фомичёв, һичшиксез, бүгенге уңышларга һәм социаль гарантияләргә нигезне предприятиенең беренче директоры – легендар Сергей Павлович Титов салган булуына басым ясар. Барысы да шулай, тик дәвамчыларның үзләренә кадәргеләрнең казанышларын «уңышлы» пыран-заран китерүенә мисаллар азмыни?

Бәхеткә, биредә андый хәл булмый. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Андрей Геннадьевич КБК ветераннары салган күркәм традицияләрне дәвам итә һәм, бүгенге вазгыятьне исәпкә алып, җитештерүне оештыруга шактый зур яңалык, прогрессив өлеш кертә. Дөресен әйткәндә, башкача булуы да мөмкин түгел – Андрей Фомичёв өчен комбинат үз гаиләсе кебек: биргә 40 ел элек, ерак 1986 елда – предприятиенең беренче чираты эшләп киткән көннәрдә килә. Гади механиктан генераль директорга кадәр булган хезмәт юлын уза.

Халык предприятиесенең көчле буыны – аның профсоюз оешмасы. Предприятиенең барлык хезмәткәрләре профсоюз әгъзалары санала. Фомичёв профсоюз белән ничек эшли? Үзара аңлашып. КБК җитәкчелеге һәм профсоюз оешмасы – хезмәткәрләр көнкүрешенең барлык мәсьәләләрен хәл итүдә тигез хокуклы социаль партнерлар. Һәрхәлдә, бергәләп хәл итәргә туры килгән чираттан тыш мәсьәләләр алай ук күп түгел. Чөнки генераль директор, коллектив раславынча, үзе профсоюз әгъзасы буларак, бернәрсәне дә «соңыннанга» калдырмый. Профсоюз үз тәкъдимнәрен кертә, эш бирүче белән сөйләшүләр алып бара, ә КБКның коллектив килешүе – үзе бер фолиант.

– Бер-беребезне беренче сүздән үк аңлап эшлибез, – диде профсоюз оешмасы рәисе Римма Ризванова. – Бу куркынычсызлык техникасы, матди ярдәм, гуманитар ярдәм яки ниндидер чаралар уздыру мәсьәләсе булсынмы, башка әйберме. Әгәр кеше шәхси проблемасы белән профкомга килә икән, мин аның белән директорга барам, чөнки ул һичшиксез хәл итү юлын табачак, дип ышанам. Бездә генераль директорга керү өчен язылырга кирәкми. Әгәр ул урынында икән, һичшиксез кабул итәчәк.

АНДРЕЙ ГЕННАДЬЕВИЧ ФОМИЧЁВ

«С.П. Титов исемендәге Яр Чаллы картон-кәгазь комбинаты» Халык предприятиесе генераль директоры. 2016 елдан 2024 елга кадәр – ТР Дәүләт Советы депутаты. «Югары конкурентлыкка сәләтлелек өчен» номинациясендә «Ел җитәкчесе» конкурсы лауреаты (2017 ел). II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, РФ Кораллы Көчләре Генераль штабы башлыгы грамотасы, Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале, «Профсоюз алдындагы казанышлары өчен» билгесе, «Татарстан Республикасында Профсоюз алдындагы казанышлары өчен» мактау билгесе белән бүләкләнгән.

Фото: nkbk.ru. РЕКЛАМА

СОЦИАЛЬ ПРОГРАММАЛАР КӨЧЕ

Комбинатта гаиләләргә тәгаенләнгән кайбер үз социаль программалары гамәлдә. Алар арасында – яшьләр өчен торак программасы, бала туу уңаеннан яшь гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү, махсус хәрби операциягә киткән хезмәткәрләр гаиләләренә булышу.

Күп кенә социаль программаларны, сүз уңаеннан, Фомичёв үзе башлап җибәрә. 2015 елда директор урынына билгеләнгәннән соң, беренче көннәрдә үк ул яшьләргә өйләнешү, беренче һәм аннан соңгы балалар туу уңаеннан, шулай ук опекуннарга һәм тәрбиягә бала алган гаиләләргә саллы матди ярдәм күрсәтү тәкъдимен кертә. Узган елда, сүз уңаеннан, әлеге түләүләр шактыйга арттырыла. Лаеклы ялга китүче пенсионерлар да матди ярдәм формасында «бонус»ларга ия була, 15 һәм аннан да күбрәк ел эшләгәннәргә предприятие пенсияләренә өстәмә акчалар түли.

Комбинатта үз торак программасы да эшли. Предприятиедә өч ел эшләгән яшь хезмәткәрләргә торак алу өчен процентсыз займ бирелә.

ҮЗ ӘРНҮЕҢ КЕБЕК

Махсус хәрби операция башлануга, Фомичёв, өстән карарлар көтеп тормыйча: «Егетләребез мобилизацияләнгән очракта, аларны эшләреннән чыгармаячакбыз. Эш урыннары сакланып калачак. Алар безнеке, алар да безнең кебек үк акционерлар һәм хуҗалар», – дип белдерә. Шунда ук аларның гаиләләренә булышырга тәкъдим итә, гаиләләргә ярдәм түләнә дә башлый. «Махсус хәрби операция тәмамлангач, без һичшиксез үзебезнең сугышчыларыбыз хөрмәтенә Дан аллеясе ясаячакбыз, ә җиңүче егетләребезне гаиләләре белән бергә үзләре теләгән җиргә ял итәргә җибәрәчәкбез», – ди генераль директор. Һәм моның шулай булачагына беркем дә шикләнми: Фомичёв һәрвакыт сүзендә тора. Ул инде хәзер үк комбинатның санаторий-профилакториенда сугыштан кайтучылар өчен тернәкләндерү программасын булдырырга кушкан. Комбинаттан даими рәвештә безнең сугышчыларга гуманитар ярдәм китеп тора.

Һәр хезмәткәренең борчуын, әрнүен Фомичёв үзенеке кебек кабул итә. Ул ярдәм кулы сузган кешеләрнең исемнәрен санап бетереп булмый. Фомичёв – Яр Чаллыда Инвалидларны тернәкләндерү үзәгенең Попечительләр советы рәисе дә, һәм беркайчан да игелекле гамәлләрен кешегә күрсәтеп эшләми. Кемнән сорасагыз да, Фомичёвның беркайчан да кешегә ярдәм итүдән баш тартканы юк, диячәк.

Андрей Геннадьевич үз хезмәткәрләре язмышына, комбинатта барган вакыйгаларга битараф түгел, ул шул казанда кайный. Бу хакта гаҗәеп бер факт та сөйли. Берничә ел элек комбинатның «Титов исемендәге разведка» дип аталган эзтабарлар отряды 1941–1944 елларда Карелия фронтында хәбәрсез югалган солдатларны эзләү экспедициясендә катнаша. Генераль директор, отрядның гап-гади әгъзасы кебек, сазлыклы урындагы катлаулы шартларда, үз предприятиесе хезмәткәрләре белән бергә палаткада яши, башкалар белән бергә совет сугышчыларын эзләүдә катнаша.

Зыялы, тыйнак, эрудицияле, әдәпле, исеме зур хәрефтән язылырга тиешле шәхес. Фомичёв турында шулай диләр. Ул классик музыка ярата, матур әдәбият укый, илдәге һәм дөньядагы барлык яңалыклардан хәбәрдар. Җиде онык үскән зур гаиләсе һәм комбинатның хезмәт коллективы – аның горурлыгы, ышанычы һәм таянычы.

«ВАКЫТ СЫНАВЫН УЗГАН ЫШАНЫЧЛЫЛЫК»

«Мин Чаллының уникаль халык предприятиесенең безнең тармак профсоюзында торуын бик югары бәялим, – ди Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү хезмәткәрләренең гомумроссия профсоюзының Татарстан республика оешмасы рәисе Ольга Калашникова. – Андрей Геннадьевич белән күптән таныш, аны яхшы беләм. Бу кешенең энергиясенә, миһербанлылыгына, зирәклегенә, эчке көченә һәм кешелеклелегенә гаҗәпләнүдән туктамыйм».

Ольга Анатольевна сүзләренә караганда, комбинатта асылда хезмәт мөнәсәбәтләренең һәм хезмәткәрләрне социаль яклауның профсоюз идеалы гәүдәләндерелгән.

«Хезмәткәрләр, югары хезмәт хакы алып, яхшы шартларда эшлиләр, биредә заманча җитештерү оештырылган, табыш гадел бүленә, җитәкчелек һәм хезмәткәрләр арасында тигез хокуклы мөнәсәбәтләр урнаштырылган, профсоюз оешмасының статусы югары, хезмәткәрләр турында һәрьяклап кайгырталар һәм, нәтиҗәдә, җитештерү күрсәткечләре югары, комбинат конкурентлыкка сәләтле продукция чыгара, – ди Ольга Калашникова. – Һәм, әлбәттә, бу күбесенчә халык предприятиесенең идеологиясе һәм аның җитәкчесенең намуслы булуы нәтиҗәсендә. Республикабызның горурланырлыгы бар: бездә шундый уникаль предприятие һәм Андрей Геннадьевич Фомичёв кебек чын халык җитәкчесе бар».

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Мәнгелек
Игелекле
Әһәмияте
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Финансовая грамотность
Реклама 16+

игелекле
эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

акыллы
гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Каюм Насыйри **нинди** мирас калдырган

Язучы Марат Кәбиров **нәрсәләр** укый

Казанда **нинди** күргәзмә ачылды

КАЮМ НАСЫЙРИ

БАКЫРДА, КӨМЕШТӘ, ТАШТА, ХӘТЕРДӘ...



Луиза Янсуар

Каюм Насыйри – фәндә дә, әдәбиятта да, мәгариф өлкәсендә дә беренчеләрдән булып эз салучы новатор, реформатор. Үзеннән соң 60 тан артык фәнни эш, олы әдәби мирас калдыра ул. Быел аның тууына 200 ел тулуны билгелибез.

Бу кадәр өлкәне кем генә берүзе колачлый алыр иде икән: химия, медицина, фармацевтика, арифметика, фольклор, геометрия, география, педагогика, табигать белеме, тарих, тел белеме, әдәбият, тәнкыйть, тәрҗемә, дин гыйлеме, кулинария һ.б. Еллар узган саен Насыйриның заманыннан алда туганына һәм аның киләчәгенә ныклы фундамент салып калдырганына ныграк инанабыз. Ул бит әле – гомерен балаларга багышлаган мөгаллим, остаз да.

КАЮМ БАБАЙ ТӘҢКӘСЕ

Нәселе борынгы Болгарга – ханнар заманына барып тоташкан Насыйриның шәҗәрәсе кадерләп Казандагы музеенда саклана. Юкка гына «Әл-Ширдани», «Әл-Болгари» тәхәллүсләрен еш һәм яратып кулланмаган әдип. Төрки-татар тарихын энәсеннән җебенә кадәр өйрәнеп, безгә дә җиткергән, шул ук вакытта үткәнгә түгел, ә киләчәккә карап фикер вә эш йөрткән.

«Каюм бабайның» 150 еллыгын бәйрәм иткәндә сурәтен инде маркаларда мәңгеләштергән, конверт тышларында чыгарган булсалар, хәзер чират тәңкәгә җитте.

– Тәңкәдәге Насыйри сурәте тарихи яктан да, сәнгати яктан да халык күңелендә уелып калган образга тәңгәл килсен өчен, экспертларны чакырып, аларның профессиональ фикерләрен тыңладык, – дигән иде әле ясалу этабында ТР мәдәният министры Ирада Әюпова. Менә, ниһаять, 15 гыйнварда, Камал театрының яңа бинасында узган Мәдәният министрлыгының чираттагы коллегиясендә, ул халыкка тәкъдим дә ителде.

МУЗЕЙЛАРДА НИЛӘР БАР?

Каюм Насыйриның Казанда музей-йорты эшләп тора – ул ТР Милли музееның филиалы. Мәркәзебезнең иң үзәгендә – Иске Татар бистәсендә урнашкан. Хәзерге Париж Коммунасы урамы, элеккеге «Печән базары» – татар бистәсе гөрләп торган, татарлар күмәкләп яшәгән тарихи җирләр. Насыйри монда җиң сызганып хезмәтләрен язган, мөгаллимлек иткән, урамнарында һәм кешеләр тормышында җуелмас эзләрен калдырган.

Тарихи-архитектура һәйкәле, 1979 елда бина янгын вакытында көлгә әверелгәч, шул ук нигез урынында 1991–1995 елларда яңадан торгызыла. Каюм Насыйриның туганы Мөхәммәтбәдигъ Хөсәеновның XIX гасырның 50–60 нчы елларында төзелгән бу йорты – Казанда беркайчан да үз өе-почмагы булмаган галимнең яшәгән соңгы урыны. Мөхәммәтбәдигъ Хөсәенов үзе исә ерак түгел генә урнашкан Ак мәчеттә (хәзерге «Галия» мәчете) азанчы булган.

Иске Татар Бистәсенең тарихи үзәген кистереп узган җәяүле урам үзе дә Насыйри исемен йөртә, ул Татарстан урамыннан башлап Сафьян урамына кадәр сузыла. Бу – элек-электән татар аксөякләре һәм бай сәүдәгәрләре, шулай ук югары катлам руханилары яши торган урыннар.

Насыйриның икенче музее – туган туфрагында, Кече Ширданда. Әлеге музей-китапханә мәгърифәтченең 196 еллыгына ачылган иде. Аны җирле энтузиаст – Татарстанның атказанган төзүчесе Асия Гобәйдуллина башкарып чыкты.

200 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН РОССИЯ БАНКЫ ТАРАФЫННАН БАСЫЛГАН «МӘГЪРИФӘТЧЕ-ГАЛИМ КАЮМ НАСЫЙРИ» КӨМЕШ ТӘҢКӘСЕ – «РОССИЯНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕ» СЕРИЯСЕНЕҢ ДӘВАМЫ. ТӘҢКӘДӘ – ГАЛИМ, МӘГЪРИФӘТЧЕ КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ КИТАПЛАР ФОНЫНДА ЯСАЛГАН БАРЫБЫЗГА ДА ТАНЫШ ПОРТРЕТЫ.

Фото: ТР Милли музее фондларыннан.

Биредә шулай ук XX йөз башында төзелешенә Каюм Насыйри үз көчен керткән мәчет тә реставрацияләп бетерелде. Алдагы буыннарга Насыйри мирасын җиткерү һәм туган ягына эзне суытмау өчен тырышалар шырданлылар, аның чорыннан калган уникаль объектлар кадерләп саклана: Каюм Насыйри су эчкән кизләү, 500 яшьлек карт карама, борынгы «Каюм коесы» һәм, әлбәттә инде, гаҗәеп матур мәчет.

БАБАСЫНЫҢ 100 ДӘН АРТЫК КОРЪӘНЕ...

Габделкаюм Габденасыйр улы Насыйров 1825 елның 2 (14) февралендә Казан губернасы Зөя (Свияжск) өязе Югары Шырдан авылында дөньяга килә. Әтисе Габденасыйр белән бабасы Габделхөсәен – тирән рухани белемле кешеләр. Бабасы Изге китапны күчереп язучы була, Коръәннең 100 дән артык нөсхәсен ясый. Алар гарәп теле дәреслекләре, уку әсбаплары төзүчеләр буларак та тарихка кереп калган. Башлангыч белемне кечкенә Каюм әтисеннән ала. Аннары, 16 яшендә, аны Казандагы атаклы «Сәгыйть мәдрәсәсе»нә укырга бирәләр. Биредә Каюм иман нигезләрен, гарәп-фарсы телләрен өйрәнә, ә дөньяви фәннәрне исә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә үзләштерә.

Әтисе дә, бабасы да рус телен яхшы белгәнлектән, Мәскәү белән хезмәт ягыннан бәйләнешләре булганлыктан, бәләкәй Каюм да бу телне белеп үсә. Инде галим вә әдип булып җитешкәч тә, Каюм Насыйри рус даирәсе вәкилләре, бигрәк тә галим-голамә белән күп аралаша. Бистә халкы аның үзен бик хөрмәт итсә дә, рус телен кирәк дип исәпләвен, җитмәсә әле, «русча» киенүен бик үк өнәп бетерми.

ГАЛИМНЕҢ БУЛМАГАН ФОТОЛАРЫ ҺӘМ ПОРТРЕТЫ

Музеендагы язу өстәлендә, язу әсбапларыннан тыш, керосин лампасы, шәмдәл, кубыз, курай бар. Диварга скрипка, мандолина эленгән. Замандашлары теркәп калдырган истәлекләрдә Каюмның уен коралларында уйный белүе, музыкага һәвәс кеше икәнлеге искә алына.

Каюм Насыйри бер күзгә сукыр, берсенә кылыйрак булган, диләр. Әмма болар – сөйләүләре буенча гына. Чөнки аның үзе исәндә төшкән фотографиясе сакланып калмаган. Насыйриның бик ыспай, көяз киенеп шәһәр урамнарында йөрүен дә хәтерләүчеләр була. 1944 елда әдипнең юбилее уңае белән комиссия төзелә һәм рәссам Байназар Әлменовка аның портретын ясарга заказ бирәләр. Тарихка охшаш булып кереп калсын өчен, төс-кыяфәте Каюмга тартым туганын дәшеп китерәләр. Ясалып

беткәч, портретны Шырдан кешеләре белән Насыйрины еш кына атында йөрткән берәүгә күрсәтәләр. Алар портретны хуплый. Шәкертләренең берсе хәтта: «Растан да, Каюм абзый бит бу!» – дип кычкырып ук җибәрә, имеш.

КЫРЫС МӨГАЛЛИМ

15 ел мәдрәсәдә укыганнан соң, пишкадәм Каюм әле университетка ирекле рәвештә лекцияләр тыңларга да йөри. Мәдрәсәдә уку аңа төрки-мөселман мәдәнияте, Көнчыгыш гыйлеме, фәлсәфәсе турында тирән белем бирсә, Казан университетындагы рус галимнәре белән аралашу Европа дөньясына ишекләр ача. 1855 елда православ рухани уку йортына – Казан руханилар училищесына һәм Казан руханилар семинариясенә татар теле укытырга чакырып алына, 1871 елга кадәр укыта. Шуннан соң татар балаларына рус телен өйрәтү өчен үз мәктәбен оештыра. Кырыс мөгаллим була, татар телен җиренә җиткереп үзләштерүләрен таләп итә. Моны ул заманның документлары раслый: 10 баллы системадан иң шәпләргә дә Насыйри 8 баллдан югарырак бәя куймаган. 1876 елда Казан уку-укыту округының татар, башкорт, казах мәктәпләре инспекторы Василий Радлов белән укыту методикасы мәсьәләсендә бер фикергә килә алмыйча, мәктәпне ташлап китә.

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ЭТНОГРАФИЯДӘН КӨЗГЕ ЯСАУГА КАДӘР

Үзен тулаем әдәби һәм гыйльми эшчәнлеккә багышлый. Бу елларда Насыйри иң яхшы әсәрләрен иҗат итә. Шәхси дәресләр бирә, татар документларын русчага тәрҗемә итә, китаплары сатылудан кергән акчага көн күрә. Гуманитар фәннәрнең төрле тармаклары үсешенә зур өлеш кертә, хәзерге татар әдәби теленә, аның фәнни терминологиясенә нигез сала. «Казан Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» мәҗмугасында рус телендә татар этнографиясенә караган мәкаләләре дә даими басылып килә. Насыйри хезмәтләре турында рус матбугатында үз чорының иң мәртәбәле галимнәре язып чыга. Замандашлары әйтүе буенча, Насыйри эш вакытын төгәл бүлә һәм оештыра белә. Акыл хезмәте белән физик хезмәтне дә аралаштырып бара.

Кулыннан җитмеш төрле һөнәр килгән: ул китаплар төпләп ябыштыра, көзгеләр ясый, агач эшенә бик оста була, крахмал кайната, кулинария белән халык медицинасын, дару үләннәрен яхшы белә. Боларның барысын да хезмәтләрендә, бигрәк тә календарьларында теркәп, халыкка җиткерергә омтыла. Картайган көнендә, паралич суккач, Насыйри үзе өчен махсус күнекмәләр уйлап таба, моңа өстәп, электр тогы кулланып та дәвалана. Күпмедер вакытка аякка да баса.

БЕРЕНЧЕ МАТЕМАТИКА ҺӘМ ГЕОМЕТРИЯ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕ

Халык телен гадиләштерү, гарәп-фарсы алынмаларыннан арындыру максатыннан, татарча атамалар уйлап таба: «сан», «кушу», «аеру» һ.б. Шулай итеп, татарча дәреслекләргә һәм методологиягә нигез салына. Алга таба әдәбият та, фән дә халыкка якыная, аңлаешлырак була. XX йөз башында Насыйри эстафетасын башка галимнәр эләктереп ала.

192 дару үләнен, 155 төр авыруны алар ярдәмендә дәвалауны язып калдыра. Татар Бистәсендәге музеенда хәзер дә дару үләннәрен үстерәләр. Асылда, Каюм Насыйриның әлеге хезмәтләре белән календарьлары беренче милли энциклопедияләр була да инде. Шуңа без аны татарда тәүге энциклопедияләргә нигез салучы буларак та олылыйбыз.

ФОЛЬКЛОР ҺӘМ «ӘБҮГАЛИСИНА»

Каюм Насыйри – беренче татар этнографы. Ул төрки-татар дөньясындагы йолалар, иямләр, ырымнар, фольклорны теркәп кенә калмый, ә анализлый, классификацияли дә. Аның туплаган байлыгына таянып, нигезләнеп, 1910 елда Яков Коблов атаклы «Казан татарлары мифологиясе» хезмәтен яза. Бу өлкәдә инде күп тикшеренүләр булса да, без хәзер дә Насыйри чыганагына даими мөрәҗәгать итәбез, чөнки ул халыктан ишеткәнне аутентик чагында теркәп алып калдыра.

Ислам дөньясы тарихындагы бөек галимнәрнең берсе, табиб, философ һәм әдип Әбү Гали Хөсәен ибн Сина (Әбүгалисина), Каюм Насыйриның атаклы риваятенә бәйле рәвештә, татар халкының иң яраткан каһарманнарының берсе булып китә. Мәгарәдә белем эстәгән Әбүгалисина һәм Әбелхарис турындагы әсәрне белмәгән татар баласы юк. Насыйри аны Көнчыгыш легендалары вә әсәрләренә нигезләнеп, безнең җирлек өчен махсус иҗат итә. Ул күп еллар халыкта кулъязма рәвешендә һәм, кыйсса булып, телдән-телгә күчеп йөри.

КАЮМ НАСЫЙРИ ДӘВАМЧЫЛАРЫ: ТӘВӘККӘЛЛӘР ЮЛЫ

Казанның Татарстан урамындагы Каюм Насыйри музее янында урнашкан белем учагы – 80 нче мәктәп турында белмәгән-ишетмәгән кеше юктыр. Беренчедән, ул үзен тәмамлап чыккан яисә язмышы аның белән бәйле танылган кешеләре белән билгеле: Таһир Якупов, Ладимер Иванов, Лена Шагыйрьҗан, Рада Нигъмәтуллина, Булат Хәмидуллин һ.б. Икенчедән, менә инде берничә ел дәвамында ул Каюм Насыйри исемен йөртә һәм аның традицияләрен саклап, мирасын мәңгеләштерү юлында уңышлы эшләп килә. Өченчедән, мәктәпнең уңыш-казанышлары гаҗәеп актив, үз эшенең чын остасы булган милләтпәрвәр шәхес – Роберт Мансуров белән турыдан-туры бәйле.

РОБЕРТ МИЯССӘР УЛЫ МАНСУРОВ
1958 елның 3 маенда Кукмара районының Ятмас-Дусай авылында туа. Башлангыч белемне туган авылында ала, аннары Березняк урта мәктәбендә укый, урта мәктәпне Мамадыш районы Түбән Тәкәнеш авылында тәмамлый. 1976–1979 елларда Хәрби диңгез флотында хезмәт итә, беренче статьялы старшина була.
1984 елда Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлый. Институтта «Яшьлек» («Юность») студентлар төзелеш отрядын җитәкли. Томск өлкәсендә Стрежевой шәһәрендә Бөтенсоюз удар комсомол төзелешендә катнаша.
Мәгариф системасында 45 еллык хезмәт стажы бар. 1984 елдан укытучыдан алып мәктәп директорына, район мәгариф бүлеге җитәкчесенә кадәр булган хезмәт юлы уза.
1988–2017 елларда Кукмара муниципаль районының мәгариф идарәсе җитәкчесе булып эшли, 2017–2020 елларда – Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары-мәгариф идарәсе башлыгы вазыйфасында. 2021 елдан – Казан шәһәрендәге 80 нче мәктәптә директор.

Фотолар Роберт Мансуровның шәхси архивыннан

«АЛДЫБЫЗДА БИТ – КАЗАН...»

Роберт Мияссәр улы Казанга югалтулар ачысын һәм зарын татып килә. Коронавирус афәте гаиләләрен читләтеп узмый, ул тормыш иптәшен – атказанган педагог, үзе кебек үк гомерен балаларга багышлаган Розалия Илгизәр кызын югалта. Үзе дә аяусыз авыру белән бик кискен көрәшә.

– Тормышыбыз гаилә булып яши башлаганнан бирле гел мәктәптәге уңышларны да, борчуларны уртаклашып, киңәш-табыш итешеп, бер-беребезгә терәк-таяныч булып узды. Башкача булуын күз алдына да китереп булмый иде. Кукмарадагы бәхетле елларыбызны еш искә алам, – ди Роберт Мияссәр улы. Әмма ул югалтулардан да көчле булып чыга алган зат, табигате шундый, күрәсең: эшләргә, эшләргә, эшләргә...

Кызларының берсе – Яшел Үзәндә, икенчесе – Казанда. Роберт Мияссәр улы, алдына максат куеп, Казанга килергә, мәгариф өлкәсе белән милләткә хезмәтен башкалада дәвам итәргә көч таба. 80 нче мәктәптә вакансия барлыгын белгәч, озак уйлап тормый, тәвәккәлли.

Килүең – бер хәл, ә менә зур идеяләр, планнар белән янып, тирәндәге бөтенләй яңа кешеләрне кузгатып, рухландырып җибәрә алу – һәркем дә башкарып чыга торган эш түгел. Аның тормыш һәм хезмәт юлы, чыннан да, тәвәккәлләр юлы. Юкка гына Россия һәм Татарстанның атказанган төзүчесе, дүрт орден кавалеры – этисе Мияссәр Мансур улының һәм әнисе Наҗия Гаян кызының акыллы, зирәк киңәшләрен, балачакта ук сызган кыйбласын еш искә алмыйдыр Роберт Мияссәр улы:

– Ул безне намуслы, тырыш, максатчан кеше булырга һәм укытучының авыр хезмәтенә олы ихтирам белән карарга өйрәтте. – ди. – Мин шуңа мөгаллим булырга тәвәккәлләдем. Шулай ук мәктәп мәгариф системасына килүдә Березняк мәктәбе директоры, легендар укытучым Харис Ваһаповның роле зур булды.

«ӘЙ, КУКМАРА, КУКМАРА...»

Кукмарадагы белем учакларын саклау һәм үстерү, аларны яхшы педагогик кадрлар белән тәэмин итү, матди базаны ныгыту буенча бик күп көч куя Роберт Мияссәр улы. Нәкъ менә ул җитәкчелек иткән вакытта укыту һәм тәрбия бирү процессына милли-төбәк компоненты тирәнтен кертелә. Республикаларда беренчеләрдән булып бөтен районда мәгълүмат технологияләре кулланыла башлый.

Республика күләмендә мәгариф өлкәсен оптимальләштергәндә, Кукмара районындагы барлык мәгариф учреждениеләрен саклап калуга ирешә алар. Шул рәвешле, күпсанлы милләт вәкилләреннән торган районда белем бирү процессына хилафлык, зыян килми. Ә бит бик яхшы беләбез: мәктәп калмаса, балалар читкә барып укырга мәҗбүр ителсә, авыллар да күз алдында таркала. Биредә татар, рус, удмурт, мари һ.б. халыклар яшәгән авылларда исә мәктәпләр эшләвен, ә халык үз ритмында яшәвен дәвам итә. Яшьләрнең туган туфрагына әйләнеп кайтып төпләнүе дә шушының белән бәйле.

Роберт Мияссәр улы мәгариф системасы белән җитәкчелек иткән елларда районда эксплуатациягә 50 бина тапшырыла, биналарның 95% ы капиталь ремонт һәм төзекләндерүне уза, моннан тыш, өр-яңа 16 мәгариф учреждениесе нигездән торгызып аякка бастырыла. Болар – урта мәктәп һәм гимназияләр дә, һөнәри лицейлар белән көллиятләр дә, «балалар бакчасы – мәктәп» тибындагы комплекслар да, аерым предметларны тирәнтен үзләштерү өчен каралган мәктәпләр дә, өстәмә белем бирү учреждениеләре дә, мәгариф үзәкләре дә.

КОЛАЧЛАП БУЛМАСТАЙНЫ КОЛАЧЛАП...

2018 елда Кукмара муниципаль районы республикабызда беренче булып иң югары бүләк – «Татарстан Республикасы каршындагы хезмәтләре өчен» ордены белән бүләкләнде. Бу бүләкне алуда район мәгариф системасының, педагогик коллективларның, җитәкчеләрнең дә өлеше зур. 2018 елда күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Татарстан Президенты Указы белән ТРның «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләделәр Роберт Мияссәр улын. Бу – аның күпсанлы бүләкләренең һәм дәрәҗәле исемнәренең берсе генә: «Халык мәгарифе отличнигы» күкрәк билгесе, РФнең атказанган укытучысы, «Казанның 1000 еллыгы» медале, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты исеме, «Кукмара муниципаль районы каршындагы казанышлары өчен» медале, «Кукмара районының мактаулы гражданины» исеме һ.б.

Озак елларга сузылган педагогик хезмәтен фәнни эшчәнлек белән дә тыгыз үреп алып бара Роберт Мияссәр улы. Үзе тынгысыз эзләнү юлында булгач, райондагы укытучыларның фәнни омтылышларына да киң колач бирә һәм зур мөмкинлекләр тудыра. Аның турыдан-туры инициативасы белән күпсанлы халыкара, федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге чаралар оештырыла. Боларга уку-укыту һәм методика өлкәсендәге семинарлар, симпозиумнар, фәнни-гамәли конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, эксперименталь тикшеренүләрнең нәтиҗәләре буенча үткәрелгән апробацияләр дә керә. Федераль дәрәҗәдәге вузлар һәм республиканың иң мәртәбәле уку йортлары белән хезмәттәшлек итеп, аларның әйдәп баручы галимнәрен җәлеп итү, квалификация күтәрү, педагогик кадрларны өр-яңадан әзерләү буенча аларның профессиональ ярдәменә таяну – Кукмарада мәгариф системасында боларга зур әһәмият бирәләр.

Роберт Мияссәр улы Россия табигать фәннәре академиясенә «Россиянең тотрыклы үсеш проблемалары» секциясенә мөхбир-әгъзасы буларак кабул ителә, ул шулай ук – РТФА (РАЕН) Татарстан бүлегендә фәнни сәркатип, җитәкче булып тора.

Зур белемле педагог һәм методик юнәлештә армый-талмый эзләнүче тикшеренүче буларак, боларга үзенең тирән җитәкчелек тәҗрибәсен дә кушып җибәреп, Роберт Мияссәр улы үз тәҗрибәсе белән бик рәхәтләнеп уртаклаша. Аның саллы мәкаләләре белән язмалары үзәк һәм республика басмаларында даими басылып килә. Моннан тыш, ул журналистлар белән тыгыз аралашып, үзенең идеяләре, фикерләре белән дә бүлешә.

1988 елдан Роберт Мияссәр улы районның балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе рәисенең урынбасары да. Аның актив катнашы белән районда профилактика чаралары уздырыла, балалар тарафыннан хокук бозу очраклары күзгә күренеп кими. Чөнки ул уйландыра да, ышандыра да белә, бер генә баланың язмышына һәм шәхесенә карата да битараф калмый.

ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АШКАНДА...

Нәкъ менә аның җиңел кулы белән 2021 елның 19 августында 80 нче мәктәпкә Каюм Насыйри исеме бирелә. 2022 елда яңа директорның тырышлыгы белән биредә инде Татарстан Республикасына бер булган Каюм Насыйрига скульптура композициясе куела.

Бүгенге көндә белем бирү учагы Каюм Насыйри мирасын иң югары кимәлдә өйрәнә – фәнни яктан да, әдәби яктан да, педагогик эшчәнлеге ягыннан да. 2022 елдан мәктәптә «Насыйри укулары» фәнни-гамәли конференциясе, экологик-географик конференция уздырыла. Бу конференцияләрдә мәктәп укучылары югары уку йортлары мөгаллимнәре һәм галимнәре белән турыдан-туры аралаша, үзләренең эшләренә бәя алып кына калмый, ә киләчәккә юнәлешләрен дә ачыклый. Шулай итеп, мәктәп җирлегендә Каюм Насыйри үзәге оеша.

Мәктәптә ТРның Көрәш федерациясе ярдәме белән «Каюм-батыр» дигән милли көрәш республика ярышлары, Мәктәп Сабан туе, әле Кукмарада эшләгәндә үк нигез салынган «БалаSKILS» бәйгеләре ел саен уздырыла. Бөтендөнья татар конгрессының «Ак калфак» җәмгыяте белән берлектә «Татар малае – 2022» шәһәр конкурсы үткәрелде. Балаларга эстетик тәрбия бирү өчен, Иске татар бистәсе һәм мәктәпнең тарихына багышланган Россия һәм Татарстан рәссамнарының 19 күргәзмәсе оештырылды.

Роберт Мияссәр улы һәм аның кул астында эшләгән тырыш, булдыклы коллектив көче белән мәктәп музее комплексы ныгый, зурая һәм аның фәнни базасы байый. 80 нче мәктәпне инде бүгенге көндә һәркем ишетеп белә, Каюм Насыйри дәвамчылары буларак бәяли һәм олылый.

ТЕЛ ҺӘМ МИЛЛӘТ САГЫНДА...

– Устав нигезендә Казан шәһәре Вахитов районының «Каюм Насыйри исемендәге аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 80 нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе булып исәпләнә, – дип аңлата безгә Роберт Мияссәр улы. – Биредә асылда Вахитов районың безнең мәктәпкә беркетелгән микрорайонында яши торган балалар укый. Милли составка килгәндә, укучыларның күпчелеген – 58% татар балалары тәшкил итә, икенче урында – руслар – 24% һәм тагын егерме процентка якыны – башка милләт вәкилләре. Боларга нигездә азәрбайҗаннар, үзбәкләр, таҗиклар, кыргызлар, гарәпләр, кытайлар, вьетнамнар керә. Балалар үзләренең кайсы мәктәптә укуын, Насыйриның кем икәнлеген, нинди традицияләрнең дәвамчылары икәнен яхшы аңлый, без бу юнәлештә актив эш алып барабыз.

Нәтиҗәләре дә күренә, билгеле: мәктәпкә килеп керүгә, кунакларны татар телендә каршы алалар, төрле милләт балалары татар җырларын башкаралар, милли каһарманнарны, мәдәниятне, әдәбиятны беләләр. Монда урнашкан якшәмбе мәктәбе дә башка милләт балаларын татар мохитенә якынайта. Әмма, шуның белән беррәттән, бу аларның үз милли үзенчәлегенә хилафлык китерү бәрабәренә түгел, киресенчә, биредә бөтен милләтләргә карата да зур хөрмәт тәрбиялиләр.

– Бу уку йорты хәзерге хәлендә эшләп китсен һәм яшәсен өчен, республиканың иң югары җитәкчелегеннән башлап, барлык буыннардагы фидакарьләре дә олы көч куйды – без моны һәрдаим истә тотып, рәхмәтле булып, бурычыбызны белеп эшлибез һәм яшибез, – ди Роберт Мияссәр улы. – Форсаттан файдаланып, республика җитәкчелегенә, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгына, Казан Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә олы рәхмәтемне белдерәм, мәктәп коллективының эшен күрүләре – алга барыр өчен зур этәргеч.

Коллективның киләчәккә планнары тагын да зуррак. Барысын да тормышка ашырып чыгар өчен, көч-куәт һәм уңышлар телик!

китап к

ДЖЕК ЛОНДОН АРКАСЫНДА ФИЛОСОФЛАРНЫ УКЫДЫМ

Марат Кәбиров шәхесе һәм иҗаты бүгенге чор әдәбиятында аерым бер урын алып тора. Ул гел турыга гына сызган сукмаклардан йөрергә яратмый, аларны күбрәк үзе салырга омтыла. Беренчеләрдән булып, ул XX йөз азагы – нуленче еллар әдәбиятына Көнбатышның бестселлер булып йөргән романнары рухын, синтезын кертеп җибәрде, жанрлар белән эксперимент ясарга курыкмады, элитар һәм масса әдәбияты арасындагы чикләрнең ни дәрәҗәдә шартлы булуын исбатлады, укучысы белән онлайн-платформалар аша турыдан-туры аралашуны җайга салды.

Яшьлеге Әфган афәте елларына туры килеп, андагы мәхшәрнең шаһиты да булган Марат Кәбировның бу темага әсәрләре дә бар. «Сары йортлар сере», «Акбабайның туган көне», «Убырлар уянган чак», «Мәхәббәттән җырлар кала», «Бердәнбер һәм кабатланмас», «Елмаю», «Китап» һ.б. әсәрләрен китап кибетләреннән алып та, язучының үз сайтыннан алып та укырга була.

Ә үзе кемнәрне укый соң Марат Кәбиров?

МИН ХӘТЕРЛӘГӘН БЕРЕНЧЕ КИТАП...

Исемен белмим, әмма гарәп имлясындагы китаплар күп иде бездә. Аларны кешегә бик күрсәтмәскә тырышалар. Шуларны идәнгә тезеп, машина итеп уйнаган өчен әрләгәннәре хәтердә.

БАЛАЧАК КИТАПЛАРЫМ...

Әнгам Атнабаев шигырьләре. Шуның белән хәреф танырга өйрәндем. Аннан Мостай Кәрим, Наҗар Нәҗми, Һади Такташ, Муса Җәлил, Хәсән Туфан китаплары укылды. Чәчмә әсәрләрдән Динис Исламов, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники китаплары.

Фотолар Марат Кәбиров архивыннан алынды

иштәсе

ДОМИНО ПРИНЦИБЫ, ДИЛӘРМЕ ӘЛЕ АНЫ, БЕР АКЫЛ ИЯСЕ БЕЛӘН ТАНЫШКАЧ, ИКЕНЧЕСЕНЕҢ ФИКЕРЕ ДӘ КЫЗЫКСЫНДЫРА.

Руслардан Достоевскийны нык яраттым. Хис-тойгыларны тотып карарлык дәрәҗәгә җиткерә ала торган язучы. Шуннан Чехов, Лев Толстой хикәяләре. Боларның берсе дә балалар өчен язылган әсәрләр түгел иде. Балалар әдәбиятын мин үскәч кенә, үземнең балалар булгач кына укый башладым бугай. Бәләкәй чактагы язучылар егет булганга кадәр озатып барды. Әле дә укыштырам.

ҮСМЕР ЧАГЫМДА НЫК ТӘЭСИР ИТКӘН КИТАП...

Джек Лондонның «Мартин Иден», Габриэль Гарсиа Маркесның «Ялгызлык» романы – боларны мин тәүге мәртәбә татар телендә укыдым. «Мартин Иден»да кешенең югарырак баскычка күтәрелү өчен көрәше, рухи үсеше сурәтләнә. Ул минем офыкларны киңәйтеп җибәрде – романда телгә алынган философларның, шагыйрьләрнең әсәрләре белән танышуга этәрде. Джек Лондон аркасында бик күп философларның китапларын укып чыктым.

«Мартин Иден»да иң гаҗәпкә калдырган нәрсә социализмның билгеле бер вакыттан соң җимереләчәге турындагы фикер булды. Коллар җәмгыяте җимереләчәк дигән фикер үзе дә, аны СССРда бастырып чыгарулары да гаҗәп иде. Аңа кадәр ике тапкыр укыган булсам да, СССР таркалгач, тагы бер кат укып чыктым.



Гарсиа Маркесның «Ялгызлык» романы язылышы белән дә, укылу үзенчәлеге белән дә аерылып тора. Аның телгә алып сөйләрлек сюжеты да юк кебек, тик укып чыкканнан соң, шул китаптагы тормышны сагыну тойгысы кала. Кала, яши. Озак яши. Ул тойгы китапны кабат укып та басылмый. Ул тойгы миндә әле дә яши.

ТОРМЫШЫМДА ИҢ МӨҺИМ КАРАР КАБУЛ ИТӘРГӘ БУЛЫШКАН КИТАП

Тормышта мин мөһим карарлар кабул итеп текә борылышлар ясамадым. «Менә шул китап булмаса, болай итмәс идем», – дип әйтә алмыймдыр. Тетрәндергән әсәрләрнең һәркайсы җанда үз чагылышын тапкандыр. Шул ук «Мартин Иден», шул ук «Ялгызлык», мәсәлән. Андрей Платоновның «Котлован» дигән әсәре. Минем «Сары йортлар сере» һәм «Акбабайның туган көне» повестьлары шушы әсәрләр тәэсирендә язылды. Владимир Набоковның «Лолита»сы, Патрик Зюскиндның «Парфюмер»ы – болар уку барышында үзгәрә, «борылып ята» торган әсәрләр. Укыган саен яңа яклары белән ачыла торган. Мин аларга сокланып: «Карале, болай да язып була икән!» – дип йөрдем. Нәтиҗәдә, үземнең «Елмаю» романы барлыкка килде – вакыйгаларның да, персонажларның да астын-өскә әйләндерә торган әсәр.





Барысын да санап тормыйм. Укып чыккан һәр яхшы китап мине дә үзгәрткән, әйбәтрәк итәргә тырышкан.

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

Нигездә, әдәби осталыкны үстерү турындагы нон-фикшн. Яңалыгы да, файдасы да юк инде аларның, эш режимына күчәргә ярдәм итәләр – шул гына. Һәм бу мөһим кебек. Дөнья җәмәгатьчелегенең игътибарын яулаган әсәрләр, бестселлерлар. Нәрсәгәдер өйрәнергә теләп укыйм да – бик килеп

чыкмый. Мин хәзер дә элекке китапларны күбрәк кулга алам. Дэниел Киз, Рэй Брэдбери, Стивен Кинг, Харлан Эллисон, Уильям Голдинг, Фатих Әмирхан, Мәхмүт Галәү, Фатих Хөсни, Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Флүс Латыйфи... Горурланыбрак әйтә торган бер нәрсә бар әле тагын... «Дөньякүләм бестселлер» дип тәкъдим ителә торган китаплардан үзебезнең татар язучыларының әсәрләре күпкә әйбәтрәк. Мин аңа әсәрләрне, нигездә, «Казан утлары» журналыннан укыйм. Һәркайсы үзенчәлекле. Прозага яшьләрнең килүе, яңа исемнәр күбәюе сөендерә. Исемләп әйтеп тормыйм, я берәрсен онытып калдырырмын. Болай дип кенә әйтәм: яхшы әсәрләр языгыз, сезне мин укыйм.

СОҢГЫ АРАДА ИҢ ТЕТРӘНДЕРГӘН ӘСӘР...

Андый әсәрләр юк бүгенге әдәбиятта. Әллә минем күңел каткан, әллә язучылар йомшарган. Бәлки, икесе дә бардыр. Хәзер бит укучыны җәлеп итү дә бик авыр, аны берни белән дә аптыратып булмый. Фаҗигале үлемнәргә, төрле һәлакәтләргә, шартлауларга гадәти хәл итеп карый торган халык бит ул! Үз тормышына битараф кеше кемдер язган китапка капланып елап утыра алмый инде. Бәлки, бүгенге чор кешесен яктылык белән тетрәндереп буладыр. Елатырлык матурлык белән...

КАЙСЫ КИТАП МИНЕ БӨТЕНЛӘЙ ҖӘЛЕП ИТМӘДЕ...

У-у-у-ууу... Адәм гомере болай да кыска, аларны санап вакыт уздырмыйк инде.

ЯРАТКАН ҺӘМ УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘ ТОРГАН КИТАПЛАРЫМ...

Яраткан әсәрләрнең бер ишен югарыда телгә алдым... Бер мәлне миңа соңгы ун елда басылган яхшы романнар исемлеге төзергә туры килде. Бүтән алай кыланмыйм. Аннан соң, китап та бәхет шикеллерәк бит инде ул. Бөтен кешегә дә ярый торган бәхет булмый. Булган хәлдә дә аны һәркем үзе табарга тиеш. Бәхетсезләр дә аңласын өчен, кием кебек дияргә дә буладыр, чөнки син һәр әсәрдә кемнеңдер тормышын, язмышын киеп карыйсың. Бөтен кешегә дә ярашлы кием булмый. Китап та шулай. Мин яраткан китапларны ярату өчен минем кебек булырга кирәк.

ӨСТӘЛ КИТАБЫМ...

Кинәт кенә карадым да менә – Ркаил Зәйдулла белән Газинур Морат китапларына күзем төште. Берсе – «Сунар», икенчесе «Ике икең биш була» дип атала. Укылган инде алар, шулай да вакыт-вакыт актарып чыгам. Өстәл китаплары дияргә мөмкин бугай. Электрон вариантта Луиза Янсуарның «Минем чәчем җиде толым» романы тизрәк укыганны көтеп ята. Лилия Фәттахова, Лилия Гыйбадуллина, Ландыш Әбүдәрова, Гөлүсә Батталова, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рөстәм Галиуллин әсәрләрен, иркенләбрәк укыр өчен, дип, интернеттан җыеп куйдым. Өстәлдә торгач, алар да өстәл китабы инде.

БЕРКАЙЧАН ДА ИСКЕРМИ ТОРГАН КЛАССИКА ДИП ИСӘПЛИМ...

Бүгенге чорда язылган бер әсәрне дә алай дип әйтә алмыйм. Мин әйтә торган сүз түгел бу. Вакыт әйтергә мөмкин. Тик кайчакта ул да дәшми кала.

КӘГАЗЬ КИТАПМЫ, ЭЛЕКТРОН ФОРМАТМЫ?

Икесе дә. Кәгазь китапның үз өстенлеге бардыр. Электрон китапларның – үзенеке. Мин электрон китапларны ешрак кулланам, чөнки мөмкинлекләре күбрәк – хәтта телевизор экраныннан да укырга була. Күп җайланмаларда кеше тавышы белән дә укытырга мөмкинлек бар. Мин барысын да укыйм. Һәркайсы үз урынында кирәк, алар бер-берсен алыштыра алмый.

АУДИОКИТАПЛАР...

Әлбәттә! Нindидер тынычрак эш эшләп йөрисең, әйтик, бакча утыйсың, я кар көрисең, ә китап укыла. Вакытны икеләтә файдалы үткәрүнең иң җайлы ысулы.

КИТАП – МИНЕМ ӨЧЕН...

...мәгълүмат чыганагы. Юк, болай дип әйтергә кирәктер... Бүтәннәр язган китап ул – рухи, ә үзем язганы матди байлык чыганагы.

ҮЗ КИТАПЛАРЫМНАН КАЙСЫЛАРЫН УКЫРГА ТӘКЪДИМ ИТӘР ИДЕММЕ?

Тәкъдим итмим берсен дә. Уены-чыны итеп кисәтәм генә: әгәр Марат Кәбиров китапларын укымый калырлык көч таба аласыз икән, укымаска тырышыгыз.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-79
8-9600-487-900
8-9033-132-741

Реклама 16+



КАЙНАР БУЛОК: ТАУ БАШЫНДАГЫ КЫШЛАК

КАЙНАР БУЛОК

«Татарстан»ның сәяхәтчеләрен кайда гына йөртми язмыш! Кайвакыт бөтенләй Татарстанда булмаган авылларга да барып чыгарга туры килә. Шунысы кызык та инде: кардәшләрнең яшәү рәвешен күрү, аны безнеке белән чагыштыру, барлык авыл-кышлакларда да бердәй ачык йөзле, кунакчыл, дустанә кешеләр белән танышу үзе генә дә ни тора бит!

Шулай итеп, авыл тормышы белән хозурлану өчен Үзбәкстанның ераграк төбәкләренә җыенабыз.

Татьяна Вафина

Шәһәр Үзбәкстаны һәм авыл Үзбәкстаны – икесе ике төрле Үзбәкстан ул. Һәм аларның кайсысы яхшырак икәне билгесез әле. Шау-шулы заманча Ташкенттан борынгы гүзәл Сәмәрканд аша Кашкадәрья өлкәсенә, биек-биек таулардагы Кайнар Булок авылына юл тотабыз.

КАШКАРЫЙЛЫ ЮЛ

Асфальт юл чите буенча, аны җәйге кояш көйдереп бетергән кырлардан аерып, төрле төстәге кашкарыйлар үсә. Андыйларны без гадәттә дачаларда утыртабыз. Тик моның кадәр күп итеп түгел. Кашкарыйлар шулкадәр җете һәм бик купшы, ак, шәмәхә, куе кызыл төстә... Без бакчада гына күрергә күнеккән чәчәкләрнең сафлыгы һәм матурлыгы юл-кыр шартларында шулкадәр гайре табигый ки, гүя кемдер, безнең машина алдыннан йөгереп, махсус әзерләнгән чокырларга аларны тиз-тиз утыртып бара.

Автор фотолары

Гаҗәеп Зарафшан таулары.

Әлбәттә, бу алай түгел. Әмма мондый уйлардан тагын да күңеллерәк булып китә – ни әйтсәң дә, Үзбәкстанда кунакларга бәйрәм ясый беләләр икән бит. Хәтта гап-гади юл буенча барганда да.

Кайбер җирдә кашкарыйлар урынына юл кырыйларын кавын яки лимон таулары бизи. Кайвакыт кипкән җиләк-җимеш өемнәре калка һәм юл буйлары базарга әверелә. Анда сезгә соралган 200 грамм өрек яки кипкән инҗир урынына шул ук бәягә икесен дә берәр килограмм итеп үлчәп бирәләр...

Кыскасы, Үзбәкстан юллары буйлап йөрү – үзе бер ләззәт. Әмма бу ләззәтне язын яки безнең кебек көз көне алу яхшырак, чөнки җәен – эссе, кышын – юллар пычрак. Рәхәт чакта, башыңда менә шул кашкарыйлар турындагы уйлардан башка, бернинди проблемалар булмаганда...

ТАХТАКАРАЧА ҮТКЕЛЕНДӘ

Кашкадәрья өлкәсенә аяк басабыз. Мондагы таулар, кайбер урыннарда туристлар калдырган «Здесь был Вася!» стилендәге язмалар очраштыргаласа да, Марс планетасы пейзажларын хәтерләтә. Шуңа да карамастан, тау – тау инде ул, бигрәк тә Зарафшан таулары. Сәмәрканд белән Кашкадәрья өлкәләрен тоташтыра торган Тахтакарача үткеле безне бик тә хозурландыра. Таулар хәтта хәзер, көз көне дә матур, тик монда шулкадәр дымлы һәм томанлы ки, машинабыз томанга чумган шул үткелгә кинәт төшеп китәр төсле тоела...

Тау башындагы «Катта тош» («Ак таш») кафесында безне тандырда әзерләнгән төшке аш көтә. Тандыр гына да түгел, бәлки тауны чокып ясалган гаять зур балчык тандырлардан торган тулы бер «цех» бу. Һава торышы нинди генә булса да, ит яратучылар тау башындагы бу кафедан өзелеп тормый дип сөйләделәр безгә.

Сәгать саен тандыр ыргакларына биш кешедән торган команда ылыс һәм тозда маринадланган сарык итен элеп куя. Ит өстенә туя ботаклары салына. Һәр тандырга атаклы Кукмара продукциясен (Аны монда бик яраталар, диләр. Ташкент-ситида хәтта Кукмара табасына һәйкәл дә куелган. – *Ред. иск.*) хәтерләткән гаять зур казан каплана. Аннан соң казанны тукыма белән урыйлар да өстенә балчык сылыйлар. Сарык ите шунда сәгать ярым буе мәмрәп пешә, аны татып караган кешегә бөтен барлык ит тә тәмсез тоела башлый...

Бу ризыкка мөкиббән халык бирегә әллә кайлардан килергә, сәгатьләр буе чират торып, дастархан бушаганны көтәргә әзер, чөнки үткелдә андый урыннар икәү генә.





Сәгать саен тандыр ыргакларына биш кешедән торган команда ылыс һәм тозда маринадланган сарык итен элеп куя...



Икрам әкә белән Әкрам әкә.

ИКРАМ БЕЛӘН ӘКРАМ

Икенчесенә, астарак, шарлавыклар янында урнашканына безне кунакчыл дусты Әкрам янына шундый ук кунакчыл Икрам алып бара.

Әкрамның кафесы тау битендә урнашкан һәм «Шаршара» дип атала, бу «шарлавык» дип тәрҗемә ителә.

Әлеге матур урындагы дастарханлы террасалар берьюлы меңгә кадәр кунакны – салкынча җиләс һавада сыйланырга ятучыны сыйдыра ала.

– Җәй көне бу Үзбәкстанда иң салкынча урын, – ди Әкрам. – Салкынрак җир эзләп, барысы да монда, шарлавык янына агыла. Ташкенттан, Мәскәүдән, башка шәһәрләрдән киләләр... Урын җитми, мин хәтта кайчакта телефонны да алмыйм, чөнки барысы да иртәдән кичкә кадәр шалтырата һәм үзләренә урын калдыруны сорый...

Әкрам әкә белән Икрам әкә*, тандырда пешкән иң тәмле ит белән сыйлаганнан соң, безне кышлакка экскурсиягә озата.

– Кайтканда да миңа сугылыгыз! Кичке ашка! Көтәм! – дип, Әкрам әкә безнең арттан кул болгап кала.

Керергә вәгъдә бирәбез.

ИШӘКЛӘР ҺӘМ СЫЕРЛАР

Сочиныкыннан да текәрәк булган Зарафшан серпантины буйлап барып, Кайнар Булок кышлагына керәбез.

Каршыбызга бик моңсу тоелган бер ишәк очрый – нәкъ менә Винни Пух турындагы мультфильмдагы Иа диярсең. Экраннан сикереп төшкәнмени!

Яңгыр килә бугай, дигәндәй, ул вак яңгыр сибәли башлаган болытка карап куя.

...Кышлакта караңгы төшә. Тау көтүлекләреннән сыерлар кайта. Алар яңгырга һич тә игътибар итми, кайбер урыннарда үсеп утырган үләнне чемченүен дәвам итә.

– Монда сыерлар арык, чөнки тауда йөреп май туплап булмый, – дип аңлата Икрам әкә хайваннарның арыклыгын. – Аның каравы, тау көтүлекләреннән соң аларның сөте бик тәмле!

ТАУ ҺАВАСЫНДА ТАГЫН ДА ТӘМЛЕРӘК

Кышлак йортларының берсенең капкасы ачык. Аннан биш яшьләр тирәсендәге бер кызчык күренә. Ул түземсезләнеп сикергәли-сикергәли кунак көтә. Әнисе Мөһия безне өенә чакыра.

– Безнең йортка 100 ел, – ди ул, горурланып. – Без монда тудык, үстек – җиденче буынга кадәр барыбыз да.

Әкрам әкәнең шәхси бөркете.

Биредә Кашкадарья районы башлана. Күзәтү мәйданчыгы.

Әкә - өлкән яшьтәге ир-атка ихтирам белән мөрәҗәгать иту.*

Шундый олпат яшенә карамастан, йорт бик яхшы сакланган, кунакларга өр-яңа пластик тәрәзәләре белән күз кысып утыра. Бусагада хуҗабикә Мәүсүдә Мүйиддинова көтеп тора. Безгә үзенең биләмәләрен күрсәтә: бакча, кечкенә генә «ике бүлмәле» сарай, аның берсендә кышкылыкка әзерләнгән яшелчә һәм җиләк-җимеш – бәрәңге, кабак, татлы хөрмә әрҗәләргә тутырылган...

– Ә менә монда кабартма пешерәбез, – дип, икенче бүлмәгә чакыра Мөһия һәм өй тандырын күрсәтә.

Бүген нинди генә тандырлар күрмәдек без! Зурысын да, кечкенәсен дә, сорысын да, агын да, түгәрәген дә, озынчасын да, хәтта менә шундый – уң ягында тишекләләрен дә... Тандыр, рус йортында мич кебек, үзбәкләрнең милли байлыгы, ахрысы. Без сыйланган атаклы үзбәк кабартмалары тандырда гадәттән тыш тәмле булып пешеп чыга, чөнки искиткеч саф тау һавасы да кушыла кебек.

100 еллык йортның хуҗабикәсе Мәүсүдә Мүйиддинова.

Кышка запас.

Без сыйланган атаклы үзбәк кабартмалары тандырда гадәттән тыш тәмле булып пешеп чыга, чөнки искиткеч саф тау һавасы да кушыла кебек.

– Ә менә монда кабартма пешерәбез, – дип, икенче бүлмәгә чакыра Мөһия һәм өй тандырын күрсәтә.

Күрше бүлмәдә бишектә Мәүсүдәнең оныклары – бер яшьлек игезәкләр Фатыйма белән Зөһрә йоклый.

Фатыйма сеңлесе Зөһрәдән иртәрәк туа һәм, күргәнебезчә, йокыдан да иртәрәк уяна икән.

ФАТЫЙМА БЕЛӘН ЗӨҺРӘ

Мәүсүдәнең биш кызы бар, барысы да – кияүдә. Менә ике кызы – Мөһия белән Иборат – балалары белән әбиләренә кунакка килгән. Электр плитәсендә бик зур мантый кәстрүле тора. Күрәсең, төшке аш әзерләнә.

Күрше бүлмәдә бишектә Мәүсүдәнең оныклары – бер яшьлек игезәкләр Фатыйма белән Зөһрә йоклый.

– Сезне көттеләр-көттеләр дә йоклап киттеләр, – дип елмая әниләре Иборат.

Шул арада игезәкләрнең берсе, күрәсең, кунаклар тавышын ишетеп уянды да, имезлеген таптыра һәм кулга алырга кушып еламсырый башлый. Үзе күзен тутырып кунакларга карый.

Икенчесе татлы мышнап йоклавын дәвам итә.

Безнең өчен шунысы гаҗәп: шундый сабыйлар да бик җылы киенгән – башлык, куртка, йон оекбашлардан, кәбестә кебек төренеп, өч кат юрган астында яталар...

– Үзбәкстан көньяк ил булганга җылылык системалары каралмаган, без өйне урамда бик салкын вакытта гына җылытабыз, – дип аңлата хуҗабикә. – Әлегә түзәрлек.

Кемдәдер «җылылык» – газ баллоннарында, кемдәдер – мич утынында, кемдәдер җылыткычларда саклана.

АЕРЫМ БҮЛЕК

Игезәкләргә исем кушу тарихы аерым бүлеккә язарга лаек. Әгәр үзбәк гаиләсендә игезәк кызлар туа икән, аларга Фатыйма һәм Зөһрә исемнәре кушалар. Өстәвенә, олысы һәрвакыт Фатыйма. Ул сеңлесеннән иртәрәк туа һәм, күргәнебезчә, йокыдан да иртәрәк уяна икән.

Игезәк малайлар белән дә шундый ук хәл. Аларны бары тик Хәсән һәм Хөсәен дип кенә атыйлар – шулай ук өлкәнлек буенча. Димәк, әгәр сез Үзбәкстанда Фатыйманы очратсагыз, белегез, аның һичшиксез игезәк сеңлесе бар. Игезәк кыз һәм малайга исем шулай ук бу традиция буенча кушыла. Дөньяга

100 ел яшәгән йорт.

беренче булып кыз туган икән – Фатыйма исеме кушылачак. Икенче булып туган малайга Хөсәен исеме биреләчәк. Һәм – киресенчә. Гомумән, беренчесенә – беренче исем, икенчесенә – икенче. Менә шундый игезәкләр математикасы.

...Мәүсүдә Мүйиддинованың кунакчыл гаиләсе белән саубуллашып, кире кайтырга ашыгабыз. Тәрәзәдән безгә биш яшьлек Сәрвиназ кул болгый. Ә тегендә, биек-биек тауларда, шарлавык янында, тандырда тагын да шәбрәк сый-нигъмәт әзерләп, безне кунакчыл Әкрам әкә көтә...

– Яңгыр килә бугай...

Мәүсүдә Мүйиддинованың кунакчыл гаиләсе.

НИЧЕК БАРЫРГА:
Башта Сәмәркандка барып җитәргә кирәк. Һәм аның бөтен дөньяга танылган истәлекле урыннарын карап чыгып, тау юлы белән Кашкадәрья өлкәсенә китәргә. Кирәкле ноктага кадәр ераклык – якынча 70 км

КАЙДА ТУКТАРГА:
Кышлакка бару юлында тандырлар бик күп. Әмма тандырда пешкән иң тәмле сарык итен ашыйсыгыз килсә, Икрам белән Әкрамны исә тотыгыз. Үкенмәссез.

НӘРСӘГӘ ГАҖӘПЛӘНЕРГӘ:
Тирә-юньдәге искиткеч матурлыкка. Мондагы илаһи тынлыкка. Биредәге саф-чиста табигатькә.

НӘРСӘГӘ ӨЙРӘНЕРГӘ:
Әлбәттә инде, легендага әйләнгән үзбәк кунакчыллыгына. Заманча шәһәрдәме сез, ерак кышлактамы, әллә биек-биек таулардамы – кайда булуыгыз мөһим түгел, сез һәр җирле кеше өчен кадерле кунак булырсыз. Һәм һәрвакыт тук һәм канәгать. Шундый ул Үзбәкстан – халкының ихласлыгы һәм кунакчыллыгы сәбәпле, һәрвакыт кояшлы һәм тәмле.

ай кәефе тугралы

КАНАТЛЫ БАРС НИ СӨЙЛИ

Рәссам һәм сынчы Бакый Урманче музеенда Татарстан туграсына багышланган классик гарәп каллиграфиясе күргәзмәсе ачылды.

Күргәзмәдә Казанның оста каллиграфы, Россия ислам институты каршында Гарәп каллиграфиясе үзәгенә нигез салган Рамил Насыйбулловның сигез хезмәте урын алган.

Рамил Насыйбуллов – күренекле кешеләрнең, шул исәптән Россия Президенты Владимир Путинның, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның һәм башка бик күпләрнең шәхси тугараларын ясаган кеше.

Күзгәзмәнең үзенчәлеге – «Безнең барс» – Татарстан символы. Бирегә килгән кунакларга республиканың канатлы символы төшерелгән туграсы турында тулырак итеп тарих фәннәре докторы Искәндәр Измайлов сөйләде:

– Бабаларыбызның беренче символлары сыйфатында төрле тамгалар йөргән, тора-бара алар төрле сурәтләр белән алыштырыла башлый. XVI–XVII гасырларда, инде Рус дәүләте составында, Казан патшалыгында (воеводасында, соңрак – губернасында) җирле традицияләргә һәм риваятьләргә нигезләнгән үз символлары пәйда була. Зилант белән Барс шундый символлардан санала, – дип аңлатты ул.

Чара ахырында Рамил Насыйбуллов мастер-класс оештырды. Анда һәркем татар каллиграфиясе традицияләрендә ясалган үз исеме үрнәген алды.

Фото: Александр Ефремов


«КАЛЛИГРАФИЯ - ГЕОМЕТРИЯ ДУШИ, ВЫРАЖЕННАЯ ЧЕРЕЗ МАТЕРИАЛЬНОЕ»
Author: Ramil An-Namir (Nasybullah), Kazan, TATARSTAN, 2024

بوتون دنيا تاتارلري

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:
тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

Реклама 16+